КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни җомга

№ 5
18 август
1995 ел

...елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

...ҮГЕНГЕ САНДА:

Җәүдәт ДӘРЗА-...МАН. Җан җәрәхә-...ләрегезгә шифа ...булырдай нинди дә-...валар табыйм...

Флүн МУСИН. ...алачактан ук та-...тарлар белән якын-...нан аралашкан һәм ...дуслашкан Абай бу ...гаиләнешне гомере-...нең ахырына кадәр ...саклый.

...0 *Солтан* ШӘМ-...СИ. Казан ханлы-...гын Алтын Урда ...дәүләтеннән аерып ...карау һич тә мөм-...кин түгел.

...2 *Илдар* НИЗА-...МОВ. Җәмәгатьче-...лек йокыда булгач, ...житәкчеләргә дә ...ел сәясәте дип бо-...рчыласы юк.

...9 *Заһид* МӘХ-...МУДИ. Хатын-кыз ...ягында, министр-...лар да кәнәфилә-...реннән очкан очрак-...лар азмыни?..



بسم الله الرحمن الرحيم

**Бар да мулла булмак, бар да – Алла,
Ә печәнне атка кем сала?..**

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Мөхтәрәм дәүләт җитәкчеләре!

Көннәрнең берендә үзегезнең курсташларыгыз яки са[-]
таш-шәрикләрегез белән очрашыгыз әле. Бәлки, алар [...]
лыкка якынрак торып, тормыш агы-зыгысының үзәге[-]
рәк кайнаучылардыр, һәм яшьлек дусларыгызның, элекке [...]
лас сабакташ буларак, уйнамый-боргаланмый, туры[-]
ярып әйтерлек мөһим сүзләре бардыр. Кем белә, мө[...]
очрашуларның Сезгә генә түгел, безгә дә күзелле [...]
файдалы булып куюы бар

Мансуров Зиннур МАНСУ[РОВ]

КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ

Җәүдәт ДӘРЗАМАН

Дөнья матур, дөнья киңме?

Эш бүлмәмә университет елларындагы сабакташым Рафикъ Хаҗиев килеп керде. Күрешмәгәнебезгә чирек гасыр гомер узган булса да, кичә генә аерылышкандай җылы күрештек. Рафикъның Биектау районы Чыпчык урта мәктәбендә байтак еллар тарих укытуын белсәм дә, моңарчы очрашырга туры килмәгән иде.

— Килеп чык әле безнең якларга, — диде ул, хәл-әхвәл сорашканнан соң, ерактан уратып тормыйча гына. — Син — каләм әһеле, әйбәт кешеләр белән танышырсың. Бәлки язмышлары киләчәктә берәр әсәреңә ярап куяр. Табиблар алар, күптән түгел генә Кыргызстаннан кайттылар. Суфия ханым үзебезнең участок шифаханәсендә эшли, врач-терапевт. Илдар — Биектау район шифаханәсендә анестезиолог.

Сизенәм инде, күчәрләрен язмыш арбасы бәрелештермәсә, тикмәгә генә язучы сабакташын эзләп килмәс иде Рафикъ. Аңа гамьсез генә:

— Ирле-хатынлы врачлар күп инде алар, — дигән булам.

— Ашыкма син, сөйләп бетергәнне көт! — ди сабакташым, кабынып китәргә чамалап. — Бер дигән белгечләр. Авыл халкы шушы аз гына арада да яратып өлгерде үзләрен. Чыпчыкның урыс авылы икәнен онытма. Һәр өйдә «безнең Суфия» дә «безнең Илдар» дип кенә торалар. Үзең беләсең, халыкның сәламәтлеге ташка үлчим бит хәзер. Авылда яшеннән карты күбрәк. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында дәштерәләр. Суфия ханымның чакырган җиргә баруы табигый, чөнки аның үз участогы. Илдарга да тынгы юк. Үзем дә аптырыйм инде. Һәркөнне йөреп эшли, таңнан китә, соң кайта. Көне-төне — сырхаулап киткән авылдашлары арасында... Юкса, хезмәт вазифасына керми бит ул аның. Әллә шул, Гиппократ анты дисәң генә инде...

— Соңгы вакытта үзеннең дә мотор кызгалый дибрәк ишеткән идем...

— Кызып кына калса икән... — дип ачынулы елмайды сабакташым. — Беркөнне цилиндр чатнамасынмы... Инфаркт... Ярый әле Илдар белән Суфиянең өйдә чагына туры килде. Алып калдылар тәки...

Дөресен әйтим, күңелемдә журналист комарлыгы кузгалса да, Рафикъ киткәч, сүрелә төште. Күпмедер вакыттан соң, вәгъдә — иман икәнлеге исемә төшеп, Чыпчык авылына юл тоттым. Ул чакта куенына гарасатлы яшеннәр яшергән язмышлар болытына килеп керермен дип кем уйлаган...

Илдар эштә чакта өйләренә барырга яхшысынмыйча, Суфия ханым белән Рафикъ-лар гаиләсендә очраштык. Җыйнак гәүдәле, олы кара күзле, ачык йөзле, үтә тыйнак бу ханым үз дәрәҗәсен, тормышта үз урынын яхшы белгәнгә охшый иде. Чәй өлгергән арада яңа танышым үз башыннан узган байтак кына гыйбрәтле вакыйгаларга тукталырга өлгерде. Ул тумышы белән Ош шәһәреннән, ә тамырлары Башкортстан якларына барып чыга икән. Ерак тамырлары исә, әлбәттә, биредә — Татарстан туфрагында... Балачактан әдәбиятчы булырга хыялланган. Матур әдәбиятны су урынына эчә идем, дип елмая Суфия ханым. Әмма күршедәге яһүд гаиләсе аның сайлаячак һөнәрен сиздерми генә акрынлап бөтенләй башка юнәлештән җибәрә. Кыз кергән саен күршеләре китапханәләреннән башта табиблар тормышын тасвирлаган әдәби китаплар, алар эченә тәмам кереп киткәч, фәлсәфи, гыйльми хезмәтләр белән мавыктырып, кыз күңелендә табиблык һөнәренә мәхәббәт уятуга ирешәләр. Әмма керү имтиханнары җиткән сәгатьләргә кадәр икеләнә Суфия, ике институтка берьюлы әзерләнә. Бары тик соңгы минутларда гына аны Фрунзе медицина институтына барырга күндерәләр.

Илдар белән танышуга килгәндә... Суфия ханым моңсу гына елмаеп куйды:

— Беренче күрүдә үк гашыйк булдым, дип әйтә алмыйм. Мин — шәһәр кызы, ул — авыл егете. Тирәмдә бөтерелгән купшы егетләр дә аз түгел иде... Әмма Илдар, аз сүзле булса да, чамасыз үҗәт булып чыкты. Аннан соң, институтта татар егетләре бармак белән генә санарлык. Бик теләсәң дә, әллә ни сайлана алмыйсың...

Чәйләп алганнан соң Суфия ханым безне үзләренә алып китте. Участок шифаханәсенең ишек алдында, кайчандыр земский врач яшәгән ике катлы йортның өске катында торалар икән. Ашалып беткән такталары аяк баскан саен ыңгырашкан тар баскычтан күтәрелеп, ишекне ачуга, олы яшьләрдәге ике әби-карчыкка тап булгач, югалып калдым — алар хакында миңа берни дә әйтмәгәннәр иде.

— Әссәламегаләйкүм, хәерле көннәр булсын!

— Вәгаләйкүмәссәлам, улым, әйдә, түрдән уз!

Уздык. Илдар белән уртак телне тиз таптык. Ул ифрат туры сүзле, бик үткен кеше икән.

— Беләсеңме, туган, ни өчен монда алып кайттым мин гаиләмне? Бу як кешесе мин, чөнки тамырларым монда өзелеп калган. Монда дигәч тә, төп нигезебез Кама Тамагы районының Каратай авылында безнең. Борһанетдин бабабыз бик хәлле кеше булган. Үз хезмәте белән көн күргән. Әмма революциядән соң аны бөтен гаиләсе белән раскулачивать иткәннәр, йорт-җирен талап алып, гаиләсен читкә сөргәннәр, каторжан хезмәтенә дучар иткәннәр. Геноцид ич бу, Сиражетдиновлар гаиләсенә геноцид, ахыр чиктә!

Илдә үзгәртеп кору, ниһаять, гаделлек тантана итәчәк икән, дип уйладым. Бабамның йорт-җирләрен кайтарып алу максаты белән хәтта районыбызны да урап килдем. Хат арты хат юллый торгач, бабамның акланууына ирештем, ә менә йорт-җирне кабат кайтару мәсьәләсе... Монысы кайчандыр мәҗбүри юк ителгән кешенең аклануы хакында кәгазь алу гына түгел икән шул... «Больше ничего не хочешь? На вот, понюхай!» — диделәр миңа җитәкчеләр, борын төбемә өч бармактан төйнәлгән кәҗә тоягы төртеп. Әмма минем кайту теләгем сүрелмәде. Татарстан хәбәрләрен дүрт күз белән көтеп ала идем. Мөстәкыйльлек хәрәкәте киңрәк колач җәйгән саен, кайту теләгем көчәя генә барды. Хатыным, аның туганнары, апасы белән әнием никадәр генә үгетләсәләр дә, күндерә алмадылар. Аңлыйм, урыннарыннан, соңгы нигезләреннән кубарылган карчыкларым монда инде кабат тамырлана алмаячаклар. Суфиягә шулай ук [...] лмаячак, анысын [...] Хәтта ике сабый [...] җиңел түгел мон[...] Алар да үзләренең [...] рын, бергә уйнаган [...] рен сагына. Әмма [...] ны кабат көйләп ж[...] сам, алар әле туг[...] станыбыз туфрагын[...] чак, нәселебезне мо[...] итәчәк. Аллаһы [...] Мин монда да туль[...] белән яшәргә тыры[...] занга еш барып йө[...] ли хәрәкәттә якын[...] шам, әле бу хакта к[...] каләләр дә язарга[...] нам.

— Кыргызстан[...] гыдан да, начаррак[...] соң тормыш шартл[...]

Илдар миңа га[...] хәтта беркадәр сә[...] тә карады.

— Син нәрсә, Җ[...] Оҗмах иде анда бе[...] катлы үз йортыбы[...] җимешләре үскән [...] бер дигән хуҗа[...] кош-кортларыбыз [...] Әмма нигез барыбе[...] Тегe чакны кайтка[...] эзләмәдем мин аны[...] лмәгән, аңламаган[...] мине ихтыярсыз шу[...] ргә алып килгән б[...] ты. Безнең нәселне[...] птән онытканнар. [...] ган картлардан сор[...] гезебезнең кайсы [...]

(Ахыры 17 нче б[иттә])

ХӘБӘРЛӘР
ЯҢАЛЫКЛАР

Президент җырчыны кабул итте

Президент Минтимер Шәймиев 15 августта Кремльдәге резиденциясендә күренекле җырчы, СССРның һәм Татарстан Республикасының халык артисты, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солисты Азат Аббасовны кабул итте. Алар арасында дусларча җылы әңгәмә булды. М.Шәймиев әңгәмәдәшен әле күптән түгел генә 70 яше тулу белән котлады, республиканың опера сәнгатен үстерүгә зур шәхси өлеш керткән өчен зур рәхмәт әйтте, иҗат эшен дәвам итүен, сәламәтлек һәм гаилә бәхете теләде.

Әңгәмәдә тамаша учреждениеләренең иҗади хәлен яхшырту, бүгенге кыен чорда әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренә матди һәм мораль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре күтәрелде. Президент иҗади сәхнә коллективларының иң яхшы традицияләрен саклау һәм бәсту кирәклегенә, А.Аббасов кебек милли горурлыгыбыз булырга сәләтле яңа яшь талантлар тәрбияләүгә аеруча игътибар бирде.

Юбиляр үз хезмәтенә югары бәя биргән өчен Президентка рәхмәт белдерде, аңа Татарстан халкы бәхетенә яңа уңышлар теләде.

Очрашуда республика мәдәният министры М.Таишев, опера һәм балет театры директоры Р.Мөхәммәтҗанов катнашты.

Хосусыйлаштыру дәвам итә

Татарстанда исемле хосусыйлаштыру чекларын өләшү тәгәлләнде. Республикада 147 миллиард 350 миллион сумлык (95,68 процент) чеклар таратылды. Аларны урнаштыру чорында 800 ширкәт, ягъни республика милкәтенең 51 проценты хосусыйлаштырылды.

Митинг-концертка килегез

1995 елның 30 августында көндезге сәгать 10 да Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры янында Татарстанның мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителүгә 5 ел тулуга багышланган митинг-концерт була. Аны «Суверенитет» комитеты, Татарстан бәйсезлек фиркасе үткәрә. Митингта күренекле артистләр, язучылар, җырчылар, биючеләр, сәясәтчеләр катнаша.

Кол Шәриф мәчете кайда булган?

Менә икенче ел инде Татарстан Фәннәр академиясе һәм Казан дәүләт университеты галимнәре Кремль тупрагында казу эшләре алып баралар.

Хәзер археологлар Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган корылмаларны чистарту белән мәшгуль. Благовещение соборы һәм Архиерей сарае янәшәсендәге зур кирпеч-таш корылма җимерекләре дә кызыклы табылдыклар рәтенә керә. Белгечләр исәпләвенчә, бу бинага XYI йөзнең беренче яртысында нигез салынган. Әлеге корылманың нәрсә өчен төзелгәнен казу эшләре тәгәлләнгәч кенә әйтергә мөмкин. Шулай итеп, Кол Шәриф мәчетенең урыны әле тәгаен билгеле түгел. Кремль тупрагында галимнәр шулай ук XIY йөзнең 70 нче елларында төзелә башлаган таш дивар калдыкларына тап булганнар.

Казу эшләре нәтиҗәсендә XII йөздә борынгы Казанның булу-булмау мәсьәләсенә дә ачыклык кертелде. Ук башлары, тимер пәрәшкә, пыяла һәм таш мәрҗәннәр табылу бу сорауга уңай җавап дигән сүз.

Машина, гараж һәм... китап

Язучы кеше бер генә заманда да рәхәт гомер кичермәгән. Ә бүгенге катлаулы икътисади чорда ул ярым ач, ярым хәерче булып яшәргә мәҗбүр. Китап бастыру матур хыялга әверелеп бара. Ә менә Локман Закир һич тә югалып калмады. «Таң» нәшриятында дөнья күргән ике китабын ул гаражын һәм машинасын сатып чыгарды. Әйе, язучы кеше башта үзенең матди хәле турында түгел, ә бәлки, әдәби әсәрләренең язмышы турында ныграк кайгыртырга тиештер...

«Кристина» тәмле су җитештерә

Казан каласындагы «Кристина» фирмасы көн дә 250 мең баллон тәмле су җитештерә. Алар — «Чия», «Урман җиләге» һ.б. — җәмгысе унбер төрле тәмле су.

Хәзер Казан шәһәре хакимияте карары нигезендә әлеге фирмага калабызның барча тарафларындагы кибетләрдә дә сәүдә итү хокукы бирелде. Шул ук вакытта «Кристина» җитештерә торган суларны кинотеатр һәм театр буфетларында да сату рөхсәт ителә.

Барысы да тәртип, барысы да яхшы, әмма Татарстан башкаласында татарча исемләнгән тәмле суларның һәм дә җәй буе... квасның булмавы пиктер гел эчне пошырып тора.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

«Россия Федерациясенең халык артисты» дигән мактаулы исемнәргә лаек булдылар:

Венера Әхәт кызы ГАНИЕВА — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының опера солисты;

Зилә Даян кызы СӨНГАТУЛЛИНА — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының опера солисты.

* * *

«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

Роберт Вәли улы ӘХМӘТҖАНОВ (Роберт Әхмәтҗан) — шагыйрь.

Рулан Генят улы ХӘБИБУЛЛИН — Чиләбе дәүләт сәнгать һәм мәдәният институтының кафедра мөдире.

«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек булды:

Фоат Галимулла улы ГАЛИМУЛЛИН — әдәбият галиме.

...якны алдан киенгәч

Кукмара районы типографиясендә язучы Мәгъсүм На... 70 яшь тулу уңае белән аның турындагы хезмәтләрнең ... үзенең әсәрләренең исемлеге тупланган библиографик беле... ...лып чыкты. Бу китап Татарстан Язучылар берлеге, Кукмара ...хакимияте һәм «Сельхозхимия» катнашы белән дөнья күрде.

«Вечерняя Казань» һәм «шефлар»

...да» газетасының сәяси кү... белән әңгәмә вакытында ...Думасы депутаты, РФ ком...р партиясе башкарма коми...тасы Анатолий Лукьянов ...мал комплексы «генерал...... мәнфәгатьләрен чагыл...бер документны искә алып ...ге документта Шафраник, ...«Газпром», «RAO EAS», ...» һәм башка промышлен...антлары җитәкчеләренең ...тора. А.Лукьяновның әй...ганда, ягулык-энергетика ... «генераллары» һәрбер ...ры берләшмәсенә беркетел...ториаль-сайлау округла... шулай ук кайбер газетала...шефка» алганнар икән. Та...ан әлеге «хөрмәткә» «Вече...ань» лаек булган. Шулай ...е газета сайлау алды кам... вакытында «генераллар» ...узлырачак.

Түбән Кама чемпион бүләк итте

Шушы елның июль башында Американың Буффало шәһәрендә ветераннар арасында җиңел атлетика буенча XI дөнья чемпионаты булып узган иде. Анда республикабыздан бердәнбер вәкил булып түбәнкамалы, Россия Федерациясе һәм Татарстан чемпионы Алексей Гаврилов та катнашты һәм 10 чакрымга «кантри» кроссы буенча бронза медальгә лаек булды. Чемпион Америкага «Татэнерго» берләшмәсе һәм үзе эшләгән Түбән Каманың 1 нче ТЭЦы матди ярдәме белән бара алды һәм аларның ышанычын әнә шулай аклады.

Балаларның дини лагере

Шушы көннәрдә генә Литваның Алитус районы Райшяй авылында балаларның дини лагере үзенең эшен тәгәлләде. Биредә җөмһүриятнең төрле төбәкләреннән килгән 73 малай һәм кыз ислам нигезләрен генә түгел, ә гомумтатар, шулай ук Литва татарларының тарихын, мәдәниятен өйрәнделәр, спортның милли төрләре белән шөгыльләнделәр.

Моннан тыш балалар Вильнюс, Каунус, Тракай шәһәрләре музейларында һәм әлеге калаларның Литва татарларына кагылышлы урыннарында булдылар.

Бу лагерь Бөтендөнья Ислам яшьләре ассамблеясы тырышлыгы белән быел гына оештырылды. Ә Райшяй — борын-борыннан килгән Литва татарлары авылы. Әле моннан ике ел гына элек авылның иске мәчетен төзекләндереп, үз ишекләрен дин тотучыларга ачкан иде.

Архив кына димә...

Пензада Идел буе республикалары һәм өлкәләре архивчылары фәнни-методик советының 25 нче юбилей утырышы булды. Анда бу берләшмәнең даими әгъзасы булган безнең республика архивчылары архив тармагы үсешенең сигез мәсьәләсе буенча чыгыш ясадылар һәм тәҗрибә уртаклаштылар. Аларның архив эшләрен башкару һәм Татарстан Республикасы тарихчы-архивчылар җәмгыятенең роле турындагы чыгышлары, Җиңүнең 50 еллыгын әзерләүдәге һәм аны үткәрүдәге эшчәнлеге, дәүләт карамагында булмаган оешмаларда барлыкка килә торган документларны сайлау, хосусыйлаштырыла торган һәм үзгәртеп корыла торган предприятиеләр һәм оешмаларда эшләүчеләр составының документлары саклануын тәэмин итү, документларны диләнешләрдә дәүләт саклавына тапшыру буенча тәҗрибәләре турында сөйләүләре аеруча кызыксыну уятты.

Совет әгъзалары Татарстан Республикасы архивчылары тарафыннан чыгарылган «Гасырлар авазы» дигән тарихи-документаль журналның беренче санына югары бәя бирделәр.

Зона советының чираттагы утырышы 1996, 1997 елларда Элиста һәм Казан шәһәрләрендә узачак.

Җомгадан — җомгага

Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән 30 августта җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеге турындагы Декларацияне кабул итүгә биш ел тулуга багышланган олуг бәйрәмгә хәзерлек алып бару һәм аны үткәрү бурычы Премьер-министр урынбасары Илгиз Хәйруллинга йөкләнде.

20-30 августка кадәр Казанның колхоз базарларында Республика көненә багышланган ярминкәләр уздырыла.

Мәскәүдә Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм Россиянең «Газпром» акционерлык җәмгыяте арасында җөмһүриятебез шәһәрләренә һәм авылларына газ кертүне тәгәлләү турында килешүгә кул куелды.

Татарстан хөкүмәте сентябрь ахырында «Татнефть» акционерлык җәмгыяте устав фондының 10 процентын Нью-Йорк фонд биржасына сатуга куярга карар итте.

Польшада Балтыйк буе төбәгендә яшәүче татарларның беренче халыкара конференциясе булып узды.

Татарстанда мәгариф һәм мәдәни агарту өлкәсендә эшләүчеләр өчен Каюм Насыйри исемендәге еллык ике премия булдырылды; беренчесе — егерме минималь хезмәт хакы күләмендәгесе укытучылар коллективларына, икенчесе — ун минималь хезмәт хакы күләмендәгесе аерым кешеләргә бирелечәк.

Казан шәһәр хакимияте башлыгы аерым авыру кешеләргә даруны бушлай яисә ярты бәясен генә түләү рәвешендә бирергә дигән карар кабул итте.

Казанда «ВИКО» күргәзмә-мәгълүмат предприятиесендә «Очрашу урыны — Казан» дип аталган күргәзмә-ярминкә ачылды.

Мәскәүдә чыга торган «Век» газетасы Татарстанда эшсезлек дәрәҗәсе Рәсәйдәгедән 2 тапкырга кимрәк, дип язып чыкты.

Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиев Кремльдә Швейцариянең «И.А.С.Интернейшнел» фирмасы президенты Хефелен Вальтер әфәнде белән очрашты.

«Татар-Информ» мәгълүматлары һәм башка чыганаклар файдаланылды.

Татарстан делегациясе Казакъстанда

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе 8—11 августта Казакъстан Президенты Нурсолтан Назарбаев чакыруы буенча Казакъстан Республикасында булды. Алар анда Көнчыгышның күренекле акыны, мәшһүр шагыйрь — фикер иясе Абай Кунанбаевның 150 еллык юбилеен бәйрәм итүдә катнаштылар.

ЮНЕСКО чикләрендә Алматы, Семипалатинск шәһәрләрендә һәм Абайның туган ягы Җидебайда үткәрелгән юбилей тантаналарында 27 илнең, шул исәптән Россия, Франция, Англия, Кытай, Мисыр, Төркия, Пакистан, Һиндстанның һәм күп кенә халыкара оешмаларның рәсми делегацияләре катнашты. Бәйрәм чаралары, кунакларның фикеренчә, бер үк вакытта Казакъстан белән халыкара масштабта үзенчәлекле таныштыру да булды.

9 августта Алматы шәһәрендәге тантаналы җыелышта Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев нотык тотты. Җыелышта катнашучылар аны җылы каршыладылар. М.Шәймиев казакъ һәм татар халыклары, аларның әдәбиятлары, күренекле шагыйрьләре Абай һәм Тукай арасындагы рухи туганлык һәм якынлыкка аеруча басым ясап сөйләде. Президент татар халкы исеменнән казакъ халкына Бакый Урманченың «Абай тирмәдә» дигән картинасын бүләк итте.

Казакъстан җирендә булу Татарстан делегациясе өчен киеренке дипломатик эш көннәренә әверелде. Татарстан Республикасы делегациясе рәсми төстә кабул ителде, президентлар Н.Назарбаев һәм М.Шәймиев очрашып, ике тугандаш республиканың икътисади һәм мәдәни хезмәттәшлеген киңәйтү зарурлыгын һәм аңа әзер булуларын расладылар. Шушы очрашу вакытында Алматыда Татарстан вәкиллеген ачу турындагы килешүгә ирешү дә моңа уңай йогынты ясар.

Президент М.Шәймиев ЮНЕСКО Генераль директоры Федерико Майор әфәнде белән әңгәмә корды. Ул аңа Татарстан Республикасындагы хәл, сәяси һәм икътисади реформаларның барышы, мәдәният һәм сәнгатьне үстерүгә булышлык итү чаралары турында сөйләде. Ф.Майор әфәнде, безнең республика белән даими кызыксынып торуын әйтеп, соңгы елларда Татарстанның халыкара мәйданда абруе күтәрелүне билгеләп үтте.

М.Шәймиев Әзәрбәйҗан Президенты Гейдар Алиев, Кыргызстан Президенты Әскәр Акаев, Үзбәкстан Премьер-министры Абдулһашим Муталов, Грузия һәм Төркмәнстан парламентлары спикерлары Вахтан Гагуадзе һәм Сахат Мурадов белән очрашты. Бу очрашулар вакытында дәүләтара икътисади, сәүдә, фәнни, мәдәни бәйләнешләр урнаштыру һәм аларны тирәнәйтү проблемалары тикшерелде. Президентлар Г.Алиев һәм Ә.Акаев М.Шәймиевне үз республикаларына рәсми визит белән килергә чакырдылар. Чакыру рәхмәт хисе белән кабул ителде. Алматыда һәм Семипалатинскида М.Шәймиев һәм Татарстан делегациясе әгъзалары — «КамАЗ» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Н.Бех, республика халык депутаты, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р.Мөхәммәдиев, Татарстандагы Казакъ җәмгыяте рәисе С.Җаксыбаев, Казакъстанда Татар мәдәни үзәге рәисе М.Кәримов Абай мавзолеена һәм һәйкәленә чәчәкләр куйдылар. Делегация Семипалатинскида Абай музее комплексын, әдипнең туган ягы Җидебайда музей-мемориал ачу тантанасында, Абай районы үзәге Караултүбәдә акыннар фестивалендә катнашты.

Казакъ җирендә шулай ук татар диаспорасы вәкилләре һәм татар-башкорт мәдәни үзәге әгъзалары белән дә очрашулар булды.

11 августта Татарстан делегациясе Казанга әйләнеп кайтты.

Татарстан һәм Казакъстан җөмһүриятләре Президентл... миев һәм Н.Назарбаев.

казакъ галимнәре чыгыш ясады.

Абай Кунанбаевның шушы күркәм юбилеен бәйрәм итү казакъ җиренең бөек улына безнең уртак хөрмәтебезне белдерү белән бергә, аның мирасы нигезендә кайбер мөһим фәнни мәсьәләләрне кузгату һәм фикер алышу өчен дә кулай форсат булып тора. Әйтик, татар галимнәрен Абай шәхесе һәм кылган гамәлләре беренче чиратта татар-казакъ бәйләнешләренең һәм хезмәттәшлегенең күп гасырлык тарихын объективрак өйрәнү һәм бәяләү ягыннан кызыксындыра. Чөнки бу олы зат тугандаш халыкларыбыз хезмәттәшлегенең үткәнен һәм киләчәген бәйләп торучы вазифасын башкарган. Дөрестән дә, А.Кунанбаев тамырлары белән Алтын Урда заманнарына китә то-

гач, татарның күп кен... интеллектуаль көчләр... рен саклап калыр өчен... ләреннән качарга мә... Аларның шактые үзләр... ватанын казакъ жир... Моннан соң да үз ил... хәл калмаганда яки ур... һәм совет властьлары... веннән котылырга тел... ялылары еш кына Урт... Казакъстан якларына... булган, анда иҗади як... тчелек эшчәнлекләрен... һәм моның белән туга... ларның мәдәнияте һә... үсешенә үз өлешләрен...

Бу тарихны яхшы... үзе татарлар белән як... шкан Абай безнең хал... үз фикерен тудырган... рым алганда, програм...

Казакъстанда Абай Кунанбаевның 150 еллыгына багышланган юбилей тантаналары көннәрендә Алматы шәһәрендә әлеге вакыйгага багышланган халыкара фәнни корылтай — Казакъстан Фәннәр академиясенең юбилей сессиясе булды. Казакъстан парламентының утырышлар залында республика хөкүмәте химаясендә үткәрелгән бу сессия эшендә 20 дән артык илдән күренекле галимнәр һәм әдипләр катнашты. Анда Татарстаннан академик Флүн Мусин чыгыш ясады. Түбәндә шул чыгышны кайбер кыскартулар белән тәкъдим итәбез.

Флүн МУСИН, академик

«Андый халы...

Бу данлыклы юбилей көннәрендә без — татарларны бөек Абай исеменә һәм мирасына туган халкыбызның да турыдан-туры мөнәсәбәте булуы, әлеге олы шәхеснең уртак горурлыгыбызга әверелүе аеруча куандыра. Абайның әтисе тарафыннан бирелгән баштагы атын — Ибраһимны хәзергә исеме билгесез татар мулласы кушкан. Башлангыч белемне ул Конанбай үз балаларын укытыр өчен махсус чакырган татар мөгаллиме Габитхан Габденазар улыннан (1835-1932) алган. Аннары Абай укуын Семипалатинск шәһәрендәге танылган уку йортында — татар мәгърифәтчесе Әхмәт Риза мәдрәсәсендә дәвам итә. Биредә уку шактый дәрәҗәдә Кунанбаевның бөтен киләчәк язмышын һәм тормыш юлын билгеләде. Чөнки әлеге мәдрәсәдә яшь Абай башлап татар һәм гомумән дөнья мәдәнияте белән таныша. Шунда ук аның шагыйрьлек сәләте бөреләнә башлый. Шулай балачактан ук татарлар белән якыннан аралашкан һәм дуслашкан Абай үзенең бу бәйләнешләрен гомеренең ахырына кадәр саклый. Дөньяга карашлары һәм яшәү максатлары буенча аңа татар мәгърифәтчеләре аеруча якын була.

Икенче яктан, Абай үзе исән чакта ук татар дөньясында мәгълүм шәхескә әверелә. Инкыйлабка кадәр үк аның иҗаты күренекле татар әдипләре тарафыннан таныла һәм югары бәя ала. Мәсәлән, 1916 елда Г.Ибраһимов Абайны «бөтен казакъ сахрасына әдәби азык булып килгән... киң далада авазы яңгыраган» шагыйрь дип белдерә. Ә инде шигъриятне аеруча нечкә сиземләгән Ш.Бабич: «Мин Кунанбайның өләнендә фәсәхәт, матурлык вә ләззәт табып, аны татарның Тукае, гарәпнең Имрелкайсе дәрәҗәсенә менгердем», — дип яза. Шунлыктан Абай әсәрләре татар телендә күп тапкырлар дөнья күрә. М.Әуэзовның атаклы «Абай юлы» эпопеясы да татар укучысына җиткерелде. Безнең җөмһүриятгә дә бөек шагыйрьнең 150 еллыгы киң билгеләп үтелде. Бу вакыйга матбугат битләрендә, радио һәм телевидение аша яктыртылды, Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан фәнни конференция үткәрелеп, анда күренекле татар һәм казакъ галимнәре чыгыш ясады.

...рган әлеге хезмәттәшлекнең бай традицияләрен кабул итеп алган һәм дәвам иткән. Әмма озак вакытлар без бу тарихны, бигрәк тә Алтын Урда чорын тиешенчә өйрәнә алмадык. Хәлбуки, Алтын Урда төрки халыкларның сәяси, икътисади һәм рухи яктан бер-берсенә якынаюында, бердәм төрки дөньясын, аның мәдәниятен тудыруда хәлиткеч роль уйнады. Шуның белән бергә, хәзер Алтын Урданың урыс дәүләтчелеге, хәрби сәнгате, икътисады, теле, мәдәнияте һ.б. үсешендә уйнаган уңай ролен өйрәнергә һәм тиешенчә бәяләргә дә вакыт җитте кебек. Бу өлкәләрдә мөһим башлангычларның берсе итеп без 1993 елның август аенда Казанда Татарстан Фәннәр академиясе тарафыннан Алтын Урданың 750 еллыгына багышлап үткәрелгән халыкара фәнни конференцияне саныйбыз.

Инде әйтелгәнчә, Алтын Урда заманы, аерым алганда, татар һәм казакъ халыкларының икътисади һәм рухи-мәдәни өлкәләрдә үзара якынаюына булыша. Шул вакытта хасил булган туганлык мөнәсәбәтләре алга таба безнең халыкларның бер-берсенә булышлыгы һәм хезмәттәшлеге өчен ныклы җирлеккә әверелә. Әйтик, 1552 елда Явыз Иван Казан ханлыгын басып ал-

дагы атаклы «Гаклия»... лдырган. Бу фәлсәфи-ә... лы әсәрендә казакъ ха... кәне, бүгенгесе һәм ки... нда уйланганда Абай... ләләргә үзенең төп эт... — «Адәм бул!»дан... Әлеге принцип ниге... «тулык адәм», ягъни... һәм әхлакый яктан к... идеалы ята. Бу идеал... закъ дөньясындагы ка... рны да ачыграк күре... һәм аны үз халкыны... кый сәламәтлеге тур... тырга чакыра. Кайбе... ирәләрендәге милли... күренешләрен мәдәни... мисаллары дип бәялә... ган халкының чын ул... ләтпәрвәре буларак,... ләттәшләрең башка... үрнәк алырга һәм ө... дәгән. Шушы максатт... клия»сендә ул вакыт... халыкларының, күрә... руча якыннарына бик... ма төпле бәяләмә би... татарлар турында ул... «Мулла, мәдрәсәләре... дайга зарланмый г... Хезмәт куеп мал таб... белә, зат-зиннәт тә... ләрендә... Андый ха... булмас, чөнки һаман... тереп, төрлечә мал та... сенә булышып көн ку...

байның биредә татарларның хезмәт ярату, хезмәтчел булу кебек сыйына басым ясавы һич тә очхәл түгел. Чөнки үзенең төп идеалына — кешеләрнең булуларына» ирешүдә иң чараларның берсе итеп ул не сайлый. Беренче чиратта аша, хезмәт тәрбиясе бирү елән генә халыкны һәм аешахесне дөрес тәрбияләргә, иң рухи-әхлакый сәламәт амил булуларына ирешергә н дигән карашта тора ул. чын адәм булыр өчен кеше генә эшләргә, тырышырга түгел. Ходай бәндәсе булыр кеше башкаларга да хезмәт бурычлы. Шундый кешеләй казакъ җирендә яшәп, бу хезмәт күрсәткән татарзында да тапкан, күрәсең. казакъ фикер иясенең татакүрсәткән хөрмәтенә җавап лай, безнең Галимҗан Ибов казакъ халкына багышенең «Казакъ кызы» дигән м романын яза. Анда 1917 ларге казакъ дөньясының орамасын бирен, ул бигрәк мәт кешеләренең күркәм тларын — аларның рухи маын, яшәү көчен һәм оптиы ачуга басым ясый. Әсәр каһарманы Карлыгач-Сызында казакъ кызының эчтышкы матурлыгын, үз бәчен көрәштә кыюлык һәм ык күрсәтүен чагылдыра. кы. Г.Ибраһимов Карлыуны татар хатын-кызлаүрнәк итеп куя кебек. Чөнәсәр язылган вакытта татар кызларына да үзләренең кехокуклары өчен көрәштә й сыйфатлар бик тә кирәк

йның мирасы тагын менә лән әһәмиятле: казакъ то мисалында ул кин милләятларыбызның, гомумән, мәдәниятләребезнең берләшүенә этәргеч ясады. Шунлыктан әлеге әдипләрнең һәркайсы үз иҗаты белән безнең әдәбиятлар өчен теге яки бу дәрәҗәдә уртак булган мәсьәләләрне яктыртырга мөмкинлек бирә. Әйтик, Абай мирасы, аның башка әдәбиятлардагы фикердәшләренеке кебек үк, хәзер мәгърифәтчелек әдәбиятының идея-эстетик асылын һәм әһәмиятен үткәнрәк еллардагыдан башкачарак аңлатырга һәм бәяләргә булыша. Совет заманында бездәге мәгълүм идеология таләпләренә артыграк иярү аркасында, әлеге әдәбиятның идея-эстетик мәгънәсе һәм кыйммәте тиешенчә бәяләнмәде яки шактый берьяклы һәм гадиләштереп аңлатылды. Башлыча сыйнфыйлык принцибы белән эш итү сәбәпле, мәгърифәтчеләрнең милли әдәбият өчен аеруча мөһим мәсьәләләрне яктыртырга алынулары гадәттә милләтчелек күренеше дип бәяләнде, ә инде аларның милләтне бер-берсенә дошман булган антагонистик сыйныфларга бүлмичә бербөтен итеп караулары һәм кайгыртулары буржуаз «бердәм агым» теориясенә бирелү дип кире кагылды. Хәзер исә мәгърифәтчеләрнең милли әдип вазифаларын совет заманы белән чагыштырганда күп мәртәбә тулырак һәм нәтиҗәлерәк башкарганнарын күрәбез. Гомумән, мәгърифәтчелек әдәбиятның элеккерәк елларда җитешсезлек булып исәпләнгән кайбер сыйфатлары хәзер аның абруена әверелә. Чыннан да, әгәр мәгърифәтчеләрнен милли хәятнең сыйфаты турында кайгыртулары үткәндә еш кына милләтчелек рәвешендә каралып кимчелеккә кайтарып калдырылса, хәзер исә бу омтылыш бүген дә үрнәк булырлык сыйфат дип бәяләнергә лаеклы. Чөнки совет чорында интернационализм, сыйнфый көрәш, яңа гадел җәмгыять төзү һ.б. кебек бирә. Мәгълүм ки, 70 елдан артык бу мәсьәлә бездә сугышчан атеистик пропаганда рухында, ягъни тенденциоз төстә өйрәнелде һәм бәяләнде. Яңа заман әдәбиятларыбызның иң күренекле вәкилләрен без еш кына тумыштан ук атеистлар итеп күрсәтергә тырыштык. Аларның изге рухани дәрәҗәгә тап төшергән аерым муллаларны яки ишаннарны тәнкыйть утына

Алматы шәһәрендә татар-башкорт җәмгыяте әгъзалары белән очрашу вакыты. Казакъстан Фәннәр академиясенең гыйльми хезмәткәре Сәлимә Акашева, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев һәм академик Флүн Мусин.

алулары исә мәгънәви яктан артык киңәйтеп, гомумән, динне, бу очракта исламны фаш итү дип бәяләнде. Хәлбуки, безнең атаклы мәгърифәтчеләребез асылда дингә ихлас ышанган затлар була һәм бу халәт аларның иҗтимагый-фәлсәфи карашларына да тирән эз сала. Шул ук Абай да үзенең идеалларын беренче чиратта иман белән

леге һ.б. турында сүз алып барылды, ә менә конкрет әдәбиятларның милли хәле һәм язмышына бөтенләй диярлек игътибар ителмәде. Һәм менә хәзер, ниһаять, аерым әдәбиятларның үткәнен һәм бүгенгесен милли сәнгать буларак өйрәнү башлана. Шактый катлаулы бу эштә Абай кебек классиклар мирасы үзенә бер фәнни тикшеренү коралы һәм бәя бирү чарасы була ала.

Классиклар мирасы тарихи яшәеш хасил иткән әдәби берләшмәләрне өйрәнү кирәклеген искәртә. Мәсәлән, хәзер без пантюркизмда гаепләнүдән курыкмыйча Алтын Урда заманыннан башланган һәм үзенең эстетик кыйммәтләр системасын булдырган төрки әдәбиятлар берләшмәсе турында җитди фәнни сөйләшү алып бара алабыз. Әйтергә кирәк, бу әдәбиятлар бердәмлеге совет әдәбиятлары берлегеннән нык аерыла, чөнки төрки әдәбиятлар бердәмлеге тугандаш халыкларыбызның күп гасырлык тарихы, аларның тарихи язмышлары уртаклыгы, иҗтимагый-рухи омтылышларының һәм идеалларының якынлыгы белән тудырылган һәм ныгытылган.

...ич хур булмас...»

...ыраш ала алырлык мәсьә...үтәрә, чөнки алар башка, ...тә тугандаш төрки халык...и дә якын һәм әһәмиятле. ...н Абай безнең яңа заман ...әдәбиятларыбызның Ахун...акый, Мәхтүмкули, Муки...р, Тукай кебек иң күрене...ләре белән бер сафта то...яктан, чын милли булган, ...яктан, киң милләтара яң...ы бу әдипләр, гомумән ал...төрки дөньядагы үзәккә ом...көчләрне үзләрендә тупла...үстерде һәм шуның белән ...дөньяның эчке бердәмлеген ...лелеген ныгытуга булыш...ның шундый көчкә ия бу...ты бер үк вакытта әдәбиидеяләр белән мавыгып китеп, язучылар туган халыкларының милләт буларак асылда нинди хәлдә калуларына бөтенләй диярлек игътибар итмәде. Киресенчә, күп кенә халыклар ассимиляциягә дучар ителгән һәм милли йөзләрен югалта барган бер вакытта әдипләр зур куаныч белән аларның, имеш, революция һәм социализм биргән яңа бәхетле язмышына дан җырлады.

Абай һәм аның фикердәшләре мирасын тулырак һәм объективрак өйрәнү ислам белән революциягә кадәрге төрки әдәбиятлар арасындагы мөнәсәбәтләр кебек бик мөһим мәсьәләне яңачарак яктыртырга һәм бәяләргә дә мөмкинлек



Семипалатинский өлкәсенең Җидебай аймагында Абай һәм Шәкәрим мавзолейлары мемориалы.

бәйли. Мәсәлән, ул үзенең иң мөһим этик идеалын — рухи һәм әхлакый камил кеше тәрбияләүне иң әүвәл Аллаһы тәгалә исеме белән изгеләштерә.

Абай һәм аның фикердәшләренең мирасы, чын милли һәм гомумкешелек кыйммәтенә ия булуы белән, хәзер әдәбият фәне һәм иҗтимагый фәннәр өлкәсендә башланган җитди үзгәрешләрдә турыдан-туры катнашырга тиеш. Соңгы елларда, әйтик, артык идеологияләштерелгән совет эстетикасының мәгълүм таләпләреннән һәм күрсәтмәләреннән арына башлау әдәбиятларыбыз тарихын һәм теориясен өйрәнүнең яңа принципларын һәм юлларын булдыру кирәклеген искәртә. Бер яктан, без аерым әдәбиятларны дөнья сәнгатенең милли суверен һәм үзенчәлекле күренешләре итеп өйрәнү кирәклегенә торган саен ныграк инанабыз. Хәлбуки, совет властеның беренче елларыннан ук бездә үтә дә төрле тәҗрибә һәм традицияләргә ия һәм үз алларына һич тә тәңгәл килә алмаган бурычлар куйган төрле-төрле әдәбиятлардан уртак идеологиягә хезмәт итүче бербөтен совет әдәбиятын булдыру бурычы куелды. Үзен һич тә акламаган бу ясалма бурычны мәҗбүри төстә тормышка ашырырга алыну ахыр чиктә күп кенә әдәбиятларның милли йөзләрен югалта баруларына китерде. Шунлыктан совет чорында күбрәк совет әдәбиятының бердәмлеге, интернациональ-

Бүгенге сессиянең халыкара фәнни форум статусына ия булуын, ягъни вәкаләтләренең зур булуын күздә тотып, мин аның карарларына җөмһүриятләребезнең яки дәүләтләребезнең рәсми органнарына һәм фәнни-мәгариф оешмаларына төрки әдәбиятлар тарихын мөстәкыйль фәнни дисциплина итеп өйрәнә башлауны һәм югары уку йортлары белән урта мәктәпләрдә әлеге әдәби тарихны укыту тәкъдимен кертүне сорар идем. Бу өлкәдә безгә үрнәк тә бар инде. Әйтик, соңгы вакытта урыс әдәбият фәнендә славян әдәбиятлары тарихын бербөтен итеп өйрәнүгә игътибар бермә-бер артты, Русиянең уку йортларында исә әлеге тарихны укыту буенча практик чаралар күрелә.

Төрки әдәбиятлар тарихын да шул рәвешле өйрәнә һәм укыта башлау бер үк вакытта безнең Абай васыятьләренә турылыклы булуыбызны да раслар иде. Төрки дөньяның иң мәшһүр затларыннан булган Абай тугандаш халыкларыбызның төрле-төрле өлкәләрдә, шул исәптән мәдәният өлкәсендә дә дуслыгы һәм хезмәттәшлеге турында кайгырткан, бу изге бурычны тормышка ашыруга хезмәт иткән, аны киләчәк буыннарга да васыять итеп калдырган.

Гурий ТАВЛИН

Саескан һәм сумала

Памфлет

Сумалаланган түбәгә кунып, бәлагә тарыган, төгәлрәк әйткәндә, сумаладан томшыгын ычкындырса, койрыгы ябышып, койрыгын ычкындырса, томшыгы ябышып җәфаланучы саескан турында өзлексез сөйләп була торган бер әкият бар. Рәсәй Чечняга басып кереп, нәкъ менә сумалалы түбәгә кунган саескан хәлендә калды. Мондый нәрсәгә ул инде Әфганда юлыккан иде югыйсә, тик аннан тиешле сабак кына алмаган булып чыкты. Хәзер Рәсәй бүрәнә ярыгына кулын кыстырган мескен Шүрәле хәленә төште: үрле-кырлы сикерә, тирсәген бик тешләргә итә, әмма...

Чечен каһарманы Шамил Басаев Ставрополь краендагы Буденновск шәһәренә һич көтмәгәндә үтеп кереп, башлары белән түгел, йомшак җирләре белән генә уйларга сәләтле кайбер урыс түрәләрен тетрәтеп алгач, Мәскәүләр үзсүзле «Чечня бандитлары» белән тизрәк килешү төзергә, сугышны туктату турында сөйләшүләр алып барырга ризалаштылар... һәм сөйләштеләр дә. Әмма ул сөйләшүләрнең гамәли нәтиҗәләре суга сәнәк белән язган кебек кенә әле. Чечняда төннәрен атышлар, үтерешләр, кан коюлар һаман дәвам итә. Хәйран калырлык хәлләр: федераль гаскәрләрнең чечен кампаниясендә 1867 кешесе һәлак булган, 6481 е яраланган, 252 се хәбәрсез югалган, 36 кеше чечен боевикларына әсир төшкән. Ә менә Чечен хөкүмәте башлыгы Саламбек Хаджиев чит ил хәбәрчесенә биргән бер интервьюсында Чечняда хәрби булмаган 6 мең кешенең, 3 меңнән артык боевикның, 4 меңнән артык Рәсәй солдаты һәм офицерларының һәлак ителүен әйтте.

Грозныйда барган сөйләшүләрдә Рәсәй делегациясе әгъзасы Аркадий Вольскийның сүзләренә караганда, чечен икътисадын аякка бастырырга 5,8 триллион сум акча бүлеп бирелгән, шуның 1,7 триллион сумы үзләштерелгән инде. Акыллары тулмас җитәкчеләрнең һич кирәксезгә коралга тотынулары аркасында болай да тишек кесәдән бушка туздырылган акча бит бу.

Шунысы да мәгълүм: Чечнядан 400 меңгә якын кеше китәргә мәҗбүр булган, әлегә шуларның тик 66 меңе генә кире әйләнеп кайткан. Грозныйдагы хәзерге хакимият вәкилләренә торак белән тәэмин итүне сорап 12 мең гаилә мөрәҗәгать иткән.

Болары да — Рәсәй башлыкларының кычытмаган җирләрен кашып, корал белән уйнаулары нәтиҗәсе, халыкны санга сукмаулары. Әгәр килешү көткәнне бирмәсә, алда тагын ниләр буласын әйтүе кыен, чөнки түбәгә кунган саескан әле һаман сумаладан ычкынмаган.

Инде белгәнебезчә, 30 июльдә чечен конфликтын җайга салу җәһәтеннән хәрби мәсьәләләрне хәл итү буенча килешүгә кул куелды. Моны бик күпләр зур түземсезлек белән көттеләр. Сөйләшүләр берничә тапкыр чак кына өзелмичә калды. Ниһаять, рәсәйлеләр өчен дә, чеченнәр өчен дә бик мөһим нәрсәгә — сугыш хәрәкәтләрен туктатырга килешенелде. Әлеге документ инде көченә керде. Рәсәй белән Чечня арасындагы сугышның тукталуы турында килешү инде буш, коры сүзләр генә булып калмады, юридик кануннарга нигезләп рәсмиләштерелде. Аның төп пунктлары — бөтен Чечняда сугыш хәрәкәтләрен туктату, федераль гаскәрләрне Чечнядан өлешләп-өлешләп чыгару, чечен хәрби частьләрен коралсызландыру, әсирләр алмашу. Рәсәй белән Чечня низагы киләчәктә хәрби көчләр кулланып хәл ителмәячәкләр. Чечняның булачак дәүләт төзелеше, статусын хәл итү әлегә кичектереп торыла. Табигый ки, аны бер яктан туплардан атып, икенче яктан гранаталар чөеп торганда тормышка ашырып булмый. Хәзергә әле кайсы якның — рәсәйнекеләрнеңме, чеченнәрнекеме җиңүләре турында әйтерлек түгел, ике арада бау тартышу һаман дәвам итә. Чечня Рәсәй составында калырмы, бәйсезлек алырмы, билгесез.

Хәзергә алда ике юл төсмерләнә. Рәсәй гаскәрләрен билгеләнгән срокларда тәртип белән чыгару һәм чеченнәрнең кулларындагы автоматларны кабул итү пунктларына һәркайсын 150 меңнән 300 меңгә кадәр сумга тапшырту юллары. Шунысы шикләндерә: Рәсәй гаскәрләре Чечнядан чыкканда, дудаевчылар белән барган сугышларда үлеп калган иптәшләре өчен үч алмыйча тыныч кына китәрләр, дип бүген кем әйтә ала? Сугышудан туймаучы Рәсәй алда да тыныч кына яши алмаячак. Чечняда калачак ике бригаданың үз тәртипләрен урнаштыруны дәвам итүләре һәм сүнеп барган сугыш күмерен кабат дөрләтеп җибәрүләре бик ихтимал. Җирле халык Рәсәй гаскәрләрен юлларына чәчәкләр түшәп түгел, бәддога укып озатыр. Анда рәсәйлеләр күпме гариплләр, күпме ятимнәр, күпме толлар, күпме кара хәсрәт, дистәләрчә еллар кипмәслек күз яшьләре калдыралар бит.

Азатлык сөючә каһәрләнгән горур чеченнәр бәйсезлек өчен көрәштә нинди генә кыенлыклар күрсәләр дә баш тартмаслар, иртәме, соңмы — барыбер үз дигәннәренә ирешерләр. Әмма Чечняга тынычлыкның тиз генә килеренә һич тә ышанып булмый әле. Чечня Рәсәй өчен сумалаланган түбә. Урыс саескаы түбәгә нык ябышты...

Сафа САБИРОВКА 80 я



башларга чират җитте.
Ләкин бу вакытта ил күгендә дәһ
прессия болытлары куера, рәхимсез
ләү кампаниясе башланган иде. Ха
берләнгән бик күпләр белән бергә то
җитәкчесе, Татарстан Үзәк Башкар
теты әгъзасы (хәзергечә әйтсәк, Дәү
ты депутаты) Шәрәфетдинов һәм
архитектор С.Пэн көтмәгәндә юкка
эшкә килмиләр. Ни булганын, кая к
луларын беркем белмәгән. Бернич
соң гына алар турында халык дошм
жуаз милләтче булганнар, корткыч
ганнар икән, дигән имеш-мимеш хәб
рала, аларны гаепләп фаш итүгә баг
шау-шулы җыелышлар үткәрелә.
Шулай да тормыш дәвам итә. Зур
лар белән булса да, 1935 елның җә
леш нигездә тәмамланып, Матбу
файдалануга тапшырыла. Соңгы ун
саж бинасының аскы катындагы ярым
бүлмәләрдә үткәргән китап нәшрият
нага күчә, хәзерге Париж Коммунасы

Татар китабының төп йорты

Казан каласының үзәгендә — Бауман урамында урнашкан, үзенчә бик тә күркәм архитектуралы биш катлы мәһабәт бина бар. Ул — Матбугат йорты. Аны 1935 елның җәендә төзеп бетерделәр. Бинаны җиһазлап файдалануга тапшыру республика тормышында бик тә сөенечле, шатлыклы вакыйга буларак, зурлап, тантаналы төстә билгеләп үтелде.

Мондый йортны төзү, китап нәшрияты һәм газета-журналлар өчен куәтле база булдыру кирәклеге инде күптәннән, егерменче еллар уртасында ук кузгатылган, әмма, төрле сәбәпләр белән елдан-елга кичектерелә килгән иде. Татарстан китап нәшрияты җитәкчесе, кайнар йөрәкле публицист Самат Шәрәфетдинов бу мәсьәләне Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты утырышларында һәм матбугат битләрендә кабат-кабат күтәреп чыкканнан соң гына, мәсьәлә уңай якка чишелде, анда да хуҗалык ысулы белән, ягъни бинаны нәшриятның үз исәбенә төзи башларга рөхсәт ителде.

Самат Җәләлетдин улы Шәрәфетдинов, үзенең төп вазифасы белән берәттән, бу тынгысыз эшкә шундук җиң сызганып керешә. Мондый зур төзелешкә керешер өчен иң әүвәл аның кулай проектын булдырырга кирәк бит. Бу эшне талантлы архитектор С.Пэн башкара. Җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәяләнеп, рәсми рәвештә расланганнан соң, аның проекты буенча Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамында ярым җимерек иске йорт, шыксыз киоскалар урынында төзелешне башлап җибәрергә мөмкинлек туа. Биш катлы мәһабәт бинаның төп корпусы урамга яны белән торачак. Арткы якның сул канатында типография цехлары, ашханә, складлар төзеләчәк. Аларга каршы якта матбагачылар өчен биш катлы торак йорт салу күздә тотыла.

Ул елларда төзелешләрдә күп эшләр кул көче белән башкарыла иде. Шуңа карамастан, эш дәррәү башланып китә һәм кызу темплар белән бара. Төп эшчеләргә ярдәм йөзеннән үткәрелгән өмәләрдә каләм әһелләре, студентлар актив катнаша. Төрле тарафлардан вагоннарда, баржаларда килгән төзелеш материалларын ашыгыч рәвештә бушатырга кирәк булганда, безне дә Луначарский исемендәге типография мәктәбендә укучы яшүсмерләрне дә, ара-тирә булышырга чакыралар иде.

Төзелеш җитәкчесе дә, архитектор да һәрвакыт диярлек шунда, эшче халык арасында. Көтмәгәндә берәр тоткарлык килеп чыкса, аны шундук хәл итәргә тырышалар. Һәркайда аларның оештыру осталыгы, оператив җитәкчелеге сизелеп тора. Төзелешнең барышы, алдынгы эшчеләр турында көндәлек матбугатта әледән-әле хәбәрләр басылып чыга.

Бөтен коллективның омтканлык белән эшләве һәм шәһәр җәмәгатьчелегенең зур ярдәм күрсәтүе нәтиҗәсендә 1933 елның көзендә Матбугат йортының төп корпусын төзү тәмамланды, аның цехларына яңа машиналар урнаштырырга, китапханә, склад һәм кабинетларны җиһазлый

дагы Камил Якуб исемендәге китап
сы һәм башка вак типографияләр д
машиналар белән җиһазландырыл
цехларда урнаша. Китап нәшрияты
Язучылар берлеге идарәсе, газета-
дакцияләре, китап сәүдәсе идарәсе
көн күрә башлый. Шулай итеп, бу
бина татар матбугатының төп йорты
лә. Язучылар, журналистлар үзара
җылылык белән «безнең төп йорты
йөртәләр.
Мәдәниятебез үсеше белән аерыл
лган мәшһүр Матбугат йортына 60
бер көннәрдә аны төзүгә аеруча күп
лык куючыларны ихтирам белән иск
аларга ихлас күңелдән рәхмәт әйтәс
Аларның берсе, әйткәнемчә, нәш
рәчесе Самат агай Шәрәфетдинов.
аның хаксызга гаепләнүе, тоткынлы
булуы беленде, шәхес культы фаш и
соң акланды.
Икенчесе — күренекле архитекто
Пэн. Ул да реабилитацияләнде, м
белән бу хакта очрашып сөйләшерг
килде. Хәтерем ялгышмаса, 1959 ел
дә булса кирәк. Китап нәшриятында
чагым иде, директор Г.Камалиев ми
тып алды да:
— Менә безнең Матбугат йорты
текторы иптәш Пэн, — дип каршын
ндыкта утырган олпат гәүдәле, чәлар
өлкән яшьтәге кешегә күрсәтте. У
утырып чыккан, реабилитацияләнг
хатыны белән Идел буйлап сәяхәт
Теплоход Казанда туктап торган ара
иҗат җимешен, кайчандыр эшлә
урыннарны күрергә теләи. Аңа йортн
ярдәм итәргә кирәк.
Башта без редакцияләр урнашкан
рне, клуб һәм китапханәне, цехлар
чыктык. Аннары урам яктан тыш
шен карадык. Телдән әйтмәсә дә, йо
авторда әйбәт тәэсир калдырмавы
азакка таба чырае караңгыланды.
арткы ягындагы килбәтсез мәйдан
кенә:
— Монда матбагачылар торак йо
рга тиеш иде, бездән соң шуны да т
нәр икән, — диде.

Сафа С



Фәнис ЯРУЛЛИН

Горур булыйк

Мескенләнмик әле, горур булыйк,
Горур булуларга ни җитә!
Сокланабыз хәтта бөркеткә дә
Очса гына күктә, биектә.

Син бит, халкым, бөркет нәселеннән,
Һич килешми сиңа мескенлек.
Дошманнарың хөрмәт итсен, дисәң
Горурлыгың итсен өстенлек.

Матур халык бит без, батыр халык,
Күпме изсәләр дә калыктык.
Милләт үлми — горурлыгы барда,
Горурлык ул — безнең таныклык.

Яшереп яткырмыйча йөрәкләрдә
Никадәрле гайрәт, көч барын —
Яшик җирдә бер дә кимсенмичә,
Башны биек тотып, татарым!

8 май, 1995.

* * *

Мин халкымның баласы —
Агачтагы алмасы.
Бар әле, бар, җилдә җилләп,
Кояшларда янасы.

Мин халкымның баласы,
Килми арып каласы —
Халык күңеленә таба
Барасы да барасы.

Мин халкымның баласы,
Килә шуны аңласы —
Әллә күзенең карасы,
Әллә йөрәк ярасы?!

8 май, 1995.

Илдә әле ирләр бар

Биек-биек таулар бар,
Тау башында таллар бар;
Тау өстендә таллар булып
Калкып чыккан җаннар бар.

Биек-биек таулар бар,
Тау башында ташлар бар:
Өсләренә таш яуса да
Иелмәгән башлар бар.

Биек-биек таулар бар,
Тау башында җилләр бар;
Җил-давылда егылмаслык
Илдә әле ирләр бар,
Шөкер, андый ирләр бар.

8 май, 1995.

Бетмәс

Болыннарның яме бетмәс,
Җирдә гөлләр барында.
Гүзәлләрнең кадре бетмәс,
Илдә ирләр барында.

Илдә батыр ирләр бетмәс,
Җирдә көрәш барында.
Җирдә әле көрәш бетмәс,
Күзләрдә яшь барында.

15 май, 1995.

Мактау

Мактау — шәраб,
Бик аз эчсәң
Куя ярап:
Арта көчең,
Балкый йөзең,
Гөрли эшең.

Китсә күпкә,
Менсәң күккә:
Ул исертә
Һәм сикертә,
Һәм тилертә.

13 май, 1995.

* * *

Бу дөньяның бик еш кына җае булмый,
Боткаң булса, салыр өчен мае булмый.
Атың булса, арбаң яки чанаң булмый —
Йөгең тартып китәр өчен чараң булмый.

Яр сөйгәндә — сайлар өчен
акыл булмый,
Акыл кергәч, йөрәгеңдә ялкын булмый.
Эзләнәсең — эзләгәнең алтын булмый,
Акыл белән табылганнар якын булмый.

Отам, отам, отам, дисең —
отып булмый,
Бәхет кошын тотам, дисең —
тотып булмый.
Кайчагында кулга кергән калҗаңны да
Тешләп кенә карыйсың,
ә йотып булмый.

Югалтасың табам, табам, табам, диеп,
Ымсынасың кабам, кабам, кабам. диеп.
Сүреләсең һәм сүнәсең, үз-үзеңне
Алдый-алдый әле һаман янам, диеп.

16 май, 1995.

Аерма

Җирдә генә көчле кеше,
Җирдә генә ул батыр.
Өскәрәк үрелгән саен
Өзелә бара тамыр.

Күпләр, тамырларын йолкып,
Гел-гел өскә калыккан.
Аерылган алар шулай
Җиреннән һәм халыктан.

Авалар андый «биек»ләр
Хәтта көчсез җилләрдән.
Аерма берүк, язмышым,
Тамыр җәйгән җирләрдән.
Терәк булган иңнәрдән.

21 июнь, 1995.

Озак-озак яначак

Кеше бит ул бер учак:
Утынын сала торсаң,
Көлләрен ала торсаң,
Бераз кузгатып куйсаң,
Утын уятып куйсаң,
Давылдан саклый алсаң,
Явымнан каплый алсаң,
Сүнгәндә өргәләсәң,
Яңа көч биргәләсәң,
Күмерен таратмасаң,
Урынын яңартмасаң,
Таш белән бастырмасаң,
Боз белән катырмасаң,

Ялкыннарын үрләтсәң,
Күмерләрен дөрләтсәң —
Бу учак
Озак-озак яначак.

18 июнь, 1995.

Гариф АХУНОВ,
Татарстанның халык язучысы

КУШЛАВЫЧ

Даһи шагыйрьнең 110 еллыгын ул ничек каршылый

Быел Арча поездында кайтканда да зур бер бәхәскә тап булдым. Халык белән шыгрым тулы вагонда кара мыеклы яшь кенә бер егет белән яше инде илленәрне узып киткән авыл апае бәхәсләшә иде. Баштарак аларның өзек-төтек сүзләре генә ишетелеп торды. Бераздан вагон эче тынды, кешеләрнең игътибары бәхәскә юнәлде.

Мин дә бу бәхәскә ихтыярсыз колак салдым, чөнки анда «Тукай», «Кушлавыч» дигән сүзләр әледән-әле кабатланып тора иде.

Авыл апае белән мыеклы чибәр егет янында бер урын буш иде, шунда күчеп утырдым. Тыңлый башладым.

Егет әйтте:

— Сез, апа, юкка бәхәсләшәсез: Тукай Кушлавычта туган.

Башына өчкелләп чытыр ак яулык бәйләгән апа бирешми:

— Син, энем, ничаклы тавышлансаң да, мине ышандыра алмыйсың, Тукай Кушлавычта түгел, Кырлайда туган.

— Мин бит инде беләм, мин үзем Кушлавычныкы, Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф хәзрәтләрнең йорт урыннарын да беләм...

— Юк, — ди авыл апае, — әллә ниткән дәлилләр китереп тә син, энем, мине ышандыра алмыйсың. Тукай Кырлайда туган.

-- Алайса, исбат итегез, — ди егет, авыл апаеның һөҗүменнән арып.

— Исбатлап-нитеп торасы юк аны. Тукайның сиксән, туксан, йөз еллыгы булды. Музейны кайда салдылар? Кырлайда! Арчадан башлап 20 чакрым асфальт юлны кая үткәрделәр? Кырлайга! Авылның культура-мультура сарайларын, мәктәп биналарын, кибетләрен, тагын әллә ниткән йортларын кайда җиткезделәр? Кырлайда түгелмени?

Әлеге бәхәс мине уйга калдырды. Тукайның, барыбыз өчен дә газиз булган бөек шагыйребезнең туган авылын, туган туфрагын ничәмә-ничә еллар без халыктан яшереп килмәдек микән?

Күптән түгел Кушлавычның мәдәният йортында булып узган очрашу вакытында да шундый ук сорау куелды: Габдулла Тукай Кушлавычта туганмы, Кырлайдамы?

Очрашуда катнашкан Татар дәүләт академия театры артистлары Шәүкәт Биктимеров, Ренат Таҗетдинов, Әзһәр Шакиров, Наил Әюпов, Илдус Әхмәтҗанов, Наилә Ибраһимова, Татарстан телевидениесе режиссеры Әхтәм Зарипов, күп серияле «Тукай» фильмының директоры Әзһәр Хөсәенов һәм без фәкыйрегез «Тукай Кушлавычта туганмы, Кырлайдамы?» дигән сорауга җавап бирергә мәҗбүр булдык.

Дөресен дөрес итеп әйтергә кирәк. Кушлавычка еллар буе игътибар җитмәде, ул гел читтә калып килде. Инде егерме елдан артык без Татарстанда Шигырь бәйрәме үткәрәбез. Ул нәкъ менә Тукай туган көнгә багышлап, апрель азакларында уздырыла. Казанда, Арчада, Кырлайда шагыйрьләребез шигъри митингларда кайнар сүз сөйлиләр, ә Тукайның туган авылы Кушлавыч читтә кала. Нилектән? Язын, ташкын сулары аккан чакта, Кушлавычка юл юк. Кушлавычның урта бер җирендә тирән чокыр бар, күпер юк, авылның уртасына язын кереп булмый — Кушлавыч тагын читтә торып кала.

1996 елның апрелендә Тукайның тууына 110 ел тула. Шул уңайдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты махсус карар кабул итте. Шушы елның 10 мартында кабул ителгән карарда, ниһаять, Тукайның туган авылы Кушлавыч та телгә алына. «Телгә алына» дип әйтүем юкка түгел. Кушлавыч беренче чиратта Казаннан, Кырлайдан, Өчиледән — барлык башка урыннардан алдарак әйтелергә, беренче рәткә чыгарып куелырга тиеш иде. Татарстан Мәдәният министрлыгы Кушлавычның гел арткы рәттә калып килгәнен белмиме әллә? Белмәсә — белгертергә кирәк. Тукай бездә бер генә. Чит илләргә чыккан чакта бездән: «Күпме бодай үстердегез? Күпме нефть чыгарасыз? Күпме чуен коясыз?» — дип сорамыйлар, чөнки Аурупа илләрендә икътисад мәсьәләләре инде хәл ителгән, ул хакта сүз куертып торуның хаҗәте юк. Бездән визит карточкасы итеп даһиларыбызның кем булуын сорыйлар. Без андый чакта Тукайны, Җәлилне, Сәйдәшне күрсәтәбез.

Торгынлык елларын хурлау соңгы вакытта модага керде. Моны безнең зыялыларыбыз (дөресен әйткәндә, халыкка әллә ни файда китермәгән, әсәрләре белән милләтне куандырмаган зыялыларыбыз) күбрәк эшли, әмма алар «торгынлык» елларында мәдәниятебезнең күкрәп барганын, Татарстан хөкүмәтенең нәкъ шул елларда мәдәният үсеше өчен бик зур һәм җитди чаралар күргәнлеген онытлар. Тукайның Кырлайдагы дәүләт музее, Аурупа күләмендәге музей, кайчан салынды? Торгынлык дип тиргәлгән 76 нчы елны! Шул дәвердә Арчадан Кырлайга 20 чакрым озынлыктагы асфальт юл түшәлде, ул юлның ике ягына буй урман утыртылды. Болар барысы минем хәтеремдә. Татарстанның Министрлар Советы рәисе урынбасары Мансур Хәсәнов атна саен диярлек Кырлайга бара, үзе белән йә мәдәният министрын, йә Язучылар берлеге рәисен алып бара иде. Тукай бәйрәмнәренә әзерлекне ул бөек шагыйрьнең 90 еллыгында да, 100 еллыгында да күз уңыннан ычкындырмады. Нәкъ шул елларда Тукайның бәйрәмен без «ЮНЕСКО» масштабында, бөтен дөнья җәмәгатьчелеге белән бергәләп уздыра алдык. Әйтик, Тукайның 90 еллык бәйрәме «ЮНЕСКО» тарафыннан 140 илдә билгеләп узылды. Шул елларда Тукайның 4 томлык һәм 5 томлык «Әсәрләр»е дөнья күрде, фәнни монографияләр басылды, бәйрәм тантаналары Кырлайда, Казанда, Мәскәүдә, Финляндиядә, хәтта Америкада үткәрелде.

Хәзерге чорыбызны без «ЯҢАРЫШ» чоры дип атыйбыз. Шулай булгач, яңарыш зуррак, күләмлерәк булырга тиеш. Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты үзенең карарында элек эшләнгән эшләрнең, күрелгән чараларның берсен дә калдырмаган, шул исәптән Казанда ачылган Тукай музее да искә алынган. Карарда миңа, мәсәлән, Казанның «Болгар» номерларын реставрацияләү, Кушлавычта башкарылачак эшләр асруча ошады.

Карар нинди генә матур булмасын, әгәр аны тормышка ашыручы кешеләр юк икән, ул карар булып кәгазьдә генә кала. Кушлавычта күмәк хуҗалык предприятиесенең рәисе Ренат Фәйзиев һәм авыл советы рәисе Гөлфия Шаһиева — Кушлавычның киләчәге, Тукай ватанының гүзәллеге, бөек шагыйребезнең истәлеген мәңгеләштерү өчен җаннарын фида кылырга әзер торучылар. Алар, төп вазифалары-муеннан булса да, Тукай хакына, әдәбиятыбыз-сәнгатебез хакына армый-талмый эшлиләр. Тукайның 110 еллыгына 20 серияле телевизион фильмның беренче өлеше — шагыйрьнең балачак тормышын гәүдәләндергән 7 сериясе өлгерсен өчен, алар барлык шартларны тудырдылар. Мәктәп балалары, картлар-карчыклар фильмны төшерүдә катнашты, борынгы киемнәрне, йорт җиһазларын табып бирештe. Кушлавычның даһи улына мөнәсәбәте, аңа булган чиксез ихтирамы менә шунда күренде.

Мәдәният йортында Кушлавыч халкы белән артистларның очрашуында да алар оештырды, ихласлык, туганлык хисләре ташып торган бу очрашуда Тукай шигырьләре, Җәлил шигырьләре укылды, Әлмәндәрнең атаклы җыры җырланды, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләре күтәрелде, кичә Тукайның «Туган тел» җырын очрашуга җыелган халыкның һәм артистларның бергәләп җырлавы белән тәмамланды.

Бу урында мин Кушлавыч авылының мәдәният йорты реставрацияләнүен аеруча билгеләп узарга телим. Арча педагогия колледжыннан килгән ике егет — Илсур белән Атлас — мәдәният йортын яңа, сап-сары такталар белән безнең күз алдында тышладылар, сәхнәне яңарттылар, өстәвенә, сәхнәгә керү ишегенә агачтан кисеп, төрле фигуралар, орнамент бизәкләре куйдылар. Орнаментны Илсур эшли. СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров аның осталыгына таң калып: «Бу егетне сәнгать академиясенә җибәрергә кирәк», — диде.

Күмәк хуҗалык җитәкчесе Ренат Фәйзиев, Тукайның 110 еллык бәйрәменә әзерлекнең никадәрле җитди вә мөһим чара икәнлеген тормыш мисалында күрсәтергә теләп, безгә Кушлавычның аркылысын-буен күрсәтте.

Гомер буе Кушлавычка керүне тоткарлап торган коры елга — тирән бер чокырда тракторлар, бульдозерлар эшли — коры елганы 18 метрга күтәрү, аннары аның аша күпер салу эшен Мари-Эль Республикасының Бәрәңге районы татарлары башкара. Мари-Эль җитәкчеләренең Тукайга якты күз белән караулары барыбызны да шатландырды.

— Бу күперне салуга бер миллиард сум акча тотылачак. Мари дусларның биредә механикалаштырылган күчмә колоннасы эшли. Егетләрнең тамаган без туйдырабыз, машиналарына ягулыкны без бирәбез, калганы — трактор һәм бульдозерлары, тимер-бетон плитәләре, субай-баганалары — барысы да үзләренеке, — ди Ренат Фәйзиев. Ул боларны күңел канәгатьлеге белән әйтә, аннары кинәт моңсуланып, боегып кала. — Без аларга хәзер эшләгән эшләре һәм тоткан материаллары өчен 150 миллион сум акча түләргә тиеш. Ә акча юк, Казан акча җибәрми, нишләргә? Ярый әле егетләр — Тукайны аңлаучылар, ыңгырашмый эшли бирәләр, юкса, эшнең туктап калуы да мөмкин иде. Акча юклык муеннан суя, билләһи...

Без — Шәүкәт Биктимеров, мин, Гөлфия ханым, Әхтәм Зарипов баш селкеп утырабыз, да-а-а, дибез, күпер кирәк, күперсез Кушлавычны дөньяга танытып булмый!

Киночыларның хәлен белергә, Тукай бәйрәменә Кушлавычта ничек әзерләнгәнне карарга дип килгән ике җитәкче — Арча хакимияте башлыгының урынбасары Шәфигулла Гарипов һәм хакимиятнең мәдәният бүлеге җитәкчесе Рафил әфәнде кулларын җәеп җибәрәләр — акча юклыктан гаҗиз булуларын белдерәләр.

Ренат Фәйзиев кулдан килгәннең барысын үзе башкара — авылга инде газ кертеп бетереп киләләр икән. Авыл өчен бу, әлбәттә, зур куаныч — җәй буена утын артыннан чабасы юк. Әмма бер яхшылыкның бер начарлыгы бар дигәндәй, газ кертү уңаеннан авыл урамнарын казырга, хәтфә чирәмне ертырга туры килгән. Авыл халкы өчен — газ кертү әйбәт, чирәмне ерту — начар. Йомшак табигатьле, булдыклы Фәйзиевне авылда яраталар, ул килгәннән бирле эшләр гөрләп китте, диләр, әмма Тукай заманнарыннан бирле сакланган чирәмле урамнарны бозуын яратмыйлар.

— Менә газны кертеп бетерик, Кушлавыч урамнарына — урта бер җиргә асфальт сузарбыз, ян-яклары яшел хәтфә чирәм булыр, чирәм, үзем дә беләм, җаннарны иркәли бит ул, — ди Фәйзиев.

Рафил әфәнде кино аппараты а... чыккан, күпер салучыларны, авыл... гомуми күренешен киноiа төшерә, ... сөйләшкәннәрне язып ала. Болар Ту... усадьбасындагы музей өчен кирәк бу... чак.

Авылны «зыр круглый» әйләнеп ... габыз. Читтән караганда да, урамнар... на кереп караганда да — Кушлав... матур. Ул ике сөзәк тау битенә урна... кан. Агач күп биредә, яшеллек күп. Ч... авыл икәне җанга ягымлылык өстәп ... ра.

— Арча ягыннан асфальтны без ... лып киләбез. Кушлавыч ягын авыл ... салыр. шулай итеп безнең татар хал... табыначак Мәккәбез әзер булыр, б... лык юллар да аңа китерер, — ди Шә... гулла әфәнде.

Фәйзиев аны игътибар белән т... лый. рәхмәт әйтеп, «сакалын селкет... аннары:

— Без хәзер Тукаебызның була... усадьбасына барыйк. анда инде сүз ... шкачарак булыр. — ди.

Без усадьбага юнәләбез. Музей й... ты әзер. Ул — шыңгырдап торга... рат бүрәнәләрдән салынган озынча ... катлы йорт. Иңе — 9. буе 19 ме... Гомуми мәйданы 171 квадрат метр.

— Сезнең монда эшләр шәп б... икән бит. — дим мин, Кушлавычта ... зей бинасы салынганга куанып.

— Бигүк шәп түгел шул, — ди Ф... зиев. — Бинаны без ничек кирәк. а... салдык. Әмма әле аңа акча түләнеп б... мәгән. Шуның өстенә бит әле аның э... позициясен эшлисе бар. Әнә карш... ы мәчет бинасын күрәсезме? Бина ... җиткезелде. манарасының да ярты... корылды. шуның белән эш туктал... — акча юк. Юк бит акча, каһәр с... кыры! Музей экспозициясе һәм мә... корылышы өчен 200 миллион чама... акча кирәк. Шуны берничек тә таба ... мыйлар. Бер тотынгач, күпер дә са... ныр. асфальт юл да булыр, ә менә ... зей әзер булмаса, мәчет корылып б... мәсә нишләрбез? Бөек бәйрәмнең ... булмас бит.

Аның сүзен авыл советы рәисе Г... фия ханым куәтләп җибәрә:

— Шушы бәйрәм уңае белән мәкт... нең дә һич югы нигезен салып куя... иде. Бездә бит моңарчы башлангыч ... ктәп кенә эшләп килде. Зур мәктәп б... магач, читкә киткәннәр кире кайт... Бездә 70 йорт бар иде, инде менә ... булдык. Тукайның туган авылы 150 ... ртлы булса, күзгә күренеп, җаннар ... кинәндереп яшәр иде. Безнең әнә ба... лар бакчабыз бар. балаларны анда м... ли рухта бик матур итеп тәрбияли... мәктәбебез дә булса, эшләр гел дә г... ләп китәр иде...

Кулдан килми торган нәрсәләрме... болар? Бу хакта Мәдәният министрл... гы белән Мәгариф министрлыгы да ... рчылсын иде. Мәктәп һәм мәчет, Тук... усадьбасы аларга йөкләнгән бит. ... җәмәгать, барыбыз бергә тотынып, ... шлавычны Мәккәбез итик әле!

— Менә, Гариф абый, әйтегез ә... язучылар безгә ничек булыша а... — дип сорый Фәйзиев.

— Язучыларның бүген үз хәлл... хәл, авыр тормыш кичерәләр. Әм... безнең кулда бик көчле корал бар: ... түрәләрне, ягъни республикабыз җит... че085ләрен борчып, аларның вазифалар... искә төшереп тора алабыз, — дим м...

— Ә үзебез музейга берәр генә китаб... бызны автограф белән бирсәк тә, ... китап дигән сүз. Мин үзем, мәсәл... музейга 100 китап бирергә вәгъдә ит... китап күп безнең гаиләдә.

— Гариф абый, сез безгә Илгиз Х... руллинны алып килсәгез иде. Аны ... дәният өчен янып-көеп яшәүче, дил... Без башкарган эшләрне үз күзе бе... күрсә, бәлки сметада каралган а... ягын да җайга сала алыр иде, — ... тәмле телле Гөлфия ханым.

Барыбыз да тын калабыз. Күңелл... дә — Кушлавыч. Аңа ни рәвешле ярд... итеп була? Башланган эшләрне төг... ләп чыгу өчен тагын нишләп карар... кирәк?

Миңа калса, Кушлавыч халкы һ... аның җитәкчеләре кулдан килгән... инде барысын да эшләгәннәр.

Халык биредә бик тырыш, бер та... чы яңгыр төшмәгән елны да гектарь... нан 16 центнер уңыш җыеп алганн... җәмәгать терлекләрен һәм хуҗалык... рдагы мал-туарны азык белән тәэм... иткәннәр, йортларга газ кертүне төг... ләп киләләр, кыскасы — Кушлавыч ... лкының йөзе ак, намусы пакь, хә... калганы — республикабыз җитәкче... кулында.

Татар халкының рухи хәзинәсен һ... күңел газапларын җаны аша уздыр... даһи Тукайга лаек булсын иде Кушл... вычи

«Тарих каршылыгына урыс җавабы»

Рәсәй һәм Чечня

Чечнядагы хәлләр бөтен Рәсәйне тетрәтте. Илдәге ...әле сәяси көчләрнең Грозныйда Дудаев режимын ...ырута карата мөнәсәбәтен тикшергәндә шундый ...нәтиҗәгә киләсең: Чечнядагы сугыш Рәсәйдә «бе...м уң-сул оппозиция» барлыгы турындагы уйдыр...ны юкка чыгарды һәм «Хакимият һәм реформа...р» партиясен икегә бүлде. Булырга тиеш хәл таби...й вә канунлы рәвештә тормышка ашты. Әле кичә ...а теш-тырнаклары белән Ельцинны яклаган сә...тчеләр (Гайдар, Явлинский, С.Ковалев, Юшенков, ...нар һ.б.) «халык тарафыннан сайланган прези...тка» каршы чыктылар. Аларга шулай ук иң сул...р (Анпилов), Думаның РФ компартиясеннән булган ...р төркем депутатлар, «дәүләтче-центрист» Ю.Ско...в, Рәсәй Халык Союзы җитәкчесе А.Стерлигов, РФ ...ставындагы күп кенә милли республикалар җитәк...ләре (Р.Аушев — Ингушетия, Н.Федоров — Чува...я, М.Николаев — Якутия, М.Шәймиев — Татар...н) һ.б. теләктәшлек белдерделәр.

Әлеге вакыйгалардан соң шунысы ачыкланды: ба...ынча Рәсәй дәүләтчелеген җимерү белән шөгыль...ләнгән Ельцин режимы, империяне янә ныгыта баш...у чараларын күрергә керешкәч ук кичәге дошман...ары — радикаль демократлар, коммунистлар аңа ...рдәм фронт белән каршы чыктылар дияргә була. ...к Кремль хакимиятенә оппозициядә торган урыс ...лли оешмалары исә Чечнядагы сәясәтне принципи...ь рәвештә якладылар.

Шулай итеп, 1994 елның декабрендә Чечняга Рәсәй ...миясе частьләрен кертү XXI гасырга керен бар...ган Рәсәй тарихының яңа этабын башлап җибәрде.

Бәлки бүген, соңгы чиккә килеп җиткән бер вакыт...ы, урыслар үзләренең Рәсәй халкының 82 процентын ...ның 5 проценты — тугандаш белоруслар һәм укра...ннар) тәшкил итә торып та «Федерация субъект...ларындагы» милләтчеләрнең оятсыз дәгъвалары кар...ында куркаклык күрсәткән һәм икътисади, этник ...ктан кәрлә республикаларның (РФ республикалары...ндагы җирле халыклар бөтен халыкның 6,6 процентын ...ына тәшкил итә) гаять зур Рәсәйнең сәяси хуҗалары ...әверелүләренә юл куйган очракта, безгә котыл...гысыз тарихи үлем янаганын аңлый алырлар. Ә урыс...лар белән бергә Рәсәй дә һәлак булачак. Ник дигәндә, ...фәкать милләтләр генә дәүләт төзи ала. Киресе була ...мый.

Чечнядагы хәлләр РФ составындагы «суверен» ...лли республикаларның Рәсәйнең бердәмлегенә һәм ...ылынычсызлыгына нинди зур куркыныч белән яна...ларын бик ачык күрсәтте. Кайбер сәяси лидерлар, ...тик, Чабаксардагы Н.Федоров, ачыктан-ачык дәүләткә каршы позициягә күчте. «Территориаль бөтенлек белән кешеләрнең күпләп кырылу мөмкинлеге арасында коллизия туганда территориаль бөтенлекне корбан итәргә кирәк», — дип әйтте Чувашия Президенты. Н.Федоров Рәсәйнең юстиция министры булган вакытта чеченнарның җинаятьчел группировкаларына каршы нинди дә булса чаралар күрдеме соң? Ә ул вакытта Рәсәйдә алар кулыннан күпме кеше һәлак булды бит.

Республикалар башында утыручы «суверен президентлар»ның Гайдар-Юшенков-Старовойтова тибындагы «демократлар» белән берлектә бердәм фронт булып каршы чыгуы бик гыйбрәтле хәл, әлбәттә. Мин үзем киләчәк Рәсәйдә һичбер милли республикалар булырга тиеш түгел дигән карашта торам. Анда фәкать губернәләр, милли-мәдәни автономияләр, барча Рәсәй халыкларының үзидарәләре кебек үзләрен тарихи яктан аклаган формалар гына калырга тиеш. Сәяси һәм хәрби өлкәләрдә ваемсызлык һәм булдыксызлык күрсәткән түрәләр каты җәзага тартылырга тиешләр. Дәүләтне таркатуга юнәлдерелгән (бигрәк тә сугыш чорында) теләсә нинди эшчәнлек сатлыкҗанлык дип бәяләнергә тиеш.

Төрле милләтләр яшәүче СССР таркалгач, элекке союздаш республикалар урынында яңа дәүләтләр барлыкка килде. Милли мәсьәлә Рәсәйнең үзендә дә кискенләште. Монда Чечня һәм Татарстан этник низагларның флагманнары булып торалар. Рәсәйдә ачык рәвештә ярылып ятмаган киеренкелек булган төбәкләр дә аз түгел.

Хәзерге Рәсәйнең көньяк чикләрендә барлыкка килгән күптөрле низаглар Рәсәйне эчтән тотрыксызландыручы факторлары белән бергә кушылып бердәм конфронтация кырына әверелергә мөмкиннәр. Бу исә Рәсәйгә куркыныч белән яный. Моны аңлатып торуның кирәге юк, дип уйлыйм.

Эчке ислам

Рәсәйнең үзендәге мөселман анклавлары безнең ислам дөньясы белән мөнәсәбәтләребездә төп каршылык булып торалар. Монда сентиментальлеккә урын юк. Христиан илендә мөселман автономияләре булуның нәрсәгә китерүен Югославия мисалында да күрергә мөмкин. Хәзер без аны Чечня мисалында күрәбез.

Рәсәй туфрагында ислам мәдәнияте чагыштырмача нык үскән бер генә үзәк бар. Ул — Казан. Татарстан үзенең урта гасырлардагы дәүләтчелеген бик яхшы хәтерли. Татар элитасы арасында исламчылык һәм төркичелек карашлары бик киң таралган. Татарлар Рәсәй икътисадында һәм финанслар өлкәсендә нык позиция алып торалар. Урыс мәдәни позицияләреннән ерак торган бу милләтнең әһәмиятен игътибардан читтә калдырырга ярамый. Әгәр исламчылык һәм төркичелек татар элитасын тулаем яулап ала икән, Рәсәйгә иртәме-соңмы милли-шовинистик көчләрнең республика структураларына йогынты ясавын кискен рәвештә чикләргә туры киләчәк. Татарстанның Төркия, Урта Азия, Туран комплексы белән сәяси яктан якынаюына юл куярга ярамый.

Эчке исламның икенче үзәге — ул Төньяк Кавказ. Бу төбәк халкы үзенең агрессивлыгы һәм социаль мобильлеге белән аерылып тора. Рәсәйдәге чечен, ингуш, дагстанлылар мафияләренең «батырлыкларын» без бик яхшы беләбез. Бу төбәкләргә карата без аеруча зур сәяси катылык күрсәтергә тиешбез.

Төньяк Кавказдагы вакыйгаларга әйләнеп кайтып, тагын бер кабатлыйсым килә: Чечня (республиканың көньяк районнары) безнең дәүләт составына реинтеграцияләнергә тиеш түгел. Иң беренче нәүбәттә Рәсәйдәге вайнах җинаятьчел төркемнәре өчен түзә алмаслык шартлар тудырырга кирәк.

Төньяк Кавказның башка республикаларына шуны аңлатырга кирәк: урыс милли дәүләтендә аларның мәнфәгатьләр өлкәсе фәкать эчке проблемалар белән чикләнәчәк.

Ни генә булмасын, Рәсәй нәсел-ыру кланнары арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм Төньяк Кавказ «элитасы» арасында тирән тамыр җибәргән коррупцияне үз максатларында файдаланып, ышанычлы һәм тәвәккәл рәвештә хәрәкәт итәргә тиеш. Шуны һәрвакыт истә тотарга кирәк: йомшак сәясәтнең берниндн дә киләчәге (бигрәк тә Кавказда) юк.

И.АРТЕМОВ.
(«Наш современник»).

«Урыс җавабы» уңаеннан татар кешесе уйланулары

Яшь урыс галименең «Тарих каршылыгына урыс ...вабы» дигән мәкаләсендә принципиаль яңа бернәр...ә дә юк. Ул дәүләт кризис кичергән чорда иң уң ...периячел позициягә күчүче «ватандарлар»ның га...и мөнәсәбәте.

Кызганычка, «тарих Рәсәйне даими рәвештә барье...а чакырса да», кайбер тарихчылар һаман акылга ...ра алмадылар. И.Артемовның менә шушы «җава...» егерменче йөз башында Пуришкевич әфәнде ...шнары каләме астыннан да чыгарга мөмкин иде. ...уйларга кирәк.

Әлеге җырның көе инде шактый искергән һәм ...ыксыз. Янәсе, тормыш Рәсәй белән низагка кер...икән, аңа каршы көрәшергә кирәк. Тарихны сыза...һәм яңабаштан язарга! Ник дигәндә, тарих Рәсәй ...маннары аркасында шулай язылды бит. Сәер ...м, бик сәер...

...ннары яңа, яхшы тарих кысаларында ил «яңа...» чорына басачак, имеш. Әлбәттә, булачак ис...лар вакыты җиткәч, илне мондый «яңарыш» ...а бастыручыларның үзләренең исемнәрен дә та...тан сызып ыргытачаклар. Ләкин тагын бер буын...соң аларны янә җирдән казып алып, аларга табы...башларга мөмкиннәр бит. Хоер, ахыр чиктә таш...таштый күмәчәкләр.

Күрә белебезчә, Рәсәй тарихы бик ачык циклардан ...з. Аларның һәркайсы үзеннән элек булганны ин...тә һәм «яңасын» (икенче төрле әйткәндә, оныты...искесен) гамәлгә ашыра. Шуңа күрә дә, Рәсәйнең ...е дә, киләчәге дә билгесез, дип әйтәләр инде. ...р, үз мәнфәгатен турында гына кайгыртып яшә...очракта, үткәннәрне һәм киләчәкне ачыклау ...ни авыр эш түгел түгелен.

...р циклга ясалма рәвештә «Рәсәй дошманнары» ...төшенчә кертелә (ә алар җәллад балтасыннан ...булган гөнаһсыз корбаннар булып калалар). ...буыннар һәм кызыксынган кешеләр өчен күп...социаль күренешләр яисә миражлар «дошман» ...мы булып хезмәт итәргә мөмкин. Берәүләр ...ул «бөтендөнья жид-масон фетнәсе, икенчеләр ...— «самодержавие һәм бөтендөнья буржуази...», өченчеләр өчен — «ислам факторы»... Ә тарих ...е Клио барысы өчен дә иң дәһшәтле дошман ...күренә. Безнең яшь фикер иясе дә аңа карата ...е позициясенә басты.

...ызганычка, боларның берсе дә көлке түгел. Һәм ...тарихы каннан ясалган кара белән яңабаштан ...рга мөмкин. Зур илдә зур кан дәрьялары кай...м инчек акканын без бик яхшы беләбез. Бу юлы ...рьялар сай булмас. Мәрхәмәт көтмәгез.

...р-берене үтерү механизмы эшләп китсә, аны ...дә туктата алмаячак. Һәм бу үтерештән читтә ...мөмкин түгел. Чөнки «Рәсәйнең тышкы до...ары белән көрәш «эчке дошманнарга» каршы ...әверелә. Ә «аңлы дошманнар» юкка чыга..., аларның «аңсыз булышчылары»н эзләү башлана. Һәм бу бердәм һәм корычтай нык хакимият барлыкка килгәнче дәвам итәчәк. Мондый хакимиятнең нигезендә исә «мәсләккә бирелгәнлек» түгел, ә гадәти курку ятачак. Нишлисең бит, подвалда тырнакларыңны суырмасыннар дисәң, телеңне тешләргә туры килә.

Рәсәй империализмының беренче гомуми кризисы чорында тарихны дуэльгә чакырырга җөрьәт иткән кайбер кайнар башлар Рәсәйнең дошманы итеп «ислам факторын» күрсәтәләр.

Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк, әлеге кара тәкәгә иң беренче тапкыр В.Жириновский атланып чыкты. Күрәсең, «юрист улына» «жид-масон фетнәсе» тәкәсенә атланып зур сәясәткә керү уңайсыз булып тоелгандыр. Белгәнебезчә, киләчәктә Һинд океанында урыс итеген юарга хыялланган бу бәндәне яклаучылар да аз түгел.

Фәннилеккә дәгъва кылучы И.Артемов «ислам куркынычы» турында бәян итеп, аны булдырмау рецептларын бирә. Шуның белән бергә, ул Рәсәй империализмының газаплы үлемен ким дигәндә тагын бер йөз елга озынайтачагын аңламый да, аңларга да теләми.

Ул уйлана торсын, ә без, кадерле укучым, кечкенә генә бер тәҗрибә ясап карыйк. Әйтик, Җир йөзендә урыслардан кала бер генә яһүд тә, татар да, чуваш та, американы да калмаган дип күз алдына китерик. Шәп булыр иде бит, ә! Бөтен дөнья урысныкы. Телисең икән, Константинопольдә яшә, телисең икән, Вашингтонда. Шуннан соң җирдә беркайчан да сугыш булмас дип уйлыйсызмы? Юк шул, ялгышасыз. Бу очракта урыслар үзара сугыша башлаячак. Әйтик, шул ук яшь көрәшче И.Артемов карт генерал Стерлиговка урыс халкы исеменнән сөйләү хокукы бирергә теләми. Берәүләр Рәсәйне мөселманнар таркатты дисә, икенчеләре яһүдләрне гаепли. Әле бит үзара тартышканда кайсысының да булса тамырларында күбрәк яһүд, яисә татар каны акканы да ачыкланырга мөмкин. Һәм китә инде шуннан соң чәч йолкыш...

Мин үзем татар милләтеннән. Һәм урыс халкына бәхет телим. Чөнки ул бәхетсез булганда, татар да, якут та, мари да бәхетсез булачак. Урыс халкы үзе бәхетсез булганда азчылыкны тагын да күбрәк газаплый бит. Тарих шуңа шаһит. Икенче төрле әйткәндә, без урыс халкының «заложниклары».

Бервакыт Казанда генерал Стерлигов белән очрашкач, мин Рәсәй дип аталган «унитар типтагы барак»ны күп фатирлы суверен дәүләтләрдән торган йортка әверелдергәч кенә урыс халкы бәхетле булачак, дигән идем. Әмма генерал минем белән килешмәде. Унитар дәүләттә дә яхшы яшәргә була, диде ул. Һәм генерал XYII гасырда Бөек Гыйсъянны бетерә алуга ирешкән беренче Рус Соборын мисал итеп китерде.

Шулай итеп, Александр Стерлигов та тарихтан гыйбрәт алмаган булып чыкты. Узган биш гасыр аның өчен бөтенләй булмаган диярсең. Рәсәйдә теләсә нинди собор органының мәрхәмәтсез рәвештә тираннарга буйсындырылганын яисә юк ителгәнен белми микәнни ул?! Иван Дүртенче чорында да шулай булган. Боярларны ни эшләтәсе килсә, ул шуны эшләгән. Николай Икенче заманында да шулай булган. Анысы үзенә ошамаган дүрт Думаның өчесен үзенә буйсындырган яисә тараткан (дүртенчесе аның үзен тәхеттән алып ыргыткан). Хакимияткә Ленин килгәч тә, шул ук хәл кабатланды. Ул «яраксыз Учредительное Собраниене» гамәлдән чыгарды. Безнең чорда да булды мондый хәлләр. Бер көнне уяндылар да Югары Советны тупка тоттылар.

Аңлашыла ки, «унитар барак» белән һәрвакыт мәрхәмәтсез «пахан» гына идарә итә. Мондый баракта — римлыларныкы, кытайларныкы, урысларныкы булсын — соборлык та, демократия да, бәхет тә була алмый.

Хәзер күп кенә алга киткән илләрдә чын демократия хөкем сөрә. Җир йөзендә әле бер генә империя дә мәңгелек булмаган. Византия, Рим кебек нинди көчле империяләр дә таркалган. Ә Рәсәй империясе Өченче Рим империясе сыйфатында XXI гасырга кереп бара. Һәм шуның өчен күпме кан, күпме күз яшьләре түгелә.

Юк, урыс та, татар да, чуваш та бәхетле булмаячак. Шулай да урыс халкының чын дошманы кем? Белмәсәгез, белегез инде: И.Артемов кебек Өченче Римны саклап калырга теләгән кешеләр алар.

Илдар СӘГЪДИ,
«Татар-Информ» хәбәрчесе.

ТАТАР ЯУГИРЛӘРЕ

Солтан ШӘМСИ

Гыйсъянчы мирза

Бу шәхес Алтын Урда дәүләте тарихында тирән эз калдыра. Бирдебәк хан үтерелгәч (1359) башланып киткән тәхет дауларында актив катнаша. Ул үзенең вафатына кадәр (1380) егерме ел дәвамында илнең сәяси тормышында мәйдан тота, шул сәясәткә юнәлеш бирүче төп затларның берсе була. Кыскасы, Мамай мирзаның тормыш юлы Алтын Урда тарихы белән бик тыгыз бәйләнгән, аны шушы тарихтан аерып карау мөмкин түгел

Мамай мирза үзе ханнар нәселеннән булмаса да, гаять көчле, һәркайда сүзе үтә торган абруйлы шәхесләрдән саналган. Тумыштан килгән ихтыяр көче, гаярьлек, тәвәккәллек, кешеләр белән идарә итә белү кебек сыйфатларга Бирдебәк хан кияве булу да өстәлгәч, аның дәрәҗәсе тагын да үсеп киткән булса кирәк. Урыс тарихчылары аның хакында, түбәнсетергә тырышып, «темник Мамай» дип кенә язалар. Темник татарча «төмән башы» дигәнне аңлата, ягъни ул — 10 мең сугышчы белән идарә итүче гаскәри-полководец, дигән сүз. Мамай мирзаның рәсми титулы-дәрәҗәсе чыннан да төмән башы булгандыр, күрәсең. Тик Алтын Урда тарихына ясаган йогынтысы-роле ягыннан караганда, аның «төмән башы» гына булуы белән килешүе кыен. Чөнки тарихи вакыйгаларга бик нык тәэсир итеп килгән, еш кына аларны теләгән якка борып җибәрә дә алган, үзенә кулай кешене тәхеткә чыгарып хан итеп куйган шәхеснең гади төмән башы гына булмавы көн кебек ачык.

Мамай мирзаның биләмәләренә Кырым белән Кара диңгез буе, Азак-Дон буе далалары кергән. Бу хәл үзе үк аның Кырым белән хәзерге Украина далаларында хуҗа булып яшәвен күрсәтә. Димәк, мирзаның тоткан урыны олыс бәге дәрәҗәсенә туры килгән. Бәлки, Бирдебәк хан көчле киявенә шушы олыс-җирләр белән идарә итүне тапшыргандыр. Мамай мирза исә үз чиратында ханга күп хезмәтләр күрсәткән, хәбәр килеп ирешү белән гаскәрен җыеп аның байрагы астына баскан, биләмәләрендә ханга тиешле салымнарны җыюны оештырган...

Мамай мирза нигездә үз олысында иркенлектә яшәсә дә, хан кияве буларак, дәүләтнең башкаласы Сарай шәһәренә дә еш килгән, анда озаклап кунак булганга охшый. Шул рәвешле ул Сарай әһелләре, дәүләт эшлеклеләре арасында бик күп дус-ишләр, табындашлар, тарафдарлар булдыра. Һәм бу файдалы танышлыклар вакыты җиткәч аңа бик тә ярап куя, сәяси эшчәнлегендә таяныч була.

Бирдебәк хан үтерелгәнче, Мамай мирзаның сәяси вакыйгаларга катнашуы тарихи чыганакларда күренми. Күрәсең, бу дәвердә ул хан кияве сыйфатында беркая да кысылмыйча тыныч кына яшәгән булса кирәк. Хәер, тәхеткә утырганнан соң күп туганнарын үтерткән явыз Бирдебәк хан заманында андый мөмкинлек булмаган да. Каршы сүз әйтү баш бәясе торган. Ә инде Бирдебәк хан фетнәчеләр тарафыннан юк ителгәч, буа ерылып киткәндәй була.

Башта Сарай тәхетенә Үзбәк ханның оныгы, Иренбәкнең улы Көлпә чыга. Тик ул ярты ел гына хакимлек итеп кала. Аның артыннан тәхеткә Нәүрүз хан утыра. Ләкин Нәүрүз хан заманы да озак дәвам итми. Ул үз эшчәнлегендә дәүләтнең Идел буе һәм аннан көнбатышта урнашкан олысларга таяна. Димәк, бу вакытта көнчыгышта урнашкан олыслар дәүләт эшләрендә үз сүзен әйтә, актив роль уйный алмаган. Бу исә андагы олыс бәкләрен, идарәчеләрне Нәүрүз ханга каршы куя. Сарайның үзендә дә ханга каршы торган әмирләр аз булмый һәм алар, мөстәкыйль яшәп яткан Күк Урда ханы Чимтайга кешеләрен җибәреп, аның Сарай тәхетенә чыгуын сорыйлар. Тик Чимтай хан башын андый хәтәр эшкә тыкмый, бу низаглардан читтә калу ягын карый. Шулай да мөмкинлекне бөтенләй кулдан ычкындырмас өчен ул Сарай тәхетенә үзенең туганы Хызырны тәкъдим итә. Күрәсең, Сарай әмирләре бу кандидатураны да ярашлы дип тапканнар, чөнки тиздән Нәүрүз хан бәреп төшерелә дә тәхеткә Сасы Буга улы Хызыр хан чыга.

Хызыр ханның тәхеткә утыруы дәүләт башкаласы Сарайда көнчыгыш олысларга йөз тоткан партиянең вакытлыча өстенлек алуы турында сөйли. Әлбәттә, мондый чакта яна хан үз «командасы» белән килгән, аны күтәргән кешеләр алдында ул үзен бурычлы итеп тойган, аларга зур бүләкләр, җылы урыннар өләшергә тиеш булган. Бу инде җиңелгән партия вәкилләрен таркату, урыннарыннан алу, эзәрлекләү, ә иң хәтәрләрен гомумән юк итү юлы белән башкарылган. Нәкъ шул сәбәпле Хызыр хан идарәсенең беренче көннәрендә үк мәрхүм Үзбәк ханның үтә дә абруйлы, зур йогынтыга ия тол хатыны Тайдула (Риза Фәхретдин аның исемен Тыйтгали дип яза), Нәүрүз ханның улы Тимер һәм төшерелгән хан тарафдарларыннан бик күп бәкләр, мирзалар, угланнар юк ителә. Шуңа да карамастан, Хызыр хан белән хакимияткә килгән Күк Урда партиясе Сарайда ныгып өлгерә алмый. Күп тә үтми, Хызыр ханны да тәхеттән алып ташлыйлар.

Уйлап карасаң, сәбәбе бик гади — монарчы Күк Урда вәкилләренең беркайчан да Сарай тәхетенә чыкканнары булмый. Бу исә аларның Сарай шәһәрендә, киңрәк алганда Идел буенда, Кыпчак даласында таянырдай көчле тарафдарлары санаулы булганлыгын күрсәтә. Ә Сарай әмирләренең, Нәүрүз ханга үч итеп, тәхеткә Хызыр угланны чакыруын башкалада барган ызгыш-талаш, идарәче даирәләрнең бер капризы дип карарга кирәктер. Күп тә үтми, Хызыр ханның да улы Тимерхуҗа тарафыннан үтерелүе фәкать шул хакта сөйли кебек. Бу вакытта башкаладагы төркем-партияләрнең һәркайсы тәхеткә үз ханын куярга омтыла.

Ләкин сүзебез Мамай мирза турында иде бит әле. Ул Алтын Урданың сәясәт мәйданына менә шундый шартларда килеп чыга. Илдә тәхет бүлешү башланып киткәч, хан кияве дә читтә торып өлешсез калырга теләмәгән, күрәсең. Ул хәтта, чаманы онытып җибәреп, 1360 елда Азак шәһәрендә үз исеменнән «Мамай солтан әл-гадел» дигән язу төшкән көмеш тәңкәләр дә суктыра. Дөрес, аның тормышында бу берләнбер очрак була, андый ялгышны ул бүтән беркайчан да кабатламый. Киләчәктә тәңкәләр бары тик үзе куйган хан исеменнән генә суктырыла.

Чыганаклар күрсәткәнчә, Хызыр хан үтерелеп, тәхеткә аның улы Тимерхуҗа чыккач, Мамай мирза аны төшерүдә актив катнаша, бәлки әле моны оештыручылардан төп кеше дә булгандыр. Шулай итеп, хыянәтче угыл тәхеттә атна-ун көн генә утырып кала (1361). Аның урынын Хызыр ханның икенче улы Урдамәлик ала (кайбер чыганаклар бу ханның исемен Урдашәех дип тә атыйлар).

Игътибар итик, Хызыр хан үзе, аның уллары Тимерхуҗа белән Урдамәликләр — барысы да Күк Урда вәкилләре, ягъни Сарай тәхете өчен ят кешеләр. Сарайда, гомумән Идел буенда аларның дошманнары күп булган, шул сәбәпле аларның гомере дә тиз киселә. Бу җәһәттән Күк Урда ханы Чимтайны искә төшерик — аның зирәклегенә сокланып куясың. Әмирләр аны күпме генә дәүләтнең төп тәхете торган Сарайга чакырып карамасыннар, үгетләмәсеннәр — ул гел биек тәхеттән баш тартып килә, анда карендәше Хызырны тәкъдим итә. Әлләни биек булмаса да, ул үзе утырган Сыгнак тәхетен, Сыр-Дәрья буйларын якынрак күрә һәм шуның аркасында башын саклап кала. Өстәвенә әле тәхет варисларыннан да бер-бер артлы арына тора.

Сарайда Урдамәлик хан хөкем сөргәндә Мамай мирза төп тәхеткә үз кешесен утыртырга кирәк, дигән ныклы фикергә килә, гаскәр туплап Идел буена юнәлә. Иң элек ул Азак каласын ала, анда Габдулла исемле

берәүне хан итеп күтәртә. Урдамәлик хан белән Мамай мирза Идел белән Дон арасындагы далада бәрелешкәннәр булса кирәк. Урдамәлик җиңелә, шуннан соң Мамай мирза Сарайдагы тәхеткә Габдулла ханны утырта һәм аның исеменнән идарә итә башлый. Тик андый болгавыр заманда Мамай мирза белән Габдулла ханга да Сарайда озаклап яшәргә туры килми. Ибне Халдун сүзләренә караганда, бу вакытта әмирләрнең берсе Габдулла ханга каршы фетнә оештыра. Фетнәчеләр уңышка ирешкәч, Габдулла хан белән Мамай мирзага Сарайны ташлап китәргә туры килә (1361). Шулай итеп, тәхеткә Котлык Тимер дигән берәү утыра.

Шул ук көннәрдә мәрхүм Җанибәк хан балаларыннан булган Килдебәк тә Мамай мирзага каршы хәрәкәт башлый. Әлбәттә, Мамай мирзаның тәхет даулаучы берничә



хан баласына каршы торырга көче җитми — ахыр чиктә Сарай тәхетенә Килдебәк чыга (1361). Чыганакларда аның үтә дә кансыз, рәхимсез адәм булуы әйтелә. Ул әмирләрне, дәүләтнең дәрәҗәле кешеләрен бер-берсенә каршы котырту юлы белән бик күпләрнең башына җитә. Әлбәттә, мондый сәясәт өске катлам вәкилләрендә нәфрәттән бүтән нәрсә уята алмаган, чөнки күпләрнең гомере кыл өстендә торган. Сарай әһелләре явыз ханны алып ташларга мәҗбүр булалар. Шулай итеп, Килдебәк хан да тәхеткә чыккан елында ук дөньядан китеп бара.

Тарихчылар Алтын Урда дәүләте тарихының 1361 елдан соңгы берничә елын иң буталчык һәм ачыкланып бетмәгән дәвере дип саныйлар. Чыннан да, бу вакытта Кыпчак даласында барган вакыйгаларны төгәл генә күз алдына китерүе җиңел эш түгел, тарихи чыганакларда да алар сирәк теркәлгән. Безнең игътибар үзәгендә Мамай мирзаның эшчәнлеге, катлаулы язмышы булганга, бу чорда аның кайда булганын, нишләп йөргәнен ачыкларга тырышып карыйк әле.

Мамай мирза әле яңа гына Габдулла хан белән Сарайны ташлап китсә дә, ул дәүләтнең мәркәзенә әйләнеп кайтып, төп тәхеткә янә үз ханын утырту уеннан һич тә баш тартмый. Тарихи фактлар һәм вакыйгалар барышы нәкъ шуны күрсәтә. Гайрәтле татар мирзасы Сарай өчен көрәшүен дәвам иттерә. Бу көрәштә ул үз артында торган Кырымга һәм Кара диңгез буе, Азак-Дон далаларына таяна.

Килдебәк ханнан соң әмирләр Морат (кайбер чыганакларда Мөрит) дигән берәүне хан итеп күтәрәләр. Тик аны Сарай шәһәре һәм аның тирә-юнендәге беркадәре җирләр генә таный. Мамай мирза бу вакытта Иделнең уңъяк ярында урнаша. Ул Иделдән дала эченә ерак китмәгәндер, чөнки аңа Морат хан белән көрәш алып бару өчен Сарайдагы хәлләрне белешеп торырга, астыртын эш йөртергә, уңай чак туры килсә, кинәт һөҗүм оештырырга кирәк булган. Ә көчне, гаскәрне ул, әйткәнебезчә, артында җәелеп яткан Кыпчак даласыннан һәм Кырым ярларындагы шәһәрләрдән алган. Анда Италиянең Генуя шәһәреннән чыккан бай сәүдәгәрләр бик күп була. Мамай мирза үз эшчәнлегендә аларга да таяна, чөнки гаскәргә түләр өчен акчаны шулардан ала.

Дөресен әйткәндә, бу вакытта дәүләт башкаласы Сарай шәһәре дә, диңгездәге утрау кебек, ялгызы утырып кала. Башкалада ханнарның туктаусыз алышынып торуы аркасында илдә тәртип тәмам бетә һәм зур дәүләтнең олыслары, Сарайдан аерылып, башка чыккан гаилә сыман, мөстәкыйль яши башлыйлар. Шулай итеп, Иделнең урта агымында Болгар белән Нарувчат, аскы агымында Хаҗитархан (Әстерхан), Җаек (Урал) елгасы буенда Сарайчык, көньякта Харәзем олыс-
лары мөстәкыйль тормыш алы
бара. Сыр-Дәрья буендагы Күк У
даның да Сарай ханнарына ин
күптән исе китми. Дөнья тәмам б
лганып, таркалу барган бер чор
Мамай мирза Иделдән көнбаты
ка таба сузылган Кыпчак даласы
ның тулы хокуклы хуҗасына әве
лә.

1360 елда Сарай өчен башланы
киткән аяусыз көрәш 1362 елда
дәвам итә. Көрәш барышын
өстенлек әле бер партиягә, әле ик
нчесенә күчә. Урыс елъязмасын
бу хакта шундый сүзләр теркәл
калган: «Ул чакта Идел буе па
шалыгында ике падишаһ бар и
— Мамай урдасы хакиме Авду
(Габдулла хан), ә икенче хак
— Амурат (Морат хан) белән С
рай кенәзләре. Бу ике патша һ
бер-берсенә каршы торучы ике у
да һәрвакыт дошманлык саклад
лар һәм үзара сугышып торд
лар», — диелә анда. Шунысы к
зык: көрәш барышында һәр
лагерена өстәмә көчләрне җә
итәргә омтыла. Бу очракта с
урыс кенәзлекләре хакында бар
Габдулла хан исеменнән Мам
мирза да, Сарайда утырган Мор
хан да урыс кенәзләренә ярлык
бирәләр, аларны үз якларына та
тырга, көрәштә үз аркадашы-сою
нигы итәргә тырышалар. Хәт
бер үк кенәзлеккә ике кешене б
рьюлы кенәз итеп билгеләү очра
лары да булгалый. Бу хәлгә тата
ның бөек мәгърифәтчесе, тарихч
Ризаэтдин Фәхретдин дә үзен
«Алтын Урда ханнары» исемле хе
мәтендә игътибар итә. Дөрес,
моңа илдә тәртип бетүнең бер м
салы итеп кенә карый.

1363 елда Морат хан да өлк
әмире Ильяс тарафыннан бәреп т
шерелә. Аннан соң Сарай
бер-бер артлы Булатхуҗа (136
аның улы Газизшәех ханн
(1364-1367) хакимлек итә. Газиз
ехтән соң Сарай тәхетенә кабат
бдулла ханның чыгуы безгә чы
накларда чагылмый калган күп в
кыйгаларның эчке механизмын а
ларга ярдәм итә. Димәк, бу вак
та Мамай мирза да кул кушыр
утырмаган, тарафдарларын үз т
рәсенә туплый алган һәм нәтиҗ
Сарай тәхетенә кабат Габд
ханны утыртуга ирешкән. Ләк
бер болганса, су да тынмый, диг
дәй, еш үзгәреп торган вазгыя
аркасында тагын бер елдан (13
Габдулла хан кабат тәхеттән ко
кала. Бу инде Мамай мирза тара
дарларының җиңелүен, башка па
тиянең өстен чыгуын күрсәтә.

Чыннан да, бу юлы Сарай ш
һәре Хаҗи Чиркәс хан кулына т
шә. Чыганаклардан аның монар
Хаҗитархан хакиме булуы билге
Күренә ки, бу вакытта үзен Ба
Үзбәк ханнардан калган асыл тә
ткә лаеклы санаучылар җитәрл
булган. Шунысын да әйтергә кир
Хаҗи Чиркәс белән беррәттән Х
сән дигән берәү дә Мамай мирз
каршы көрәш башлый. Бу бәре
шләрдә Хәсән җиңеп чыга һәм
хеткә утыра. Әйткәнебезчә, әл
вакыйгаларны тарихчылар 1368
белән билгели.

Бу очракта Хәсән хан турын
киңрәк сөйләү дә үзен аклар
уйлыйм. Эш шунда, әлеге затн
эшчәнлеге турыдан-туры Казан
нлыгы тарихы белән бәйле. Күп
түгел әдәбиятчы һәм тарихчы М
сель Әхмәтҗанов борынгы шә
рәләр, сугылган тәңкәләргә ни
ләнеп, 1368 елда Сарай тәхет
утырган Хәсән ханның Казан х
лыгына «нигез салучы» Олы М
хәммәт ханның атасы булуын а
клады. Урыс елъязмалары бу
тны «болгар кенәзе» дип кенә
алалар. Чыннан да, тагын бер
дан (1369) Хәсән хан фетнәче
оясына әверелгән Сарай шәһәр
нән качып китә дә, Болгар олы
ның мөстәкыйльлеген торгыз
шунда идарә итә башлый. Әл
факт күп нәрсә хакында сөйли.
мәк, әле Олы Мөхәммәт хан Ка
ханлыгына «нигез салганчы»
(1437 елда) Алтын Урда татарла
Болгар олысында идарә иткән
Ә Олы Мөхәммәт ханның үз
килгәндә, ул да башта 17 ел да
мында Сарай ханы була, хәл
катлауланып китү аркасында г
аннан китә һәм соңгы 8 ел гоме
Казан тәхетендә үткәрә. Мон
без Казан ханлыгын оештыру
аны дәүләт буларак яңа баскы
күтәрүчеләрнең татарлар ик
күрәбез. Шул сәбәпле, Казан
лыгын Алтын Урда дәүләтен
аерып карау һич тә мөмкин түг
Бу ике дәүләт арасында туган
җепләре, дәвамлылык гаять
булган. Казан ханлыгына «н
салучы» Олы Мөхәммәт хан
нрак бары тик атасы тәхетенә
утырган (1437).

(Ахыры киләсе санда).

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ № 1 (24)

Сабыйлар җыруы

...аз канатлары ак булыр,
...р канатлары ат булыр;
Сабыйларның
канатланыр вакты
...әплләрдә
укыр чак булыр.

Габдулла ТУКАЙ.

Телең
белән узма,
белемең
белән уз.

Телең белән
күңелеңне
бер тот.

...хифәбездә:

...туган тел...»гә
...р-фатиха бирик!

...ан телне гамәлгә
...ырырга төпле
...сәт кирәк.

...лык рейды дәвам итә:
...м язулары
...ан төзәтелер!?

...мологик табышлар.

МӨХӘРРИР ФИКЕРЕ

Юлыбызга ак җәймә

Хөрмәтле укучыларыбыз, исәнмесез! Кулыгызда «Мәдәни җомга»ның яңа бер сәхифәсе — «И туган тел...». Кайбер укучыларыбызга ул, мөгаен, таныштыр да, ә кайберәүләрегез әле беренче тапкыр күрәдер. «И туган тел...» моңарчы (1993 елның сентябрь аеннан) «Татарстан хәбәрләре» газетасының айлык кушымтасы булып чыгып килде. Ул газета ябылу сәбәпле, без «И туган тел...»нең даими укучыларына да саубуллашу сүзе белән мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган идек. («ТХ», 1995 ел, 16 июнь). Анда без сәхифәнең кыска гына тарихын, тоткан кыйбласын тәфсилләбрәк сөйләгән идек. Шул ук вакытта без җәмәгатьчелектә шактый кызыксыну тудырып өлгергән бу сәхифә бөтенләй югалмас, дәвамлы булыр, дип өметләнеп калган идек.

Шөкер, юраганыбыз юш килде — бу юлы безне үз канаты астына «Мәдәни җомга» алды. Рәхмәт аңа! Сәхифәбез аның укучыларына да кызыклы, файдалы булсын дип тырышачакбыз. Моның өчен аның элекке авторлары, укучылары белән берлектә азмы-күпме тупланган тәҗрибәсе, иҗади эзләнүләре дә ярдәм итәр дип өметләнәбез. Яңа укучыларыбыз арасында да сәхифәнең даими авторлары — тугры дуслары аз булмас дип өметләнәбез.

Сәхифәбезнең төп кыйбласы, әлбәттә инде, ана телебезгә хөрмәт тәрбияләү, аны белергә, кулланырга омтылышны җанландырып, үстереп, дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү өчен барчабызның эшчәнлеген көчәйтү, туган телебезнең асыл сыйфатларын, төп кагыйдәләрен, куллану үзенчәлекләрен төшендергән сабаклар бирү, аның тарихы белән кызыксыну уяту, тел сәясәтенең төрле процесслары белән таныштыра барып, шул хәрәкәттә катнашуны көчәйтү.

Туган телебезне кайгырту, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү ул — һәркайсыбызның, барыбызның да уртак бурычы, изге эшедер. Яшьләребезгә, киләчәк буыннарга мирас булып ул күктән әзер килеш төшмәс, аны безгә читтән китереп кертмәсләр, һәркайсыбыз үз өендә, эш урынында үз үрнәгебездә кайгыртсак кына, ул, җирен эшкәртеп, ашлап, суын сибеп, корткычларыннан арындырып, хәстәрләп үстергән агачта өлгерткән татлы җимеш кебек, тырышлык нәтиҗәсендә генә ирешелгән казаныш булыр.

Бу изге, җаваплы эштә «И туган тел...» дә, сезнең даими булышлыгыгыз белән, кадерле укучыларыбыз, үзеннән лаеклы өлеш кертер дип өметләнәбез.

Телсез калмыйк, дисәк...

Июнь аенда, Сабан туе көннәрендә, Казанда журналистларның «Милли журналистика һәм татар язмышы» дигән темага халыкара семинары булды. Татарстан Республикасы Президенты аппараты, Татарстан Министрлар Кабинеты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты һәм башка җитәкче оешмалар әзерләп үткәргән бу җыенда Татарстаннан тыш илләрдә, республика, өлкәләрдә татарча чыга торган газеталарда, радио, телевидение тапшыруларында эшләүче күп кенә журналист һәм җәмәгать эшлеклесе катнашты.

Җыенда каләм ияләренең үзләрен, аннан да бигрәк, бөтен милләтне борчыган төрледән-төрле мәсьәләләр кузгатылды, җанлы, кызыклы очрашу, әңгәмәләр булды, эшлекле карарлар кабул ителде, Бөтентатар журналистлар бергәлеге оештырылды.

Хәер, болар турында инде матбугатта хәбәр ителде. Мин исә семинарда җитди итеп кузгатылмыйча калган бер мәсьәләгә тукталмакчы булам.

Ана телебез — татар матбугатының бердәнбер коралы, аны төпле белгәндә, чарлап торганда гына фикереңне, укучыга тәэсир итәрлек итеп җиткереп була. Шуңа күрә матбугат әһелләренең, шул җөмләдән радио, телевидение журналистларының да бүгенге шартларда туган тел белән эш итү үзенчәлекләре — үзе зур бер мәсьәлә, үзе җитди бер сөйләшүгә лаек. Моннан берничә ел элек үткәрелгән шундый беренче семинарда бу хакта сүз күбрәк булып, махсус күзәтү-доклад та тыңланган иде. Кызганыч ки, семинарның монысында, гәрчә моңа ихтыяҗ үскән булуы журналистларның үзләренең тел төбеннән дә сизелеп-сизелеп китсә дә, тиешле сөйләшү булмады.

Чыннан да, татар теле язмышы, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү мәсьәләсе татар матбугатының даими темаларыннан берсенә әверелде. Дөрес, моңарчы шулай булган иде. Соңгы унъеллыкта татар матбугатының асыл үзенчәлекләрен билгеләгәндә тарихчылар, мөгаен, шушы фактны да читтә калдырмас. Тел язмышын кайгырту мөстәкыйльлек өчен, дәүләтчелек өчен көрәш белән бергә үрелеп барды. Бу — табигый, канунлы күренеш иде, чөнки милли үзаңны үстерү, мөстәкыйльлеккә ирешү, дәүләтчелекне торгызу бурычлары туган телнең дәрәҗәсен күтәреп һәм үстереп, язмышын кайгыртып, аңлату-төшендерү эшләрен ана телендә, беренче нәүбәттә матбугатта, радио, телевидениедә, алып барып кына хәл итеп була иде.

Ул вакыттагы тырышлыгыбыз, ялкынлы сүзебез нәтиҗәсез дә калмады: татар теле башта Декларациядә, аннары Конституциябездә дәүләт теле буларак рәсмиләштерелде, Телләр турында закон һәм Дәүләт программасы кабул ителде, мәгариф, матбугат өлкәсендә берникадәр яңалыкларыбыз, эшләгән эшләребез калды.

Шулай да, бик тә кызганыч ки, тел язмышы өчен борчылу, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә үстерү өчен эшлекле чаралар күрү соңгы вакытта нык сүлпәнләнде.

Дөрес, бу тема матбугатта бөтенләй үк сүнеп бетмәгән. «Ватаным Татарстан», «Татар иле», «Татарстан» журналы, Татарстан радиосы, өлкә газеталарыннан «Өмет», «Бердәмлек», «Туган як» даими рубрикаларын дәвам иттерәләр. Әмма «бу теманың үткенлегеп, колачын үстерә барабыз, яңадан-яңа ачышлар ясыйбыз», дип бүген кем генә тәҗрибә уртаклашырга алынып икән?!

Нигә сүлпәнләндек? Сәбәпләре аз түгелдер. Шулай да төп сәбәпләрнең берсе, минемчә, матбугатның үзенең мөстәкыйль тел сәясәте булмавында. Хәер, дәүләтебездә, хөкүмәтебездә, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетында да мондый сәясәт булмагач, матбугатыбызга ул каян килсен!

Тел сәясәте дигәндә, без, беренче чиратта, телне саклау, үстерү, өйрәтүнең, аны кайгыртуның республикабызда гамәлгә ашырылырга тиешле бер тәртибен, системасын, шул системаны тормышка ашыру алымнарын һәм юлларын күз алдында тотабыз. Бармы бездә бүген тел сәясәте, туган телебезне дәүләт теле дәрәҗәсенә үстерү өчен бөтен халыкны, шул җөмләдән матбугатны да җәлеп итә торган эш, хәрәкәт системасы?

Мәгълүм ки, мондый системаның нигезен, асылын ихтыяҗ хасил итә. Җәмәгать ихтыяҗы. Ихтыяҗ нинди — система шундый. Моңарчыгы их-

(Ахыры 12 нче биттә).

Әхмәт РӘШИТ

Бишек җыры

Әллү-бәллү, чәчәгем,
Бәллүр мәллә бишегең?
Йоклачы эреп кенә,
Матур төш күреп кенә.

Төшеңдә дә янында
Булыр әти-әнием,
Иң-иң тәти курчагың,
Иң-иң тәмле мәмиең.

Әй ак кынам, пакь кынам,
Тыныч йокла, нәнием.
Уянмады микән, дип
Борчылмасын әниең.

Чулпан йолдыз таңгача
Бишегеңне тирбәтер,
Фәрештәләр җыелып
Тел ачкычы өйрәтер.

Иртән сине ал кояш
Назлый-назлый уятыр.
Сөя-сөя һәммәсе
Иң-иң иркә сүз әйтер.

Мин дә назлап сөярмен,
Шатлыгым син, диярмен,
Бәхетле бул, дәү үс, дип
Изге теләк теләрмен.

МӘДӘНИ ҖОМГА

Телсез калмыйк, дисәк...

(Ахыры. Башы 11 нче биттә).

тыяҗ халыкның бик акыллы бер гыйбарәсендә берегеп калды: татар теле капкадан чыккач кемгә кирәк, ягъни ул — инегалды теле, кухня теле. Һич кимсетү түгел: әлегәчә тел өлкәсендәге фәнни эзләнүләр дә, мәктәптә, югары уку йортларында телне укыту да һәм башка эшчәнлек тә менә шушы ихтыяҗны канәгатьләндерү максатыннан әллә ни ары китә алмый иде. Үзегез уйлап карагыз, төп һөнәрендә татар телен кулланып эш итәргә тиешле югары белемле кеше ул бүген бары тик укытучы гына. Анда да татар теле һәм әдәбияты укытучысы гына. Янә дә берничә йөз журналист, артист, язучы... Ана теленә бөтен ихтыяҗ менә шул дәрәҗәдә! Унберенче сыйныфка кадәр ана телендә алган белемен бүген безнең яшьләр шушы һөнәрләрне өйрәнер өчен генә файдалана ала.

Бик тә аяныч ки, урта мәктәпне тәмамлаучыларның телне белү дәрәҗәсе гадәттә шушы һөнәрләрне юньле-башлы өйрәнер өчен дә канәгатьләнерлек түгел.

Май азагында «Техник югары уку йортларында татарча укыту проблемалары» дигән темага фәнни-методик конференция булып узды. Сөенегез, ата-ана: кайбер югары уку йортларында татарча укытуга күчәргә әзерлек бара. Әмма уйланыгыз да: күпчелегендә укытучылар борчуга калган — керергә теләүче укучыларның татарча белем дәрәҗәсе бик түбән.

Укытучылар бу хәлнең сәбәбен гадәттә аз комплекслы мәктәпләрнең бик күбәюеннән дип аңлаталар. Шулай да төп сәбәпләрнең берсе — безнең урта мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында татар телен укыту, татарча белем бирү системасының нык искерүендә. Татар теле дәүләт теле булганда аны куллану чикләре нык киңәячәк, даирәсе күпкә үсәчәк бит. Димәк, телне өйрәнү системасы да тамырдан үзгәрергә тиеш. Без әле асылда телнең төзелешен өйрәнәбез, аны сөйләм оештыру максатында куллануга җитәрлек игътибар бирмибез. Японнар, әйтик, тел структурасына телгә өйрәтүгә бирелә торган вакыт, чыгымнарның 15 процентын бирә, ягъни бала аны өйрәнүне бишенче сыйныфта тәмамлый да, калган уку чорында (югары мәктәптә дә) шуны тормышта, үз эшендә ничек куллануга өйрәнүгә бирә.

Әлбәттә, заман таләбен, туа башлаган ихтыяҗны алдан сизеп, милләт каршында җаваплылык тоеп, берникадәр алга карый алган энтузиаст шәхесләр, алдынгы коллективлар да юк түгел. Алар уку программаларына үзгәрешләр кертү, яңа кыйблаларга юнәлеш тоту ягында тора. Тик болар әле асылда очраклы туган, нык каршылыклар белән тартышта борынланган бөреләр генә, һич тә яңа системаның, яңа сәясәтнең нәтиҗәсе түгел. Юк әле бездә андый сәясәт. Мондый гамьсезлекнең кәсафәте дә безне читләтеп үтмәс — ихтыяҗның, аңа бәрабәр системаның үзеннән-үзе тууын көтеп ятсак, без янә бик нык артта калган булырбыз.

Төшенәсездер: тел системасы димичә, тел сәясәте диюнең үзенчә мәгънәсе бар. Система ул инде урнашкан, береккән, мәгълүм кысалар белән чикләнгән хәрәкәт тәртибе, ә сәясәт ул — алга да карый алырга сәләтле, көн, заман таләпләренә карап үзгәрә ала торган сыгылмалы хәрәкәт тәртибе. «Безнең бит узган ел гына Югары Совет кабул иткән Дәүләт программасы бар, шуны эзлекле үтәү дөрес сәясәт түгелмени?» диючеләр булыр. Әлбәттә, Дәүләт программасы мәгълүм бер күчеш чорында тел сәясәтен гамәлгә ашыру өчен нигез була ала. Тик бу программабыз, күпләр тарафыннан урынлы тәнкыйть ителгәнчә, соңлап, өстәвенә әле җитлекмичә барлыкка килде. Бүгенгә ул эзлекле, фәнни нигезләнгән система булудан шактый ерак тора. Бер генә мисал китерим. Программада урта мәктәптә татарча белем бирү (алу) өчен җитди генә чаралар күрелгән бервакытта, югары уку йортына килгәндә, анда «югары уку йортларында татарча укытуга күчүнең перспектив планын төзергә», диелгән. Бүген татар мәктәп-гимназияләре, начармы-яхшымы, меңнәрчә укучыны татарча укытып чыгара, ә аларга югары белем алу мөмкинлеге әле «перспективада» гына каралган. Шушы да булдымы сәясәт өчен фәнни нигез! Димәк ки, тел сәясәтен программаның үзен яңартудан, камилләштерүдән башлап җибәрергә кирәк.

Тел сәясәте өчен иң беренче чиратта татар теленең дә дәүләт теле итеп гамәлгә ашырылуының Татарстан Конституциясендә билгеләнгән гарантлары — Президент, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты җаваплы. Төпле, ышанычлы сәясәткә нигез салу, аны эзлекле гамәлгә ашыру татар матбугатының да милләт алдындагы иң зур, иң җаваплы бурычыдыр. Моны аңлау гына түгел, күңелгә сеңдерергә дә бик вакыттыр. Тел сәясәте булмаса, ул гамәлгә ашырылмаса, татар матбугатының үзенең дә, һәр журналистның да язмышы кыл өстендә кала лабаса.

Тел сәясәте бер-берсеннән аерылгысыз ике юнәлештә барырга тиештер. Беренчесе, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсендә җитлегүенең назари (теоретик) шартларын, фәнни нигезләрен барлау, ачыклау булса, икенчесе, Телләр турындагы законны, Дәүләт программасын үтәү өчен гамәли эшчәнлекне җайга салудыр. Ике юнәлеш тә матбугат өчен бер дигән иҗат мәйданы. Бүгенге ваемсыз тынычлануыбыз бик кыйммәткә төшмәсен иде! Шушы юнәлешләрдә сүздән эшкә күчмичә, җигелеп тартмыйча торып, татар теленә ихтыяҗ үзеннән-үзе туар дип өметләнү — мәгънәсезлек.

Ярар, тел сәясәте өчен турыдан-туры җаваплы Дәүләт Советы әлегә үзенең оешу мәшәкатьләрен кичерә ди, аның каравы, Министрлар Кабинеты бу өлкәдәге вазифасын икеләтә җаваплылык белән үтәргә тиеш иде. Кая ул! Нәкъ бер ел элек аның каршында Телләр турындагы законны һәм Дәүләт программасын үтәүне оештыру һәм контрольдә тоту максатында телләрне гамәлгә ашыру комитеты оештырылган иде.

Юк шул, барып чыкмады... Октябрь аенда комитетның бер утырышы булды да, шуның белән вәссәлам... Хәзер үзе дә күренми, эше дә юк дәрәҗәсендә. Ә бит шулай килеп чыгары баштук билгеле иде — комитет җәмәгать тәртибендә эшләргә тиеш, диделәр, ә андый «ясалмалылыкка» корылган «курчак» комитетлар элек тә юньле-башлы эш күрсәтмәде.

Ләкин быелгы семинар барышында да Татарстан журналистлары бу хакта чаң сукмадылар, министрларның күптән мәгълүм озын-озын хисапларын гамьсез генә тыңладылар. Телләр турында законның, программаның үтәлмәвенә борчылып, җитәкчеләрне кайбер сораулар биреп «бимазалаган» журналистларның күпчелеге Татарстаннан читтә эшләүчеләр иде.

Әлбәттә инде, канәгатьләнерлек җавап күп булмады. Гади генә фәнни-теоретик һәм гамәли сораулар да ачыкланмыйча кителде. Мәсәлән, кайбер татар газеталары татар текстлары белән аралаштырып урысчаны да баса. Моны гадәткә кертеп барган газеталар да бар. Мөхәррирләр әйтүенчә, янәсе, «җитдирәк» материалларга урыс телле укучыларның да игътибарын юнәлтәләр. Димәк, татарча материалның «җитдилеге», әһәмияте шуның кадәр генә булып чыга!

Мондый сорау туганда, һәрвакыт укучы ягына басарга, аның ихтыяҗын якларга кирәк — урысча укырга теләге булса, ул урысча газета алдырган булыр иде, — алар буа буарлык, — ә ул татарча газетага хөрмәт күрсәтеп, аннан тәм, файда алырга өметләнеп, татарчаны (тулаем татарчаны, ә ярым-йорты татарчаны түгел) алдырырга карар иткән. Кермәгез аның өлешенә, кискәләмәгез хокукын!

Бу — татар газеталарында реклама мәсьәләсенә дә карый. Мин, әйтик, «Татарстан яшьләре»н урысча реклама укыр өчен аламмыни инде, йә! Уч төбе хәтле газетага вакыт-вакыт урысча реклама тутыралар. Иң башта, туган телең өчен гарьлек: ни өчен реклама бирүче байлар татар телен дә урыс теле белән бердәй дәүләт теле дип танымыйлар, аның дәрәҗәсен бөтен республика алдында төшерәләр яисә комсызлыкларын куып, текстны урысча гына әзерлиләр, ә татар газетасы, шуларның ертык тәңкәләренә һушы китеп туган телне тибәрергә, үзе дә сизмичә укучысын да сатарга, рәнҗетергә риза.

Бу да, әлегә дә баягы, бездә тел сәясәте булмаудан килә. Милләт өчен, аның теле, мөстәкыйльлеге өчен горурлык тәрбияләү дә бу сәясәтнең максатын тәшкил итәргә тиештер. Шундый горурлык җитмәүгә адым саен юлыгып торабыз. Урамдагы элмә язулардагы хаталар турында күпме тукырга була?! Хатасыз бер генә язу да юк. Матбугатның үзен дә хата басты. Компьютерда җыябыз дигән булып, кайбер газета-журналлар татар аңында гадәт-традиция булып береккән кагыйдәләрне дә ватып-җимереп бетерделәр (мин, әйтик, юлдан-юлга дөрес күчермәсләр дип куркып, «күтәрү» һ.б. сүзләрне язудан тыелам); ике дикторның берсе татар сөйләменең сингармонизм, басым кануннарын белми; татар теле укытучылары, тәрбиячеләр, мәгариф, матбугат, мәдәният министрлыклары хезмәткәрләре, аларның урыннардагы бүлекләре хезмәткәрләре, халыкка үрнәк күрсәтәсе урында, «гибрид» телдә аралашуны гадәткә алдылар шикелле: татар теле һәм әдәбияты буенча республика олимпиадасында районнардан җиңеп килгән укучыларның да язма эшләрендә быел да хаталар хәтсез иде.

Шул ук вакытта дәүләт теленең икенчесендә (әллә беренчесендәме!?) мондый тәртипсезлеккә, җавапсызлыкка юл куелмый. Хәтерлисездер, узган ел бер сессия барышында Югары Совет Рәисе урысча бер сүздә басымны төгәл ясамаган иде, бөтен Татарстан шау килде, Рәисебез кимчелеген танырга, гафу үтенергә мәҗбүр булды. Күптән түгел Мәскәүдә Татарстан мәдәният көннәрендә «Московский комсомолец» газетасы татар спектакле атамасында һәм бер фамилиядә хата җибәргән иде, моңа радио да, матбугат та игътибар итте. «Төзәтүчеләр» урыс телле татар кешеләре иде. Менә бит ничек: урыс матбугатында, урыс сөйләмендә хата булмасын дип татар зыялысы да кайгырта (бик дөрес эшли!), ә менә татар матбугатында, татар язуларында хата тулып ятуга шул ук татар зыялысы битараф.

Җәмәгатьчелек йокыда булгач, җитәкчеләргә, түрәләргә дә тел сәясәте дип борчыласы юк. «И туган тел...» сәхифәсе Казан урамнары буйлап ике ел буе рейд үткәреп, алардагы язулардагы хаталар турында язып килде, хәтта Казан администрациясе башлыгы Камил Исхаковка махсус мөрәҗәгать хаты язарга мәҗбүр булды. Әлегә кадәр бер кәлимә җавап алынганы юк. Хәер, кабатлап әйтәбез, матбугат сигналларына хөкүмәт башлыкларыннан, Президентның үзеннән дә халыкка матбугат аша җавап бирү очраклары сирәгәйде. Әйтик, җәмәгатьчелек хөкүмәттән, Президенттан тел мәсьәләләрен яктыртырга тиешле берәр басма булдыруны үтенеп ничәләр тапкыр мөрәҗәгать итмәгәннәр. Урыс теле мәнфәгатьләрен кайгыртып торучы басмаларның саны дистәгә җитә.

Бездә исә, ике сүзнең берендә, «акча» дип авызны каплыйлар. Икътисад хәле бездә беркайчан да рухи ихтыяҗны канәгатьләндерерлек булмады, без гел «калдык» белән генә туенып гомер иттек. Шуңа күрә бүгенгедәй әхлакый түбәнлеккә төшеп җиттек тә. Җаны, рухы сәламәт булмаган тән барыбер сәламәт яңа матди байлыклар тудыра алмый. Икесен бер дәрәҗәдә кайгыртырга кирәк. Алай-болай бер җәбе артка кала икән, шунысын өстенлекле кайгыртырга кирәктер. 20 нче елларда татарларның Казан ханлыгы бетерелгәннән соң беренче дәүләте — автономияле республикасы оешкач та телне гамәлгә ашыру комиссиясе төзелә, аның да башлыгы итеп хөкүмәт җитәкчесе билгеләнә. Хөкүмәтнең атна саен үткәрелә торган утырышларында беренче көн тәртибе итеп телне гамәлгә кую мәсьәләләрен карауны гадәткә кертеп җибәрәләр. Архив документларын өйрәнгәндә, шушы гадәттән читенгән бер генә очракка юлыктым. Ул да булса 1922 елда. Идел буенда ачлыкның иң котырган чагында. Чистай өязеннән ачлыктан кеше ашау очрагы турында хәбәр алынгач, хөкүмәт бу «икътисадый» хәлне беренче булып карарга мәҗбүр була.

Андый тәртипләрнең нәтиҗәсе ничек булган соң, дип төрттерүчеләр дә бар. Әлбәттә, андый тәртипләрне куралмаучылар, башында ук томаларга, буарга омтылучылар ул чагында да булган. Бөекдержавачылар арасында гына түгел, татарларның үзләре арасында да аз булмаган андыйлар. Нишләмәк кирәк, яңа тел сәясәтенә каршы үз сәясәтен тотучылар көчлерәк булып чыккан. Бүген шунысы мөһим, тарих безгә андый факт, вакыйгаларны сабак, гыйбрәт алыр өчен дә, хаталарны кабатламас өчен дә калдырган. Белеп торыйк, үзебез тел сәясәтен булдырмыйбыз икән, аңа ябышып ятмыйбыз икән, телне кысу, изү сәясәте һичшиксез барлыкка киләчәк һәм өстенлек итәчәк. Аннары моңарчы ирешелгәннәрдән дә колак какмагаек...

Илдар НИЗАМОВ,
КДУ доценты.

Мирсәй ӘМИР

БЕЗ БӘЛӘКӘЙ ЧАКЛАРДА

Театр шаукымы балалар арасына да килеп кергән иде. «Җанвар» дигән пьесага тотындык. Бу әсәрнең Гали Рәхим иҗаты булганлыгын еллар үткәч кенә белдем. Идея эчтәлеге белән яңа заман рухына туры килә иде-ме-юкмы, мәсьәләнең бу ягы турында уйлый белми идек әле. Китап табуы да җиңел булмагандыр. Табылган кадәресендә исә кызыклы вакыйгалар, кызыклы кешеләр, тапкыр сүзләр булса, безгә шул җитә иде. «Җанвар»ның төп герое — Казандагы бер сәүдәгәр гаиләсенә кайдандыр — Төркиядәнме, Юһаннамы кайткан бер егет. Ул ирекле рухта тәрбия алган, күңелендәге уйларын кеше алдында кычкырып әйтергә дә тартынмый, теләгәнен эшләргә оялмый торган табигать сөючән кеше. Казандагы йолалар, шәригать кануннары белән кысылып яшәгән гаилә кызлары каршында аның ирекле кыланышлары бик сәер һәм кызык күренә. Шул нигездә килеп чыккан маҗаралар, аңлашылмаулар безгә ошады.

Шушы спектакльгә бәйле ике момент хәтеремдә. Беренчесе — без ул китапның бик күп сүзләрен аңламадык. Җөмләдән берсе. Кунак егет Җанвар аш өстәлендә зәйтүн җимеше күрә дә аны алып ашый башлый. Кызлар моңа гаҗәпләнә, һәм берсе әйтә: бездә аны болай ашамыйлар, соуска гына салалар, ди. Арабызда менә шул «соус» дигән сүзнең мәгънәсен аңлаучы булмады. Мөгаллим-мөгаллимәләребез дә ул сүзне аңлау дәрәҗәсенә үк күтәрелмәгән булганнар, күрәсең. Бернинди дә мәгънә бирә алмагач, без бу хәреф хатасы булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килдек, янәсе, «савыт» диясе урында ялгыш «савыс» дип (гарәп хәрефе белән язганда шулай укыла) басканнар булса кирәк. Һәм шулай дип «төзәтеп», «Бездә аны савытка гына салалар» дип уйнадык та. Уйнавын уйнадык, ләкин күңелемдә бер төер калды: белеп төзәттекме икән? Савытка гына сала торган нинди зәйтүн соң ул? Шундый, савытка салыр өчен генә тотыла торган җимеш тә була микәнни?..

Еллар үтеп, соусның нәрсә икәнен белгәч кенә ул төер йомшарып, шушындый мәзәк истәлеккә әверелде...

* * *

Сәнаигы нәфисә түгәрәгенә йөрүнең тагын да күңеллерәк ягы — һәр репетициядән яки утырыштан соң милли уеннар була иде. Ни өчен милли? Шушы көнгә кадәр аңлап җитә алганым юк. Авылыбызда моңарчы бөтенләй булмаган, безнең өчен яңа уеннар иде алар. Мәсәлән, «Римски папа» дигән уен.

Рим папасының кем булганын түгел, аның ни дигән сүз икәнен дә белми идем әле. Исеме шундый сәер булса да, аның эчтәлеге безгә ят түгел, гади әйлән-бәйлән уены кебек иде. Кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйбыз да бер кешене уртада калдырып, җырлый-җырлый әйләнәбез. Уртада калган кеше «Римски папа» исәпләнә. Җыр тәмамланып, түгәрәк әйләнүдән туктагач, ул теләгән кешесен чакырып ала да аңа наказ бирә. Я җырларга куша, я биергә яки берәр нәрсә сөйләргә, я якын күргән кешесе белән күрешергә, бик зурга китсә, яраткан кешесен үбәргә куша. Аннары «папа» наказын үтәгән кеше үзе «папа» булып уртада кала да, уен элеккечә дәвам итә.

«Бозык телефон», «Почта», «Күрше...» нинди-нинди генә «милли» уеннар уйналмый иде ул көннәрдә.

«Мәхәббәт почтасы» бар иде әле. Аны гадәттә түгәрәкнең өлкәнрәк әгъзалары үзләре генә калган чакта уйнарга яраталар иде. Мәрьям апаның янсакчысы буларак, миңа да күрергә һәм катнашырга насыйп булды. Мин үсеп, чын мәгънәсендә комсомол булып киткән елларда яшьләр арасында бу уен юк иде инде. Мещанлык печате сугылып, гамәлдән чыгарылган иде.

Ләкин яшьләр өчен әйбәт уен булган икән ул. Мәдәни, интеллигентный уен. Ул безгә рус теле аша үтеп, Европадан килеп кергән булырга тиеш. Чамача гади открытка зурлыгында киселгән кәгазь карточкалар. Алар күп. Һәркайсына номерлар урынына чәчәк исемнәре язылган: сирень, чалма-гөл, ясмин, лалә, ромашка һ.б. Һәр исем янында бер җөмлә. Алар күбесенчә төрле популяр шигырьләрдән яки башка жанрдагы әдәби әсәрләрдән сайлап алынган фразалар, афоризмнар. Матур-матур мәкальләр дә бар. Шулар арасыннан берәр кызга яки егеткә әйтәсе килгән сүзне табып аласың да, шул сүз турысына язылган чәчәк исемен генә атап, теләгән кешеңә бирәсең. Соравыңа яки тәкъдимеңә җавап булырлык гыйбарә шул карточкадан ук табылырга мөмкин. Юк икән, бүтәннәреннән эзләп таба һәм чәчәк исемен генә атап, сиңа җавап кайтара. Китә ике арада шигъри образлар теле, матур кинаяләр белән сөйләшү. Мәхәббәт турында гына түгел, башка мәсьәләләр турында да фикер алышып яки бик кызу бәхәсләшеп утырырга мөмкин. Җаныңа рәхәт табу белән бергә, никадәр гүзәл шигъри гыйбарәләр, мәгънәле афоризмнар керeп кала күңелеңә! Рухи байыйсың. Әдәпле сөйләшергә гадәтләнәсең. Тик ул карточкалар бай эрудицияле, яхшы зәвыклы автор тарафыннан төзелгән генә булсын. Кем иҗаты булгандыр, без күргән кадәресе әйбәт иде сыман. Иң күп урын Тукай, Сәгыйт Рәмиев кебек зур шагыйрьләргә бирелгән иде анда...

«Мәхәббәт почтасы»ның тагын бер әйбәт ягы — бу уеннан артык оялчан, кыюсыз кеше дә читтә кала алмый. Без яшь чакта бик мөһим мәсьәлә иде бу. Хәзерге яшьләр өчен бусы бәлки әһәмиятсездер?.. Ай-һай, шулаймы икән?.. Халкы миллионлап саналган шәһәрдә яшәүчеләр арасында да үзенә иш таба алмыйча, яки рәтләп ял итә дә белмичә, ялгызлыктан каңгырып йөрүче кызлар, егетләр юкмыни?

Яңалыклар

Файдалы өстәмә

Татарстан радиосының якшәмбе саен яңгырый торган «Хәерле иртә» тапшыруларының берсе (16 июль) халкыбызның Габдулла Тукай шигыренә җырлана торган «Туган тел» җыры белән башланып китте. Шуннан соң тапшыруның әллә ни озын булмаган бер өлеше туган телебезнең җитди мәсьәләләрен кузгатты. Вил Казыйхановның «И родной тел...» шигырен тыңлап, ана телләрен ярым-йорты гына белгән яисә бөтенләй белмәгән яшьләр, оялып, ата-аналарына, укытучыларына тагын бер мәртәбә рәнҗеп, сыкранып куйгандыр...

Тапшыруда шулай ук хәтта авыл җирләрендә дә татарча әйтелеш канун-кагыйдәләренең бозылуына борчылу белдерелде, аерым алганда, һ авазының (хәрефенең) х белән буталуы (шәхәр, хәммә һ.б.) һәм кирәсенчә булу (мәхәббәт — мәһабәт һ.б.) очраклары тәнкыйть ителде.

Татарстан радиосының инде күптән абруй казанган «Тел күрке — сүз» тапшыруы белән генә тынычланмыйча, туган телебез мәнфәгатьләрен кайгыртуны башка тапшыруларга да кертүе радиотыңлаучылар күңеленә хуш килгәндер. Файдалы өстәмәләр күбрәк булсын иде.

Коръән-Кәримдә әйтелгәнчә, мөэмин-мөселманнарның чит диндәге хатын-кызга өйләнүе бик зур гөнаһ санала. Әмма килен кеше мөселман диненә күнгәндә мондый катнаш никах мактала гына. Сез рәсемдә әнә шундый бәхетле парларның берсен күрәсез. Марина рәсми рәвештә мөселман динен кабул итеп, гомерен татар егете Марат белән бәйләргә булды. Хәзер ул — Мәрьям ханым Шәрәфиева.

Игелекле хатын, яхшы ана бул, Мәрьям. Иманлы, инсафлы һәм дә татар телле балалар тудыр. Амин!

Сүзлекләр, сүзлекчәләр...

Тел өйрәнүнең юллары һәм ысуллары күп төрле. Һәм һәркем үзе өчен аларның уңайлырагын сайлый. Күпчелек халык шулай да иң әүвәл сүзлекләргә мөрәҗәгать итә. Аларны китап кибетләреннән, китапханәләрдән эзли. Әйтик, фәлән кеше мәдәният өлкәсендә яки сәүдәдә, йә булмаса сәламәтлек саклау өешмасында эшли, ди. Ә аларның һәрберсе татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү буенча Дәүләт программасы барлыгы турында ишеткән инде. Күпләр үзе эшләгән өлкәдә генә булса да кулланыла торган төшенчә-атамаларны, еш кабатланган тәгъбир-гыйбарәләрне белергә тиеш икәнлеген, хәтта моның мәҗбүри таләп булып китү ихтималын да яхшы аңлый. Бериш халык үзе гомер буе эшләгән яисә эшләячәк тармакта татарча бер-ике мең сүз, атама өйрәнергә дә каршы түгел. Тик каян алырга, ничек табарга әнә шундый гади генә, җыйнак кына ярдәмлекләрне?

Күптән түгел мондый сорауларга уңайсызланып кына, юк шул әле андый сүзлекчә-ярдәмлекләр, дип җавап бирергә туры килә иде.

Татарстан китап нәшриятында соңгы бер-ике ел эчендә хуҗалыкның, тормыш-яшәешнең төрле тармакларына караган урысча-татарча сүзлекчәләрне басмага әзерләү эшләре туктаусыз алып барылды. Сүзлекчәләрнең берсе — ЗАГСта һәм ритуаль хезмәт күрсәтүдә эшләүчеләр өчен — элегрәк чыккан иде инде. Быел язын икенчесе — мәдәният хезмәткәрләре өчен әзерләнгәне дөнья күрде. Күләме биш табакка якын, тиражы — 10 мең.

Дөресен әйткәндә, бүгенге көнгә сүзлекчәләрнең байтагы инде басылып, таралып өлгергән булырга тиеш иде. Тик уй-ният — бер нәрсә, ә чынбарлык — икенчерәк. Кыскасы, матди хәлебез бу сүзлекчәләрне дә шактый вакыт тоткарлап торды. Шулай да соңгы бер-ике ай эчендә бу эштә хәрәкәт, алга китеш сизелә. Җәйнең калган атналарында һәм көз башында бер-бер артлы берничә сүзлекчә дөньяга чыгар дип өметләнә-өметләндерә алабыз.

Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институтының лексикография һәм лексикология бүлеге фәнни хезмәткәрләре төзегән әлеге сүзлекчәләр, икенче төрле әйткәндә, лексик минимумнар төрле тармакларда эшләүчеләргә адресланган һәм җәмгысе ике дистәдән артып китә. Арада «Иҗтимагый-сәяси сүзлекчә» күләменең зурлыгы һәм эчтәлеге ягыннан беркадәр аерылып тора. Исеменнән үк күренгәнчә, ул — һәркемгә кирәкле һәм файдалы кулланма.

«Файда» дигәч тә, тагын бер фикерне укучыга аерып әйтәсе килә. Әлеге сүзлекчәләргә «фәлән тармак хезмәткәрләре өчен» дип язылса да, сүз сүз инде ул. Аралашкан чакта сүзләрнең теләсә кайсы кирәк була бит. Кыскача гына әйткәндә, укучыларга бу сүзлекчәләрнең байтагы, хәтта һәрберсе файдалы булачак. Бигрәк тә мәктәп укучыларына, студентларга, уку йортларында укыту-тәрбия эше алып баручыларга. Хәер, кемгә генә кирәкми ул сүзлек. Хәтер дигән нәрсә бик яхшы булса да, шүрлектә яисә өстәл тартмасында сүзлек торса, ышанычлырак.

Рим ШИРИЯЗДАНОВ,
Татарстан китап нәшриятының сәнгать редакциясе мөдире.

И туган тел...

1995 ел
18 август
№ 1 (24)

Абдул Абдуличкә

«Угълым сиңа әйтәм,
киленем, син тыңла!»
Татармы, армы син —
белмим үзеңне,
Гаҗәп, тел боткасын
тансык итеп син,
Качаннан бирледер
ык-мык итеп син,
Көчәндең —
кочкә аңлаттың сүзеңне!
Дәрдмәнд.

ҖИСЕМЕ ДӘ ҮЗГӘРӘ

Казан дәүләт педагогика университетының исеме генә түгел, җисеме дә үзгәрә бара. Быел, мәсәлән, анда татар теле һәм әдәбияты бүлеге мөстәкыйль факультет булып башка чыкты. Бу чара укучы студентларның санын шактый арттырырга мөмкинлек бирә. Университет ректоры академик Р.Йосыпов әйтүенчә, быел 100 гә якын студент кабул ителә. Читтән торып укучылар саны да арттырыла.

Бу факультетта укыту тәртипләре дә уңай якка үзгәрә: элек белгечләр башлыча татар теле һәм әдәбияты укытучыларын татар мәктәпләре өчен генә әзерләсә, хәзер алар урыс мәктәпләре өчен дә чыгарыла.

Татар телен башка телләр белән бәйләнештә укыту юнәлешенә дә игътибар көчәйтелә. Мәсәлән, татар теле һәм әдәбияты укытучылары инглиз телен урыс теле нигезендә түгел, ә бәлки ана теле нигезендә өйрәнә. Бу — аларга инглиз телен мәктәптә шул фәнне укытырлык дәрәҗәдә төпле үзләштерергә мөмкинлек бирәчәк.



Китап тамгасы. «Лупза». Нәҗип Нәккаш эше.

Без — Питрәчтән

Йа, Хода, нинди генә исем, атамалар юк хәзер. Казанда урам исемнәрен әйтә алмый телләр көрмәкләнә, ә инде туган авылың атамасын «урысчалатып» та әйтә башласаң...

Без — Питрәч ягыннан. Нигөдер «Пестречинский район» диләр. Пестрый сүзеннән килеп чыккан, диләр. Имеш, питрәчләр төрле һөнәр ияләре булган. Мин атамалар нечкәләрен белмим, әмма Питрәч, Әтрәч, Кибәч исемнәрен авылларга кушканда бабаларыбыз уйлап эш иткәннәрдер...

Туган авылым — Чыты

Урысчасы — Чита. «Казань — Чита» автобусына казанлылар бик аптырый иде, җор телле якташларым да «Едет через Владивосток» дип остиләр иде. **Чыты** дип әйтергә татарга да, урыска да, немецка да бик җиңел, югыйсә.

Хәзер торуым Пимәр авылында. Урысчасы — Пимери. Районыбыздагы бик матур бер авыл — Күнчек дә урысчасы — Конь. Әйтүгә, күз алдына ат килеп баса. Татар Казысы — Отар Дубравка, Татар Тау Иле — Тат. Ходящево дип йөртелә урыс-улак телендә. Ә бит бирегә исемнәрнең хәрефләре генә үзгәртелми, мәгънәсе дә бөтенләй үзгәрә.

Советлар Союзы каһарманы, бөтен илгә яхшы билгеле П.Гаврилов — Әлбәдән авылында туган, урысчасы — Альвидино. Татарстанның иң зур авылларыннан берсе Шәле Шали дип атала. Ярый әле әнием туып-үскән, бик матур авыл исеме Салкын Чишмәне үз исеме белән атыйлар, Холодный Ключ дисәләр, нишләр идең?! Теләгәндә, әйтеп була икән ләбаса.

Ярый инде, урыс ә, ү, ж, ң, һ ларны әйтә алмасын да ди, ә менә Янсуар авылын — Янцеварыга, Иске Йортны — Иске Юртка әйләндерү нигә кирәк?

Татарстанның мөстәкыйльлеге дип сөйлиләр. Нинди мөстәкыйльлек соң, авылың исемен дә дөрес итеп әйтә, яза алмагач.

Быел 8 мартка курсташым открытка җибәргән. Адресым Питрәч районы, Пимәр авылы дип татарча язылган иде. Дустым мине ике тапкыр котлаган кебек булып китте...

Венера ХӨСӘЕНОВА.

Казанда һаман искечә...

Хөсәен Ямашев проспекты буйлап килә-килә җиңел автомашиналар кибетенә җиткәнмен. Затлы пыяла ишекләргә беркетелгән язуларга күз салам: «Махсус кибет № 6 «Автомобильләр. Эш сәгате 8-20 тәнәфес 13-14» Нинди телдә бу язу? Сүзләре татарча да кебек, ә шул сүзләрдән дөрес итеп татарча җөмлә төзергә белем җитмәгәнме, әллә теләк, җаваплылык булмаганмы?

Шул ук урамның ашамлыклар кибетендә, язуына карагандa, колбасалар, сырлар белән берләттән «кошлар» да сатыла икән. Нинди тере кошлар сатыла икән,дип кибеткә керсәм, анда тавык, күркә кебек кош итләре сатыла икән. Менә сиңа тәрҗемә!

Фәрдия МИҢЛЕБАЕВА.

А ГАЧ — АВЫЗ, БАЛТА — ТЕЛ

ИСЕМНӘРЕН КЕМНӘР КУЙГАН

(Урам, авыллар буйлап халык рейды дәвам итә)

* * *

Яшьләр татар теленә — дәүләт теленә — өйрәнсен өчен хәзер аз эшләнми: татар гимназияләре, лицейлары арта бара, матбугат ишәя. Тик болар гына аз әле. Мөмкинлекләрнең барысын да файдаланырга кирәк. Мәсәлән, урамдагы язулар да үзенә бер «дәрес» бит. Тик менә мондый «дәресләрнең» файдасыннан бигрәк зарары күбрәк түгел микән...

«Экран» кибетенең тимер ишегенә беркетелгән «Кибет эше кагыйдәләре»нә күз салдым. Урысчасы белән янәшәдә татарчасы да булу күңелгә рәхәтлек бирде, тик ашыгыбрак сөенгәнмен, әче тулы хата икән: «кибетнең эш вакыты» диясенә «кибет вакаты» дигәннәр. Ә бит икенче җөмләдә дөрес язганнар, димәк, яза беләләр, әмма татарга ничек тә ярый. дип карыйлар. Тикшерүче дә, җавапка тарттыручы да, җавап тотучы да юк. «Товарларның үрняклäре» нәрсә дигән сүздер? Тик бу хакта кемнән сорарга да белмисең. Татар теленең дәүләт теле булуын гарантияли торган җаваплы шәхес, оешмалар Татарстан Конституциясендә күрсәтелгән ләбаса!

Наилә НИЗАМЕТДИНОВА.

Тәмле дә тел,
тәмсез дә тел.

Гыйлем алу —
энә белән
кое казу.

Э ТИМОЛОГИК ТАБЫШЛАР

Ганвә. Татар теле халык сөйләме белән китап сүзенең тәэсирләшүе процессында үсеш алган. Ә китап телендә биздә элек-электән гарәп-фарсы элементлары күп булган. Шуның нәтиҗәсендә бүген бер кызыклы күренешкә тап булабыз: еш кына безнең замандашлар урысныкы дип уйлаган сүзләр, асылда, гарәп-фарсы сүзе булып чыга.

Шуларның берсе — диалекталь **ганвә** — «үпкә, кинә, үч; субъектив гаепләү». Бу сүзне 1892 елда Н.Остроумов чыгарган «Татарско-русский словарь» **гынабя** формасында, 1969 һәм 1992 елларда басылган «Татар теленең диалектологик сүзлеге» **гынива, гыйнава** дигән яңгырашларда бирә. Н.Остроумов та, «Диалектологик сүзлек» авторлары да бу сүзне урысча **гнев** — «каты ачулану» сүзеннән дип карыйлар. Хәлбуки, **гыйнвә, ганвә** — «җәбер, көчлек, тиктәскә гаепләү» мәгънәсендәге гарәп сүзе.

Бу сүзне татарча юриспруденция төшенчәсе итеп файдаланырга мөмкин.

Гауга һәм гау. Еш кына сүзнең тамыры ике була, ягъни билгеле бер телдә икеяктан килгән сүзләр берләшә. Мондый күренешне **контаминация** диләр.

Моның мисалы — татар телендәге **каугa, гауга** — «шау-шулы талаш-тартыш, җәнҗал» сүзе. Чыгтай (иске китап) телендәге **гауга**, күп төрки телләрдәге **кауга** — «шау-шу, ызгыш, сугыш» — гарәп телендә **гауга** — «тавышлы җыелыш» сүзеннән дип уйлыйлар.

Икенче яктан, татар телендә **кауга (гауга)** барабаны сүзе бар. Ул сөрән салу өчен куелган зур барабанны белдерә. Аны афәт-хәтәр очракларында, сугыш чыкканда кагыла торган нәрсә дип уйларга мөмкин. Ләкин **кауга барабаны** нишләптер кое янына куела. Һәм тагы **кауга** сүзе дә еш кына «кое чиләге» мәгънәсендә очрый. Бу мәгънә исә монголча **кавуга, кавга**, төрекчә **кован, кова, кава** — «цилиндр, чиләк» сүзенә тартым кебек.

Татар һәм фарсы телләрендә **гау** — «шау-шу, сөрән, кый-ку» сүзе дә бар һәм аны **гауга** сүзеннән кыскарган дип уйларга мөмкин. Ләкин кумык телендә һәм кайбер бүтән төрки шивәләрдә **кау, гау** — «күмәк шатлану, бергәләшеп сөенешү, тантана, рухлану». Бу сүз исә борынгы (татар-башкорт телләрендә хәзер дә очрый торган) **кау** — «былтыргы кипкән үлән; былтыргы үләнне (яшь үлән тизрәк үссен дип) яндыру күренеше» сүзенә тоташа. Чувашча **хавха** — «шатлык, куаныч, рухлану», **халхав, хавхал** — «гауга, сөрән, кып-ку», ә монголча **хавгал, каугал** — «үлән яндыру» (**кау** — «коры үлән», **гал** — «ут, янгын»).

Күз алдына шундый манзара килеп баса: киң далада былтыргы үлән яна. Бүтән тамашалар үзләренә бик үк тәтемәгән борынгы яшьләр моңа рухланып карап торалар, ура кычкыралар. Кыскасы, «каугал». Икенче яктан, даланы иңләп килгән янгын шундагы хайваннар өчен афәт, кешеләр өчен хәтәр, хәвеф. Кыскасы — «гауга».

Шунда башыбызга тагын бер уй килә: безнең китаби **гауга** сүзе гарәпчәдән булырга бик мөмкин. Әмма гарәп сүзе үзе төрки телләрдән алынма түгелме икән?

Рифкат ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы.

КИЛӘСЕ САННАРДА:

Безнең даими рубрикаларыбыз:

- Туган телне — гамәлгә!
- Гаиләдә
- Ясле-бакчада
- Мәктәпләдә
- Югары уку йортларында
- Фәнни кыйблалар
- Сөйләмият дәресләре
- Балаларга укыгыз
- Укучыларыбыз иҗаты
- 2002 мәзәк
  һәм бүтәннәр.

Сәхифәнең мөхәррире
Илдар НИЗАМОВ.
Адресыбыз: 420503,
Казан, Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга»,
«И туган тел...»



● Ризван Хәмид ● Рөстәм Мингалим

Идегәй

Әлеге кинодрама өч серияле нәфис фильм эшләү өчен «Татарфильм» киностудиясе заказы белән язылды. Язу барышында «Идегәй» дастаныннан башка бик күп тарихи һәм фәнни хезмәтләр, китаплар файдаланылды. Бүген шушы әсәрдән бер өзек тәкъдим ителә. Кинодрама тулысынча быел «Казан утлары» журналында басылып чыгачак.

Олы-Тау итәге. Көн

Апрель лыжгырдавы. Шаһ Тимернең гаскәре берничә көн хәл җыярга, авыр юлда йончыган арык атларына ял бирергә туктаган. Гаскәрнең бер өлешеауга киткән.

Шаһ Тимернең поход чатырында сөйгән яшь хатыны мәликә Чулпан. Идегәй һәм бөек падишаһ үзе генә. Шаһ Тимер белән Идегәй шахмат уйныйлар. Чулпан җиләк-җимеш ашый-ашый аларның уенын күзәтә: аңа Идегәй, ир кеше буларак, ошый булса кирәк, ул еш кына, иренә сиздермичә, аңа төбәлеп карап тора. Идегәйнең күз карашы белән очрашса, елмаеп, аның күңелен үзенә игътибар иттерергә тырыша. Идегәйгә хатынның кыланышы ошамый, аның йөзе отыры караңгылана бара. Ниһаять, ул, Чулпанның ачыктан-ачык каш сикертергә азаплануын сизеп, юри тиз-тиз генә ялгышлар җибәреп, бөек падишаһка сүзката.

Идегәй *(елмаеп)*. Бүген дә уңышка ирешә алмадым, бөек падишаһ!

Тимер *(киявен сынагандай)*. Тагын бер тапкыр омтылыш ясап карарга теләмисеңме, кияү? Бәхет елмаер, бәлки?

Идегәй *(ул падишаһның нәрсәгә ишарә ясавын аңлый)*. Кичер, бөек падишаһ... Никтер баш авыртып тора. Салкын җил бәрде микән? Рөхсәт итсәң, үз чатырыма кайтып, черем итеп алыр идем?

Чулпан *(ризасызлык белән)*. Һу! Уеныгызны рәхәтләнеп карап торырмын дигән идем... Үзем уйный белмәсәм дә, яратам мин... *(Кинаят белән Идегәйгә карый)*.

Тимер *(хатынының сүзенә игътибар итми)*. Башың авыртуның сәбәбе житдирәк түгелме икән, кияү?

Идегәй. Мин дә шулай түгелме икән дип шикләнәм, падишаһым.

Тимер. Кыстамыйм, кияү, алай булгач. Ял ит. Минем гаскәр башлыкларым һәрвакыт сау-сәламәт булырга тиеш! *(Кузгала. Идегәй дә тора)*. Ә минем башка бер... матур уй килде: бүген шахматсыз да күңелсез булмас, шәт. *(Чатырдан чыгалар. Идегәй Чулпанга күтәрелеп карамыйча гына, баш иеп чыгып китә)*.

Олы-Тау итәге. Көн

Шаһ Тимер ике тән сакчысы һәм битикчесе белән җирдә аунап яткан дүртпочмаклы зур гына таш янына килеп туктый.

Тимер. Монысы — ярый... *(Битикчегә)*. Өстен тигезләп шомарттыр да мондый сүзләрне чокып яздыр: «Мин, Туран солтаны Шаһ Тимер, ике йөз меңле гаскәрем белән Алтын Урда ханы Туктамышның канын кояргa яу чыктым. Фәләненче ел, фәлән ай». Шушы урында кеше гәүдәсеннән тирәнрәк итеп тар чокыр казылсын, ә өске өлеше — шушы ташның очы шыплап сыярлык булсын. *(Битикче аның сүзләрен язып тора һәм башын иеп кала)*.

Шунда ук. Кичке як

Тар гына тирән чокыр казылган. Чокыр янында, ясси ягын шомартып, гарәп хәрефләре белән Шаһ Тимер кушкан сүзләр чокып язылган таш ята.

Шаһ Тимернең чатырлардан корылган лагерена сугышчылар бик күп болан, поши, җәйрән һәм башка төрле киек тушкаларен киртәләргә бәйләп алып кайта, гаскәр букауллары (завхозлары) ау ганимәтләрен исәпләп тора.

Таш янына үзенең иярченнәре белән Шаһ Тимер килә. Мәликәсе Чулпан һәм Идегәй дә шунда.

Битикче *(падишаһына баш ия)*. Әмерең үтәлде, бөек падишаһ.

Шаһ Тимер чокырны һәм язулы ташны җентекләп тикшерә.

Чулпан *(шикләнеп)*. Бр-р! Нәрсә була бу, солтаным?

Тимер *(кырыс)*. Тиздән аңларсың... *(Ике тән сакчысына)*. Мәликәгезне шушы чокырга төшереп бастырып карагыз әле — үзенә таманмы икән?

Бөтенесе дә аңа гаҗәпләнеп карыйлар, Чулпанның күзләре маңгаена менә.

Чулпан *(шаярткыга борырга теләп, артка чигенә)*. Юк-юк, мин теләмим: анда бик пычрак вә салкын!

Тимер *(икеләнеп торган казакларына)*. Әмеремне үтәгез!

Чулпан. Әнекәем! *(Чиный-чиный читкә йөгерә)*.

Таза казаклар аны, куып тотып, чокыр янына китерәләр.

Чулпан *(елап)*. Гасбем булса, кичер мине, падишаһым! Синең алда бер гөнаһым да юк ич минем! *(Тезләнергә уели)*.

Тимер *(казакларга)*. Нәрсә көтәсез?! Үзегезгә дә чокыр казытасыгыз киләме әллә?

Казаклар Чулпанны акырта-акырта күтәреп, шләп кенә чокырга төшереп җибәрәләр. Аның буе чокырның яртысыннан гына була. Чулпан кулларын күтәреп, чокыр читенә тотынмакчы була, әмма үреләп тә буе җитми.

Тимер. Ташны өстенә утыртып уегыз!

Уңлаган казак язулы ташны, көч-хәл белән күтәреп, Чулпанның баш очында ясалган чокырга утырта. Чокыр капланыр алдыннан бичара хатынның җан өшеткеч ачы тавышы яңгырый һәм кинәт тына — җир астыннан шиндидер тонык авазлар гына ишетелгән кебек була. Барысы да, агарынып, тын алырга да куркып басып торалар.

Тимер. Менә хәзер беркемнең дә башы авыртмас. *(Уң ягына аксый төшеп, чатыры ягына китә, иярченнәре аның артыннан иярә)*.

Язулы таш, әле һаман да, җир астыннан аваз бирергә азапланган мескен Чулпанның кабер ташына әйләнеп, Олы-Тау итәгендә тырпаеп тора.

«Алтын Таш» хан сарае. Иртән

Туктамыш ханның йокы бүлмәсе. Чуклы бәрхет чаршаудан корылган балдахин эчендә хан ятагы. Туктамыш хан шәп-шәрә яшь кәнизәге белән йоклап ята. Саташи булса кирәк — ыңгырашып куйгалый.

Ханның йокы бүлмәсенә Йәнникә атылып килеп керә, аның башы-күзе тонган. Йәнникәнең аяк тавышыннан уянып кәнизәк сикереп тора һәм ханбикәне танып, куркуыннан аңа карап ката.

Йәнникә *(кәнизәккә исе дә китми)*. Прес! *(Мәче куганда кулын гына селти)*.

Кәнизәк кыз, җиңел котылуына шатланып, күлмәге белән түшен каплап чыгып йөгерә; аның каршына Киң Җанбай очрый.

Йәнникә *(ханны төрткәләп уята)*. Тор тизрәк, каган! Идегәй Аксак Тимерне Җаекка китергән! Урдаңа куркыныч яу килә!

Туктамыш *(йокы йөзеннән аерылмыйча сикереп торып утыра)*. Фу! Әллә нинди төшләр күреп, сатанып беттем! Нинди ау! Баш вәзиргә әйтсеннәр: бүген ауга чыгарга кәефем юк.

Йәнникә *(аны җилтерәтә)*. Уян, дим син сиңа! Синдә һаман кәнизәкләр беләнмин ау кайгысы! Идегәй илеңә яу алып кайткан! Аксак Тимер — канкаң тобенкайткан! Аксак Тимер — канкаң тобен-дә! Вакытында башын чаба белмәдең шул мөртәтнең!

Туктамыш *(күз алдында агарына)*. Булмас?!

Җанбай *(сүзгә кушылырга вакыт җиткәнлеген чамалый)*. Кызганычка, бу — хак сүз, бөек каган. Туп-туры йокы бүлмәңә килеп керүемне кичер — вакыты шундый. Шаһ Тимер, ике йөз меңле гаскәре белән Җаекны кичеп, Ку күле буена урнашкан. Идегәй — аның гаскәренең маңгаена баш. Ырыс ханның өлкән углы Коерчак — сул канат башы, ди.

Туктамыш *(бөтенләй югалып калган)*. Нишлибез? Йолым түләп, килешеп булмасмы? Яныбызда бер төмән гаскәребез дә юк бит — барысы да язгы кыр эшләрендә!

Йәнникә. Нинди йолым?! Дүрт йөз меңлек гаскәрең була торыпмы?! Тавыклар көләр!

Туктамыш *(ачык изүе аша йонлач күкрәген кашый. Күкле-яшелле тавыш белән)*. Җыеп өлгерә алмыйбыз, дип торам ич мин сиңа, тавык мие эчкән хатын!

Җанбай. Ханбикәнең сүзе нигезле, бөек каган. Болай итәргә кирәк, минемчә. Идегәй заманында пир Галәветдингә бик нык табына иде — ул аның остазы булган сәет бит. Пир Галәветдинне Идегәйгә илче булып барырга күндерик...

Туктамыш *(түземсезлек белән аны бүлдерә)*. Моның белән без нәрсә отарбыз соң? Шуны әйтеп бир син миңа!

Җанбай. Пир Галәветдин Шаһ Тимер гаскәрен беразга гына булса да тоткарлап тора алмасмы? Ишетүемчә, Идегәй — хәзер аның кияве, имеш. Әгәр дә ул остазының сүзенә колак салса... Ә аныңчы без ерак олыслардан гаскәребезне туплап өлгерербез.

Туктамыш *(ниһаять, бераз җанлана төшә)*. Фәрманымны әзерләт, Җанбай би!

Ку күле буенда Шаһ Тимернең лагере. Кичке як

Шаһ Тимер чирүе, килеп җитмәгән гаскәрләрен көтеп алыр өчен, Ку күле тирәсенә лагерь корып туктаган; сугышчылар коралларын рәткә китерәләр, кылычларына йөз салалар, кием-салымнарын сипләләр, атларын дагалыйлар, күлдә балык тоталар. Чатырлардан корылган лагерь күз күреме бөтен офыкны сырып алган.

Идегәйнең маңгай гаскәре, иң алдан йөрүче буларак, пәкъ күл буена урнашкан. Монда атларга үлән дә яхшырак, су да җитәрлек. Идегәйнең улы Норадын белән уртак чатыры күлгә терәлеп үк тора. Алар чатыр эчендә.

Норадын. Мең башы ит мине, Идегәй әти! Үз гаскәрем белән орышта катнашып, мине мәсхәрә иткән Туктамыш бәкләреннән үч аласым килә!

Идегәй. Бу — минем куллап килә торган эш түгел, Норадын улым, гаскәр башлыкларын Шаһ Тимер шәхсән үзе билгели. Аннан соң ул орыш алдыннан беркайчан да аларны алмаштырмый. Мондый гамәл гаскәр башлыкларының тәвәккәллеген киметә, дип саный. Мин үзем дә аның белән килешәм: кичүгә җиткәч, атны алмаштырмыйлар.

Норадын. Ул чагында мине Болгар иленә җибәр, болгар түрәсе Болай би көтә мине: урап кайтканыңны көтәчәкбез, дип әйтеп калды ул. Син бирә алмаган гаскәрне ул бирәчәк миңа.

Идегәй *(улының кәефен кырасы килмичә)*. Уйлашырбыз, улым.

Норадын *(түземсезләнеп)*. Уйласы юк, әти! Син үзең дә монда — Шаһ Тимернең әмерен үтәүче генә! Туктамыш җиңелсә — Шаһ Тимер яуны бөтенләе белән үзенеке итәчәк. Тәхеткә дә кемне тели — шуны куячак! Синең белән тамчы да санашмаячак ул, мин әйтте, диярсең, Идегәй баһадир. Синең урыныңда булсам, мин аның баһадиры булып йөргәнче, үз гаскәремнең батыры булырга тырышыр идем. Әйдә, без дә үз гаскәребезне җыярга киттек!

Идегәй *(елмая)*. Күз алдында көннән-көн ир-егет булып барасың бугай син, бәбкәм. Тик артык кабаланасың. Шаһ Тимер тырнагына эләгә күрмә — аның талканы коры!

Тышта: «Идегәй баһадирга — Туктамыш хан илчесе!» дип кычкырган тавыш яңгырый. Ата белән ул бер-берсенә аптырашып карыйлар.

Идегәй. Кем булыр икән? *(Тышка юнәлә. Норадын да аңа ияреп чатырдан чыга)*.

Аның чатыры янына кораллы казаклар сагы астында, пир Галәветдин белән Алтын Урданың берничә дин җитәкчесе килә. Туктамышның шыгавыллары Аңгысын белән Тыңгысын да алар арасында — илчеләрне озатып йөрүчеләр итеп билгеләнгәннәр, күрәсең.

Бер казак. Маңлай башы Идегәй баһадир! Туктамыш хан илчеләре сине сорыйлар.

Идегәй *(остазын танып, аларны ачык күңел белән каршы ала)*. Хуш киләсең, остазым пир Галәветдин сәет! Аяк астыңда тузан булыйм! *(Чын күңелдән хөрмәтләп, аңа баш ия)*. Чатырыма үтегез, хөрмәтле илчеләр. *(Чатыр ишегенең чаршавын ачып тора. Озата килгән казакларга)*. Сезгә китәргә мөмкин, кирәк булсагыз чакыртырмын. *(Казаклар киткәч, Аңгысын белән Тыңгысынга әкрен генә дәшә)*. Икегезне дә исән-имин күрүемә шатмын. Норадын улым, кунакларны сыйла. *(Пышылдап)*. Минем кешеләр болар, чит колак булмаган чакта сөйләшү яхшырак. *(Кычкырыбрак)*. Кадерле кунакларыма сый китерсеннәр, углым. *(Чатырына керә)*. Келәмгә утырышыгыз, хөрмәтле илчеләр. *(Асларына күп мендәрләре ташлый. Үзе дә алар янына урнаша)*.

Галәветдин. Йә, бер дога кылыйк.

Кулларын күтәреп, бөтенесе бергә дога кыла.

Галәветдин. Амин! *(Ике учы белән битен сыпыра)*.

Идегәй. Исән-имин килеп җиттегезме барыгыз да, остазым пир Галәветдин абзый? Юл газабы бик авыр булмадымы?

Галәветдин. Ходайга шөкер, Идегәй углым, әйбәт килеп җиттек. Юлдашларымның бөтенесен дә таныйсыңдыр? Илнең хөрмәтле имам-сәетләре болар.

Идегәй. Бик әйбәт таныйм, остазым. Онытып бетермәгәнмен икән әле.

Гаскәр коллары аларына төрле ашамлыклар кертеп куялар. Берсе, комган белән җиз таз алып кереп, кунакларның һәм Идегәйнең кулларын юдыра, сөлгеләр бирә. Хезмәтчеләр чыгып китә.

Идегәй. Хәзинәдә булганыннан житешегез, хөрмәтле сәетләр.

Галәветдин. Тыңлыйбыз сине, Идегәй углым, безгә әйтер сүзең күптер.

Идегәй. Дөрес, остазым, әйтер сүзем күп. Ләкин сез барыгыз да миннән өлкән, сезнең күз алдаң йөри.

Сәетләр. Хуш, хуш, Идегәй батыр. Ата-баба горефен читтә онытмагансың.

(Ахыры 16 нчы биттә).

Идегәй

(Ахыры. Башы 15 нче биттә).

Идегәй *(елмая)*. Кеше кайда да кешечә гореф тота, хөрмәтле сәетләр.

Сәетләр. Әйе. Шулай булырга тиеш. Кайда да адәм баласы яши! Бик мәслихәт!

Галәветдин. Сүзебез кыска безнең, Идегәй углым: үз йортыңа яу чакырып, бик начар эшләгәнсең. Атыңны кирегә бор, яисә Сарайга кайтып, кабат Туктамыш ханның бие бул! Үз халкыңның канын нахакка койдырма ләгыйньнән! Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан!

Сәетләр. Әйе. Ыруың канын койдырма. Атыңны кире бор, Идегәй батыр!

Идегәй *(йөзе караңгылана)*. «Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан»... Яхшы әйттең, остазым! Тик минем сорауларыма җавап бир, пирем: Котлыкыя атамның йортын яндырып, башын ора чапканда син кайда идең?

Пир Галәветдин дәшми.

Идегәй. Алты угыл үстергән Җантимер би дә синең кебек пир иде: ул үз башын пычак астына куеп, атамны йолып калырга тырышкан. Менә ул — пир! Бишектә яткан чагымда башымны ора чабарга торганда, ул үз төпчеген кызганмыйча минем урынга салып, мине ачы үлемнән йолып калган — ул чакта син, пирем, кайда идең?

Пир Галәветдин дәшми.

Идегәй. Туктамыш хан мине кендек каным тамган туфрагымнан аерганда син кайда идең, пирем?

Пир Галәветдин дәшми.

Идегәй. Гөнаһсыз Нурадын углымны Туктамыш хан мәсхәрәләп минем арттан куды — ул чакта син кайда булдың, пирем?

Пир Галәветдин дәшми.

Идегәй. Урда тәхетенә берүзе хуҗа булып калгач, Туктамыш хан кардәш ыруларыбызны тимер дагалы күн итекләре астына салды — син кайда идең, пир Галәветдин?!

Пир Галәветдин дәшми.

Идегәй *(ящак калкымын уйнатып)*. «Илләштермәк — илчедән, яулаштырмак — яучыдан...» Атыңны кайтыр юлыңа бор, Туктамыш илчесе!

Галәветдин. Авыр сораулар бирдең остазыңа, Идегәй батыр... Ниятеңнән кайтмасаң, синең үзеңә болардан да авыррак сорауларга җавап бирергә туры килер! *(Кузгала)*.

Идегәй. Тәкъдиргә язылганы булыр, Туктамыш илчесе!

Идегәй чатыры алды. Кичке як

Уңышсыз сәфәргә чыккан Туктамыш илчеләре караңгы чырай белән чатырдан чыгалар. Идегәй аларны озата. Чатыр янына Шаһ Тимер сәете Бәркә килә. Ул нәселдәшләрен күрергә ашыккан.

Бәркә. Әссәламегаләйкем, Рәсүлебезнең варислары! Мин — ерак нәселдәшегез Бәркә сәет булам. *(Күкрәгенә кулын куеп, сәетләргә баш ия)*. Килүегез хакында ишеткәч, сезне күрәсем килде.

Галәветдин *(аңа бераз карап тора һәм кырыс йөз белән китәргә борыла)*. Ләгыйньгә ялланган сәет белән уртак эшебез булмас безнең!

Туктамыш илчеләре ашыгып китеп баралар. Сәет Бәркә каушап басып кала.

Идегәй *(аны кызганып)*. Чатырыма рәхим ит, сәет Бәркә.

Сәет Бәркә тегеләрнең дорфалыгына Идегәйне гаепле санагандай, бер сүз дә эндәшмичә үз чатырына китә. Бу очрашу аны бөгеп салган.

Ул арада Аңгысын белән Тыңгысын, юл өстендәге бер чатырдан чыгып, Туктамыш илчеләренә кушыла. Нурадын әтисе янына килә, алар чатырга керәләр.

Чатырда. Кичке як

Чатырга кергәч, Идегәй белән Нурадын миндәрләргә таяналар һәм пышылдап сөйләшә башлыйлар.

Идегәй. Йә, нинди яңалыклар белдең?

Нурадын. Нигә килгәннәр иде соң алар?

Идегәй. Яуны туктатуны таләп иттеләр.

Нурадын. Шул гынамы? *(Көлә)*.

Әмма Идегәй аңа кушылмый.

Аңгысын белән Тыңгысының Туктамыш ханның шыгавыллары икәнен белмәсеңдер? Хәзер аларны Туктамыш хан байракчылары итеп билгеләргә теләгән икән. Чөнки Сарайда гаскәр бик аз калган, бер төмән чамасы гына, ди. Илчеләрне җибәрүе — нидер өмет иткәннән түгел, ди, яшерен максаты — яуны бераз тоткарлап, гаскәрен җыеп бетерү, имеш. Мин Аңгысын белән Тыңгысынга, әгәр дә Туктамыш хан чынлап та ниятендә торса, орыш кызган чакта урда байрагын аударырга киңәш иттем. Риза булдылар. Дөрес эшләгәнмеме, Идегәй баһадир? *(Елмая)*.

Идегәй *(йөзе ачылып китә)*. Үз гаскәребезне җыярга китәбез, углым! *(Улының маңгаеннан үбә)*. Ыру тамгасын дөрес биргәнмен икән мин сиңа, Нурадын! *(Сикереп тора)*. Юлга чыгарга әзерлән. Мин Шаһ Тимер чатырына киттем!

Шаһ Тимер чатыры. Кич

Шаһ Тимер уллары белән бергә кичкелекне ашап утыра, әкрен генә музыка ишетелә, канизәкләр бии, хезмәтчеләр ризыклар кертә.

Шыгавыл *(ишектә күренә)*. Маңгайбашы Идегәй баһадир кабул итүеңне сорый, бөек падишаһ.

Гомәр шәех. Туктамыштан илчеләр килүен яшереп калдырыр, дип көткән идем — түзмәде, килде.

Тимер *(улына кырыс карап куя)*. Керсен.

Идегәй *(керен йөгенә)*. Кичер, бөек солтан, сиңа бер яхшы хәбәрем бар. *(Чит колак юкмы икән дигәндәй, чатырдагыларга күз йөртеп чыга. Сәет Бәркә дә анда утыра)*.

Тимер. Тыңлыйм сине, кияү.

Идегәй. Миндә Туктамыш ханның сәетләре булып китте, явыңны туктатуымны үтенделәр... *(Елмая)*. Уртак тел таба алмадылар, кичер, солтаным. *(Житди)*. Әмма сиңа җиткерәсе хәбәрем икенче: сәетләр белән бергә ике ышанычлы кешем дә килгән иде, Туктамыш аларны Урда байрагын күтәрүчеләр итеп куймакчы икән. Егетләрем орыш кызгач, байракны аударырга вәгъдә бирделәр. Мин аларга үземә ышанган кебек ышанам, бөек солтан!

Чатырда тирән тынлык урнаша, барысы да ашаудан тукталар.

Музыка тына, биюче канизәкләр тавыш-тынсыз юк булалар.

Тимер *(әкрен генә урыныннан торып Идегәй янына килә һәм аңа текәлә)*. Хак сүзме бу, Идегәй баһадир?

Идегәй, уң кулын күкрәгенә куеп, аңа баш ия.

Егетләреңә әйттер: үзләре күтәрә алырлык алтын бүләк итәчәкмен мин аларга!

Идегәй *(горур)*. Алтынга хезмәт итмиләр алар, бөек солтан. Алар — минем егетләр.

Тимер *(йөзеннән ачу билгесе йөгереп уза, ләкин ул аны шундук яшерә)*. Ихтыярлары, Идегәй кияү... Ихтыярлары... Шулай да... сүзләреңдә торсалар, исемнәрен оныттырма. Яудан коры кайтканчы, яралы кайт. Табыныма рәхим ит, кияү.

Идегәй. Рәхмәт, бөек солтан. Рөхсәт итсәң, мин үз кешеләремне алып, тугрылыклы кардәшләрем арасына гаскәр җыярга китәр идем. Миннән хәбәр көткән әмирләрем бар. Яуга үз өлешемне кертеп, бәхетемне сынап карыйсым килә! Рөхсәтеңне бирче, бөек солтан!

Тимер *(уйланып)*. Яхшы. Орышка соңга калма, Идегәй баһадир!

Идегәй *(шатланып)*. Калмам, Шаһ Тимер! *(Йөгенеп чыгып китә)*.

Тимер *(узалдына)*. Ә без сине соңга калдырырга тырышырбыз... Орышны Чулман елгасы тирәсенә күчерәрбез, анда карурманнар күп икән — Туктамыш үзе безне шуннан эзләп тапсын... Идегәй дә!

Ку күле буе. Төн

Күера башлаган караңгылыкта кул буеннан егерме-утыз җайдак Тимер Казык йолдызга таба карап кузгалып китә. Җайдаклар арасында Идегәй, аның улы Нурадын һәм Тимер Котлый хан күренә.

Шаһ Тимер ставкасы. Иртән

Шактый биек калкулык: аны арттан, уңнан һәм сулдан дуга сыман итеп куе карурман уратып алган. Шаһ Тимернең чатыры калкулыкның нәкъ уртасына корылган һәм аны алгы яктан зур арбалар чылбыры ярымтүгәрәкләп коршап алган, ул чылбыр-ныгытманың ике очы еракта урман читләренә барып тоташа. Тезмәнең тышкы ягында туфрактан биек вал өелгән һәм ул туфрактан ясалган ныгытма белән арбалар чылбыры арасында тирән канау хасил булган. Кыскасы, Шаһ Тимернең ставкасы кәлә кальгасы хәтерләтә. Калкулыктан тирә-як уч төбендә кебек ап-ачык күренә. Шаһ Тимер гаскәренең арттагы күп өлеше карурман эчендә, ә аның янында үшике меңлек махсус гаскәреннән башка — үзәк маңгай, уң һәм сул канатларның маңгай гаскәрләре генә.

Шаһ Тимер уллары-оныклары һәм олкән нубашы белән киңәшмә уздырган, соңгы әмерләрен бирә. Шунда ук дистәләгән адъютантлары, күзәтчеләре, вәзирләре һәм киңәшчеләре җыелган. Сәет Бәркә, тез астына намазлык салып, иртәнге намазын укый.

Күзәтче *(шатланып)*. Туктамыш гаскәре! *(Еракта калыккан җайдакларга күрсәтә)*.

Барысы да җанланып «Kha!» дип кычкырып җибәрәләр. Аларның шатлануы аңлашыла: алар, монда күптән килеп, иң уңайлы урынны сайлап алганнар, саклану чараларын булдырганнар, орыш башлануын гына көтәләр. Ә Туктамыш ханга ерактан килгән уңайга гаскәрен рәткә тезәргә, ставка урынын сайларга һәм башка чаралар күрергә туры киләчәк. Шаһ Тимер алдан күрә белүеннән бик канәгать, әмма ул моны сиздерми, йөзе тыныч.

Туктамыш ханның кырлата еракларда килгән гаскәре күз алдында алар әкренләп сафларга тезелә башлый, ыгы-зыгы куба.

Туктамыш хан ставкасы. Шул ук вакыт

Кечкенә елга буенда тугайлык, артта да, алда да — сирәк-мирәк әрәмәләр, чокыр-чакыр. Туктамыш ашыгыч рәвештә ставка урынын сайлый; аның чатырын коралар. Сугышчылары да, Туктамыш үзе дә юктан да ярсырга әзер, чөнки алар — кыздырырга табага салынган балыклар кебек, Шаһ Тимернең күз алдында ап-ачык җирдә тукталырга мәҗбүр. Төпе буе килгәннәр, ахры, барысы да шактый йончыган күренә. Калкымлы җирдә туктыйлар.

Туктамыш. Гаскәр башлыкларын — минем янга! *(Карага кабынып, адъютантларына җикерә)*. Тизрәк кыймылдагыз, аякларыгыз маймакланып чергән нәрсәләр!

Адъютантлары абына-сөртенә төрле якка сибелә. Туктамыш, ярсудан тыела алмыйча, бертуктаусыз мыегын чәйни.

Җанбай *(ул да тыныч түгел)*. Шаһ Тимер орышны хәзер үк башласа, нишләрбез? Күз алдында иңкүлектә җәйрәп ятабыз! Бигрәк лап җир эләкте.

Туктамыш дәшми, ул, ниндидер могҗиза көткәндәй, Шаһ Тимернең байрагы җилфердәп торган калкулыкка төбәлгән. Әйтерсең лә, күзләрен бераз йомып торып, кабат ачуга дошман тылсым көче белән юкка чыгачак. Ул чынлап та күзләрен йома һәм бераздан ача: юк, кан дошманы һаман үз урынында. Аның янына әкренләп өлкән нубашлары җыела. Алар хан сүзен көтәләр.

Туктамыш *(беркемгә дә карамыйча)*. Урда байрагын күтәрсеннәр.

Байракчылар — Аңгысын белән Тыңгысын да шунда — Чыңгыздан мирас булып калган кара туны биек колгага беркетеп күтәрәләр.

Адъютант. Ту күтәрелде, бөек каган!

Туктамыш. Уң кул башы Кыпчак би!

Кыпчак. Тыңлыйм, каган.

Туктамыш. Һөҗүмне син башлыйсың. Әнә теге урман очына кадәр ара — синең өстә! Иң мөһиме — көньяклап юлыбызны кисмәсеннәр! Исабәк би!

Исабәк. Әмереңне көтәм, бөек каган.

Туктамыш. Миңа сульяклап сузылган урман ошамый. Без орыш белән мавыккан арада, Шаһ Тимер шул урман аша Идел ярына артыбызга төшмәсен! Идел ярын күз караң кебек сакла!

Исабәк. Үтәлер, бөек каган.

Туктамыш. Маңгайбашы Кара Хуҗа Аргын би!

Аргын. Мин монда, бөек каган.

Туктамыш. Маңгайга-маңгай торырга әзер бул!

Аргын. Мин һәрвакыт әзер, бөек каган!

Туктамыш. Әзер булсаң.... Калганы — Хак Тәгалә ихтыярында. Шаһ Тимергә чапкын җибәрегез — илме, яумы? Курыккан башлап йодрык күтәрә.

Аргын би үзенең адъютантына ишарә ясый, анысы атын камчылап, дошман урнашкан калкулыкка табан чаптырып китә. Бөтен гаскәр тын калып нәтиҗәне көтә. Чапкын бер кулына ак яулык күтәреп, каршыда яткан елгачык аша чыга һәм ике арадагы кыр буйлап чаба. Шулвакыт дошман ставкасыннан да бер җайдак аерыла, аны, арбалар чылбырын бер урыннан өзеп, болынга чыгаралар. Шаһ Тимер җайдагы көтмәгәндә күз алдында гаип була һәм бераздан кабат күренә. Туктамыш ставкасында гаҗәпләнеп «Kha!» дип кычкырган тавыш ишетелә. Барысы да арбалар белән ныгытылган Шаһ Тимер ставкасының тирән канау һәм биек туфрак вал белән уратып алынуын аңлыйлар. Бу хәл Туктамыш гаскәрендә тагын да ныграк каушау тудыра: Аксак Тимер орышка бик нык әзерләнгән!

Исабәк. Шаһ Тимер үз тирәсен тирән канау белән дә ураткан, димәк...

Җанбай. Орышка әзерләнергә вакыты җитәрлек булгач!

Туктамыш *(ачулы)*. Шым торыгыз!

Ул арада ике илче болын уртасында очраша. Бер-берсенә кыска-кыска гына сүзләр әйтешәләр, күкрәкләренә кулларын куеп, баш иешәләр һәм атларын үз ставкаларына таба боралар. Туктамыш хан түземсезләнеп мыек очын чәйнәргә керешә. Чапкын ставкага әйләнеп кайта.

Туктамыш. Илме, яумы?

Чапкын. Яу, бөек каган!

Гаскәр бер мәлгә өнсез кала.

Туктамыш. Галәветдин сәет кайда?

Шаһ Тимер ставкасы. Шул ук вакыт

Шаһ Тимер каршына уллары һәм оныклары тезләнгән.

Гомәр шәех. Атабыз! Туран мәмләкәтенең бөек хакиме Шаһ Тимер! Без — угылларың вә оныкларың, сиңа мәңге тугрылыклы булырга һәм соңгы тамчы каныбыз җиргә тамганчы орышны ташламаска ант эчәбез! *(Кулындагы кылычын күтәреп эчә һәм саргытын җиргә түгә. Бүтән тугашлары да шулай эшлиләр)*.

Тимер. Антыгызны кабул кылдым, угылларым!

Уллары һәм оныклары, Шаһ Тимергә йөгенеп, үз урыннарына таралалар.

Тимер. Сәет Бәркә! Орышка фатиханы бирче. *(Аның алдына тезләнә һәм түбәнчелек белән баш ия)*.

Сәет Бәркә *(Кулын Шаһ Тимернең башына куя)*. Рәсүлебез галәйһиссәлам исеменнән фатихамны бирдем сиңа, Шаһ Тимер! Юлдашың Хызыр булсын! Атың абынмасын! Кылычың күгәрмәсен! Зиһенең томаланмасын. *(Җиргә иелеп бер уч туфрак ала һәм Туктамыш хан гаскәре ягына оч тапкыр сибә)*. Ягы качты! Ягы качты! Ягы качты! Ә хәзер, Шаһ Тимер, ялгызымны калдыр. *(Алдына намазлык җәя)*.

Шаһ Тимер тора һәм тәхетенә барып утыра.

Туктамыш хан ставкасы. Шул ук вакыт

Туктамыш *(ат өстендә)*. Орышка фатихаңны бир, Галәветдин сәет!

Галәветдин *(Туктамыш янына килә һәм аңа баш ия)*. Изге фәрештәләрнең амин дигән сәгатендә башланган орыш булсын, бөек каган! Хызыр юлдашың булсын! Кылычың авыраймасын! Күзең томаланмасын! Акылың зәгыйфьләнмәсен! Рәсүлебез галәйһиссәлам сиңа уңыш бирсен! *(Җиргә иелеп бер уч туфрак ала һәм аны оч тапкыр Шаһ Тимер ставкасы ягына таба сибә)*. Ул як качты! Ул як качты! Ул як качты! Җиңүеңне теләп, дога кылырга рөхсәт ит, бөек каган? *(Алдына намазлыгын җәя)*.

Дөнья матур, дөнья киңме?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

белгәч, нәкъ менә шул тирәдән эзләвемә шаккаттылар...

Әбиләрнең гәүдәгә ныгравы — Илдар әнисенең апасы (Фатыйма карчык) сүзгә кушылды. Бер-ике җөмләдән үк инде мин аның, җаны-тәне белән татар карчыгы булган хәлдә, күпмедер дәрәҗәдә «кыргыз әбисе» икәнлеген дә абайладым — телендә кыргыз сүзләре, кыргыз аһәңе мәңгегә сеңәргә өлгергән икән шул...

— Бик әйбәт, бик шәп иде тамыбыз (йортыбыз — Җ.Д.) Тирә-юньгә бер иде... Ә монда... Үзең күреп торасың... Без, ике карчык, бер бүлмәдә. Ике олан бар. Килен белән улыбыз. Алар яшьләр, яшьләрнең тормышы яшьләрчә. Без бит инде бик картлар. Тәһарәт аласыбыз да бар безнең, намаз укыйсыбыз да. Ә шәригать намаз укыганда каршыңда кеше тору түгел, мысыкны (песине — Җ.Д.) да уздырырга кушмый. Кабул кылырмы Аллаһ тәгалә намаз-гыйбадәтләребезне, белмим... Ә тамыбыз шәп иде безнең авылда, һай шәп иде!

Әбием тагын да дәвам итмәкче иде, Илдарның әнисе Хөснибикә карчык аны бик илтифатлы гына бүлдерде:

— Син сөйләвен бик дөрес сөйлисең дә, апам, дөреслекнең дә төрлесе була бит. Бар сөйләргә ярый торганы, бар ярамаганы... Күрәсеңме кунагыбыз кулындагы шырпы кабы кадәр генә магнитофонны? Без сөйләгәннәрне язып бара булыр ул...

Шушы урында әбиләр белән әңгәмәбез өзелде.

— Дөрес шикләнә әбиләр, — диде Илдар кырыс кына. — Каян белсен алар, бәлки син чыннан да КГБ кешеседер? Заманында һай куркыткан алар безнең әти-әниләр белән әби-бабайларны.

Илдарның сүзләре миңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте.

Әбиләрне башка сөйләштерә алмадым. Максатым Илдарның әти-әниләре, әби-бабаларының язмышын якыннанрак белү булганга, морадыма ирешә алмыйча, кәефсезләнеп кайтып китәргә мәҗбүр булдым.

Ярты ел чамасы гомер узгач, яныма Рафикъ килеп чыкты. Әбиләрем бу юлы үзләре чакыртып җибәргәннәр, күтәрә алган кадәр магнитофон тасмасы алырга кушканнар...

... Бу килүдә инде әбиләремә йортның беренче катында бушаган бүлмәне биргәннәр, шунда үзләренчә гомер кичеп яткан көннәре иде.

Суфия ханымда ниндидер сәер үзгәреш мине сагаерга мәҗбүр итте. Очкан шәпкә тимерчыбыкка бәрелеп төшкән кошчыкны хәтерләтә иде ул. Соңрак белдем: Кыргызстанга әти-әнисе янына кайтып килгән, күңеле шуннан кузгалып калган икән...

Теге юлы өзелеп калган әңгәмәбезне Фатыйма әби үзе дәвам итте:

— Әйе, тирә-юньдә тиңе юк иде тамыбызның. Бабай нык холыклы, нык куллы кеше иде, урыны оҗмахта булгыры. Кыз-уллары күп булса да, арадан әтиебез Борһанетдинне аеруча яратты. Ятрарлыгы да бар иде. Әтиебез озак еллар патша хезмәтендә булды. Айлардан алып елларга кадәр йорттан югалып торыр иде. Ул кайтып киткән саен без балалар да ишәя тордык. Хезмәтен тутыргач, авылга беректе. Күрше урыс авылының җирләре күп иде. Үзең беләсең, без — татарларга җирне бик аз, анда да иң начарын гына бирәләр иде бит. Урысларның җире күп, әмма бик эшлиселәре килми. Шул урыслар белән бик дус иде безнең әти. Телләрен урысларның үзләреннән ким белмәс иде. Әти шулардан берәрсенең җирен алыр иде дә уртакка чәчәр иде. Без бөтен йортыбыз белән барып эшләшер идек. Менә шулай тырыштык без, менә шулай эшләп бай булдык. Теге тамны да нәкъ менә шуның өчен әтиебезгә биргән иде бабабыз...

Әңгәмәгә Хөснибикә әбиебез дә кушылып китте.

— Менә шулай матур гына яшәп ятканда революцияләр, колхозлашулар, хәллерәк кешеләрнең байлыгын талап, үзләрен үтерү, сөрүләр башланды... Заһретдин абыебыз, моның азагы хәерле булмаячак, үзем барып урнашуга, сезне дә алдырырмын, Аллаһ боерса, дип, Кыргызстандагы туганнар янына чыгып китте. Әмма безне кайтып алырга өлгерми калды.

Шуннан соң инде әңгәмәне азагына кадәр Фатыйма әби алып барды.

— Шулай җәйге кыр эшләре кызган чиллә бер көн иде. Басуда эшләгән олылар яныннан бик каты чоркап (йөгереп — Җ.Д.), ишек алдыбызга күрше малае килеп керде. «Ниндидер кешеләр Борһанетдин абзыйны канга батырганчы кыйнадылар анда. Тагын кемнәрнедер тотып, барысын бергә чиркәүгә илтеп ябачаклар», дип хәбәр итте ул.

Без аңга килеп өлгергәләгәнче, ишек алдыбызга коралды кешеләр кереп тулды. Китте кычкырыш, китте елаш... Бөтен мал-мөлкәтебезне язып, ишеккә мөһер салдылар да үзебезне урамга куып чыгардылар. Авыру әнебезне дә ишек алдындагы сарайда озак яткырмадылар, әти янына илтеп яптылар. Тагын берничә көннән безне — әнине, мине, сеңлемне, җиңгәбезне, әти белән бергә чиркәүгә ябылган ирләрне һәм безнең кебек бик күпләрне озын утын арбаларына тәяп, Кама Тамагына озаттылар. Анда берничә көн мәктәп бинасына ябып асрагач, пароходка утыртып, Тәтешкә алып киттеләр. Тәтештән — сыер вагоннарында Магнит шәһәренә...

Анда баруга, бихисап баракларның берсенә урнаштырдылар. Абзардагы хайваннар кебек көтүебез белән бергә яшәп, иртә таңнан көтүебез белән эшкә йөри башладык. Безгә, җитлегеп кенә килгән кыз балаларга күп кирәкмени?! Эттән дә болайрак арып, кара төндә кайтып егылабыз, саташулы йокыдан арына алмыйча, таң беленүгә үк торып эшкә китәбез. Эшкә дип әйтергә генә җиңел. Атка да күн белән тышланган камыт киертәләр. Ә безгә аркага төяп кирпеч ташу өчен көйләнгән тимер камытлар киертәләр иде. Бел, улым, заманасында сезнең журналист халкы дан җырлаган Магниткалар безнең кебек кавырсыны да ныгып җитмәгән үсмер кызлар һәм малайлар, илләреннән сөрелгән, туган нигезләреннән куып җәберләнгән ирләр-хатыннар, карт-карчыклар, гомер бакый зиһен көче белән гомер кичкән зыялылар иңнәренә таянып, еш очракта сөякләре өстендә үсте...

Фатыйма әби бер мәлгә тынып калды. Керфегенә эленгән сыңар күз яшен яулык очы белән корытты.

— Ничек исән кала алдыгыз соң сез ул тәмугтан, ничек исән-имин чыктыгыз?

— Монда килүгә, Кыргызстандагы абыйга хат яздык. Ул чакта инде әниебез вафат, җиңгәбез өзлегеп урынга егылган, хәл эчендә ята иде. Абыйдан хат тиз килде. Бераз гына түзегез, кирәк кадәр акча юнәтүгә, килеп, ничек тә сезне моннан йолу ягын карармын, дигән. Бу сүзләрне укыгач, җиңгәбез терелеп тә киткән сыман иде. Әмма озак тормыйча, дөнья куйды. Аның артыннан ук әти аяктан егылды. Монысы инде безнең өчен дөнья бетү белән бер иде. Тыныч, сабыр әтиебез күзгә күренеп көйсезләнде, барак һавасына ярамый башлады. Янында күбрәк мине тота торган булды. Ишегалдына алып чыкканчы шыбыр тиргә төшә, аз гына утыруга, туңа башлый. Чыккандагыдан да ныграк интегеп, кабат барак эченә сөйрәләбез. Шулай беркөнне икенчеме, өченчеме тапкыр әйләнеп кергәч, әти тагын һавага алып чыгарга кушты. Соңгы көчемне җыеп, урынынннан гына кузгата башлаган идем, эчендә нидер өзелгәндәй шыртлап куйды да, әти бөтенләй тынсыз калды, үзе дә өзелде. Елыйм, ялварам, илереп ярдәмгә чакырам. Әмма бар халык эштә, икең берьюлы үлеп ятсаң да, хәл белер кеше юк... Шулай кич җитте, сеңлем эштән кайтты. Урынга менеп, икебез әтинең ике ягына яттык. Юк, керми йокы. Яңагымны акрын гына әтинең салкын яңагына тидереп алам, җан кереп китмәсме, дим...

Бригадир дәштергәндер инде, иртән мулла килеп җитте. Безнең күрше авыл кешесе булган икән, таныды әтиебезне. Безне юатыр сүзләр эзләп азапланмады — моның мәгънәсе югын яхшы белә иде. Озак кына дәшми торганнан соң дога укып, китеп тә барды.

Бераздан ниндидер кешеләр колаша белән килеп, әтинең җеназасын күтәреп киттеләр. Артларыннан сеңлем белән без дә иярдек. Бараклардан хәйран ук ерак киткәч, урман буенда янә баракка охшаган галәмәт олы икенче бер корылма янына килеп җиттек. Шушы тирәдә генә зират бардыр, дип уйлаган идек, алай булып чыкмады. Әтине колашадан төшереп, эчкә алып кереп киттеләр. Ишектән килеп керүгә, йөрәгем туктап калгандай булды — корылма эче янәшә тезеп салынган мәетләр белән тулы иде. Ир-ат гәүдәсе дә шунда, хатын-кызныкы да... Бер үсмер кыз мәете өстеннән япмасы төшеп, ярымялангач хәлдә ята. Әмма игътибар биргән кеше юк... Йа Раббым, соңгы юлда мөселман мәете өчен моннан да олырак мәсхәрә булуы мөмкинме?! Әти гәүдәсен шуның янәшәсенә үк диярлек буш урынга салдылар да ишеккә юнәлделәр. Юлда сөйләшә болар, ә ни сөйләшкәннәре аңыма барып җитми:

— Барак тула язган икән инде, иртәгәдән дә калмый җыеп күмәрләр...

— Күмми ни... Әнә теге урман эченнән атнага бер күтәрелгән сасы төтенне бер дә иснәгәнең юкмыни?! Барысын бергә шунда ташып өяләр, өсләренә ниндидер дару сибәләр дә...

Мин аларның башка сүзләрен аңларлык хәлдә түгел идем инде.

...Заһретдин абый сүзендә торды. Юлга җитәрлек акча юнәтүгә, безнең янга килеп төште, күршеләребезгә үзен авылдашыбыз дип таныштырды. Йөреп килергә алып чыккан булып, безне стансага алып килде дә, товар вагонына яшереп, Кыргызстанга алып китте. Яши торгач, килеп тотарлар, дигән куркыныч кимеде, без тыныч кына көн күрә башладык. «Булса да сезнеке, булмаса да — сезнеке!» — дип, абый безгә бер башмак тана, кош-корт алып бирде. Игелекле булып чыкты малкаебыз, ел саен бер бозау китерә башлады. Ишек алдыбызда кош-корт та ишәйде.

Абыйның дус кибетчесе бар иде. Ул, кибетен абыйга калдырып, каядыр китеп барды. Шулай итеп, без кабат аякка бастык, янә бай булып киттек.

Көннәрнең берендә абый янына тәбәнәк кенә буйлы, галәмәт таза бер урыс милиционеры чоркап килде. Тиз-тиз генә абыйның колагына нидер пышылдады да, кул кысышып, китеп тә барды. Әмма мин аны танып калдым — безне Тәтештән Магниткага кадәр озата килгән иде ул.

Абый әйтә:

— Беләсезме, миңа бу милиционер ни әйтте? Аны монда безне эзләргә җибәргәннәр. Кайсыдыр бер авылдашыбыз, илгә кайтырга насыйп булганы, безнең шушы тирәдә яшәргә тиешлекне әйткән, имеш... Курыкмый гомер кичерегез, Татарстанга кайткач, сезне монда юк, дип хәбәр итәчәкмен, диде...

Бар бит әле дөньяда игелекле кешеләр! Без ул урыс милиционерына бүген дә рәхмәт укыйбыз, бүген дә аның рухына гыйбадәтләр кылабыз...

Менә шулай, балам. Бу дөньяда күпме гомерем калгандыр, белмим. Күргәннәремне калган гомерем түгел, яшәгән гомерем буена сөйләсәм дә бетәрлек түгел. Бәгырьләремне көйдергән йөрәк ялкынымны ничекләр генә басармын да, кешеләргә ничектер генә сөйләп бетерермен аларны...

Ә теге, элеккеге тамыбызга килсәк, безне озаткач ук сүтеп, таратып бетергәннәр аны... Бер өлешеннән балалар бакчасы күтәргәннәр, зур өлешен Кама Тамагына күчереп, милиция идарәсе иткәннәр, аннан соң да ниндидер бер начальник, сүттереп, кайсыдыр бер авылга илтеп күтәрткән диме шунда...

Туздырылган нигез... Имгәтелгән язмышлар... Тән табиблары турында язарга җыенып та, җан тынычлыгына, җан җылысына мохтаҗ милләттәшләренә юлыккан чарасыз каләм иясе...

Ниләр генә әйтеп юатыйм соң мин сезне, газиз әбекәйләрем? Җан җәрәхәтләрегезгә шифа булырдай нинди дәвалар табыйм? Ни хәлләр итим, юк бит алар миндә, юк... Күпме генә эзләсәм дә, табалмам мин аларны. Нинди генә җылы сүзләр табып әйтсәм дә, юаталмам шул мин сезне, юаталмам... Бары изге теләктә генә кала алам: Ходай сезгә җан тынычлыгы бирсен, иман нурыннан, үзенең рәхмәтеннән ташламасын. Ахирәттә сезнең өчен оҗмах ишекләрен киң ачсын, урыныгызны җәннәтнең түрендә кылсын, җир тәмугында бәгырегезне көйдергән язмыш утыгызны Кәүсәр чишмәләре сүндерсен. Амин, шулай булсын!

Илдар әфәнде! Суфия ханым! Сезне юатырга шулай ук сүзләрем юк минем. Юанычыгыз — хезмәтегез, шифалы кулларыгыздан вә сихәтле сүзләрегездән дәва тапкан рәхмәтле районадашларыгыз, бәхетегез — мәхәббәтегез, куанычыгыз — сәламәт, тәүфыйклы, шәфкатьле балаларыгыз булсын!

Әнә, ишетәсезме, радиодан көй агыла. Талпынып-канатланып, ир-ат җырлый:

Дөнья матур, дөнья киң!

Бәлки улыгыз Наил, кызыгыз Әклимә өчен шулай матур, шулай киң булыр ул дөнья!

Авылы барның кавеме бар

«Алга»лар алга атлый

Быел Апас районының «Алга» колхозында һәр гектардан 23 центнер икмәк җыеп алдылар. Кукуруз һәм бәрәңге уңышы да начар түгел. Колхоз рәисе Р.Гыйсмәтуллинның сүзләренә караганда, хуҗалык кышкы чорда терлекләрнең санын киметмәячәк. Шулай булгач, киләсе елда ит һәм сөт продукциясенең күләме дә кимергә тиеш түгел. Хәзерге вакытта авылда бер дигән мәдәният сарае һәм терлекләр өчен кышкы абзар төзелеп килә. Колхоз идарәсе авыл хезмәтчәннәренә яңа йортлар күтәрүдә дә зур булышлык күрсәтә.

Өстәге рәсемдә яңа абзар күтәрүдә армый-талмый эш күрсәтүче уңган балта остасы Петр Чернов, уңда — алтын куллы механик Садрислам Сәмигуллин. Яңгырява дип тормый ул — кайчан карасаң да гел басуда. Астагы рәсемдә: сулда сез колхоз рәисе Ринат Гыйсмәтуллинны күрәсез. Уңда — терлекче Әлфия Вәлиуллина.

Шәһитләрнең шаһиты...



Кеше гомере — изге, һәйкәл халәтенә тиң мизгел. Әмма һәйкәлләр мәңгелеккә төбәлә...

Кемнәндер, кайчандыр ишеткән идем: һәйкәлләр — шәһит киткәннәрнең өнсез шаһиты. Ә инде үземнең дә һәйкәл хәтле һәйкәл туу — монумент туу мизгелләренең бер шаһиты була алуымны күз алдына да китереп караганым юк иде.

Мизгел, дидем мин. Ә бит скульптура тарихын ишетеп-күзәтеп беләбез: һәйкәлләр, гадәттә, шактый озак, еллар дәвамында туалар, моның өчен кайчак дистә еллар, дистәләрчә еллар кирәк була.

Менә мин дә башта шундыйрак уйда йөрдем: Казан скульпторы Асия Миңнуллина иҗат иткән монумент-һәйкәл кайчан да булса бер калкып чыгар, әмма бу хәл әле бигүк тиз арада гына булмас, һәйкәл ачылу тантанасы безнең гомерләргә житешмәс, дидем. Аннан соң, әле тагын шунысы да күңелдә бер шик уятып йөрде: Казанда бер-бер һәйкәл, йә булмаса монумент әзерлисе-куясы булса, моның өчен скульпторны гел читтән — Мәскәүдән яки Санкт-Петербург кебегрәк шәһәрләрдән чакыру гадәте бар иде. Моның мисаллары бездә шактый.

Әмма бу юлы фал китабы үзенең битләрен башкачарак ачты: Әфганстанда һәлак булган сугышчылар истәлегенә салыначак монумент-һәйкәлнең проектына 1989 елда уздырылган конкурста Казан скульпторы Асия Миңнуллина җиңеп чыкты. Һәм, менә шул рәвешле, Асия Казан шәһәренә гаҗәеп үзенчәлекле бер һәйкәл бүләк итте, үзенә янә дә иҗат газаплары, йокысыз төннәр тапты, ә инде миңа, әйткәнемчә, һәйкәл туу мизгелләрен күрү бәхетен бирде.

Рәссамны мин күптәннән беләм, аның иҗат баскычларын, үсеш юлларын күзәтеп киләм. Ул үзе, 1984 елда В.Мухина исемендәге Ленинград сәнгать академиясен тәмамлап, Казанга кайтты. Һәр рәссам өчен иҗат остаханәсенең иң изге бер урын икәнлеген аңлатып тору да кирәкмидер. Ә Асиянең исә берничә ел дәвамында үз остаханәсе дә булмады. Әмма бу хәл аның иҗат омтылышын, иҗат дәртен сүндерә алмады. Рәссамнар берлегенең Переславльдәге иҗат йортында берничә тапкыр булып, ул аннан яңадан-яңа әсәрләр белән кайтты.

Һәр иҗат кешесен аның остазыннан, укытучысыннан аерып карап булмый. Танылган рәссам, Татарстанның халык рәссамы Васил Маликов Асиядә нәкъ менә скульпторлык сәләтен үз вакытында күреп ала, аңа һәрьяклап ярдәм итә. Хәтта үз остаханәсендә эшләү, иҗат итү мөмкинлеген тудыра. Кем белә, нәкъ менә шундый иҗади аралашу (әлегә шартлыча) Казан скульптура мәктәбе дип аталырга хаклы бер юнәлеш барлыкка китергәндер.

Бәхеткә дип әйтимме, Асиянең иҗат юлында янә дә бер оста, остаз пәйда була. Укучы һәм остаз — фәлсәфи мәсьәлә. Укучы, өйрәнүен-камилләшүен тагын да дәвам итеп, үзенең өйрәнчеклегеннән арынса да, остазына хөрмәт һәм рәхмәт йөзеннән тагын да үсәргә тиеш. Әнә шул рәвешне аңлаткан тагын бер остазын таба Асия. Ул — өлкән буын вәкиле, атаклы скульптор Дмитрий Рябичев, күптән түгел вафат булды. Мәскәү, Ташкент кебек шәһәрләрдә, Германия һәм Һиндстан кебек илләрдә калыккан зур-зур монументлар авторы Рябичев та Асиядәге сәләтне күреп ала, аңа үз остаханәсенең ишекләрен ача.

Ә хәзер, Асиянең үзе белән бераз таныштырып үткәннән соң, аның әлеге дә баягы конкурста — Әфганстанда һәлак булган сугышчылар истәлегенә салынган монумент проекты конкурсында җиңгән әсәре турында сөйлисе килә. Үзенчәлек. Сәләт. Тарихны һәм киләчәкне дөрес күзаллау, дөрес аңлау — аның иҗатына үтә дә хас. Асиянең бу һәйкәле — яшел килеш өзелгән яфраклар хакында.

Монумент, һәйкәл, хәбәрдар кеше аңлыйдыр, иң элек остаханәдә туа. Рәссам-скульптор өчен остаханә, кабатлап әйтәм, изгеләрдән изге бер урын. Асиянең дә иң изге хисләре башта проект булып остаханәдә туды. Гипста эшләнде. Юк, ялгышам икән — иң беренче булып, ул аның йөрәгендә-күңелендә туды!

Бу монумент-һәйкәл Декабристлар урамында газета-журналлар нәшрияты янында калкачак, диләр. Асиянең бу яңа әсәрендә гади күзгә ташланмаган зур бер үзенчәлек бар: монда — авторныңмы, әллә әсәренеңме беренчел булуын аеру кыен.

Һәрхәлдә, бу монумент тиз арада калкып чыксын иде, Казанны, Татарстанны, аның кунакларын уйландырсын, һәрберебез өчен ачы гыйбрәт булып калыксын иде...

Лилия САТТАРОВА,
сәнгать белгече.

Әлеге дә баягы

Ачык хатка җавап

«Мәдәни җомга» газетасының 3 нче санында басылган ачык хатның эчтәлеге белән тулысынча килешәм. Әйе, республика яшүсмерләр китапханәсе үзенең изге эшен дәвам итәргә тиеш. Бүгенге авыр чорда безнең банк балаларга дөрес тәрбия бирү эшендә кулыннан килгәнчә булышлык күрсәтә. Әмма бу очракта банк кебек, зур акча белән эш итә торган оешма эчендә күпсанлы укучыларны кабул итә торган китапханә булу һич мөмкин хәл түгел. Без моңа катгый рәвештә каршы. Банк алдында китапханәне килешү нигезендә икенче бинага күчерү бурычы тора иде. Бу мәсьәләне банк идарәсе тиешенчә хәл итәргә тырышты. Без О.Кошевой урамында урнашкан элекке 183 нче балалар бакчасын китапханә итәргә уйлаган идек. Банк шушы бинаны төзекләндерү эшен дә үз өстенә алырга әзер иде. Кирәкле күләмдә акча билгеләнде. Дәүләт милке комитетыннан әлеге бинаны китапханәгә бирергә ризалык алынды. Ләкин бу тәкъдим китапханә мөдире тарафыннан кире кагылды. Әлеге бина китапханә эшчеләрен канәгатьләндермәү сәбәпле, банк башка юлларны эзләргә мәҗбүр булды.

Китапханә өчен тагын ике урында биналар тәкъдим ителде: берсе — «Соцгород» тирәсендә, икенчесе — 2 нче Горки микрорайонында. Әмма бу очракта да безнең тәкъдим ошамады. Яшүсмерләр китапханәсе тиешле рәвештә эшләсен өчен аның хезмәткәрләре уңай фикер йөртсеннәр һәм дә бу мәсьәләне тиз арада хәл итү ягында торсыннар иде. Бүгенге көндә аларда мондый теләк бик сизелми әле. Банк үз мөмкинлекләреннән чыгып, әлеге эшкә шактый күләмдә матди ярдәм күрсәтергә әзер.

Ихтирам белән, «Ак Барс» банкы идарәсе рәисе Т.АБДУЛЛИН.

АЧЫКТАН-АЧЫК

Заһид МӘХМҮДИ

БҮРЕНЕ БҮРЕККӘ САЛМАГЫЗ



Һәй бу җәйне! Шәһәр урамына чыгуга, башлар әйләнеп китә. Гаҗәеп матур чәчәкләр болынына килеп кергәндәй буласың. Ул Бауман урамын әйтәсе дә юк инде. Тирә-юньдә берсеннән-берсе дилбәр кызлар, хатыннар бутала. Ул алардан килгән тәмле хушбуй исләре! Ул аларның йөрешләре! Киенүләре дә бит авылча гына түгел, үтерәләр инде, пәрәме үтерәләр. Ирексездән, яшьтәшем Такташ бабайның бер шигыре искә килеп төшә мондый чакларда. Әйе, көчлиләр безне кызлар, кычкыртып көчлиләр. Шулай урам буйлап үзеңне күмеп киткән матурлыкка сокланып барасың-барасың да, иртәрәк өйләнеп ташладым, ахры, дип сыкранып куясың. Юкса, әлләни үкенерлек нәрсә дә юк инде, чүтеки, кырыкка житеп килӛм бит. Минем тормышта да булды бит мондый матурлар. Берәү генә түгел хәтта, берничә. Ихластан әйтеп ташладым инде, гафу итәрсез. Калмады, берсе дә калмады: ул йолдызлы төннәр, яшел чирәм, мунча идәне, баскыч аслары, подваллар. Барысы да истә. Мин дә бит табигать баласы. Гөнаһларым, кем әйтмешли, башлар Себер китәрлек. Баш бетереп чапкан чаклар булды хатын-кыз артыннан. Заманында алар өчен Америкага кадәр җәяү барырга әзер идем мин. Ә урам чатындагы сот кибетенә барып кайтырга кирәк булса, җәмәгатем белән әрләшеп бетә идек. Ирендерә шул фани дөнья мәшәкатьләре.

Матурлык артыннан чабу күпме дәвам иткән булыр иде, белмим, әмма бер вакыйга мине кинәттән генә айнытып җибәрде. Баскыч астында сайрашкан чәчбием «күкеле сәгать» бүләк итеп китмәсенме. Ирләр әлеге авыруны борынга төшкән томау белән генә чагыштырырга яратсалар да, шактый мәшәкатьле, борчулы һәм давыллы нәрсә булды ул. Иң куркынычларыннан саклады үзе Ходай. Безнең заманда, ичмасам, сифилис дигәннәре сирәк очрый иде, СПИДтан да курыкмадык, чөнки ул юк иде әле. Нәрсә генә дисәгез дә, мин иң бәхетле торгынлык еллары баласы. Ә бүгенге яшьләр чын мәгънәсендә бәхетсезләр. Илдә демократия җилләре исеп киткәч, дөнья шундый буталды, шундый бозылды, хәтта бер генә хатын-кызга да ышаныч калмады. Хәер, хатын-кызлар да безнең турыда шул фикердә бугай. Карап торышка инсафлы, тәүфыйклы гына булып күренгән авыл баласы да төп башына утыртырга мөмкин. Иманым камил, үсеп килүче яшь буын бездән әлләни алга китә алмады, ул да безнең гамәлләрне кабатлап үсә кебек. Ул да йолдызлы төннәрдән, баскыч асларыннан, подваллардан башка яши алмый. Бу -- тормыш канууы. Күпме генә вәгазь укыма, тиле яшьлек барыбер үзенекен итә инде. Тиле дигәнгә ачуланмагыз. Тәҗрибәсезлеге белән тиле ул. Хатын-кызның серле назын тоеп карар өчен күпме яшьләр төрмәгә утыра. Аларны берни дә туктата алмый. Чөнки җенси хис шундый көчле һәм хайвани була ки, әллә нинди зур түрәләрне дә бөгеп сала ул. Хатын-кыз дигәндә, министрлар да кәнәфиләреннән очкан очраклар азмыни? СПИДны да уйлап бирми яшьләр. Төкерәләр алар синең презервативыңа. Балаларыбыз егерменче гасыр чумасыннан кырылып бетмәсен дисәк, без аларны, һәм шул исәптән үзебезне дә, саклап калу юлларын эзләргә тиешбездер. Миңа калса, моңа ирешүе әллә ни авыр түгел. Әйтсәм әйтим инде, рәсми рәвештә фәхешханәләр ачкан тәкъдирдә, без берьюлы берничә мәсьәләне хәл итә алырбыз кебек. Шәһәребездә тән сатып акча эшләүче кыз-кыркын саны елдан-ел арта бара. Араларында әллә нинди азаулы фахишәләрне уздырып җибәрә торган унөч-ундүрт яшьлекләре дә җитәрлек. Менә шулар тарата да төрле авыруларны. Берәүләрен эшсезлек, икенчеләрен җиңел яшәргә теләү, өченчеләрен табигатьләре мәҗбүр итә торгандыр, дип беләм. Ләкин җенси якынлыкны бозыклык дип уйлаучыларга мин каршы чыгам. Ник дигәндә, ул ашау-эчү кебек үк табигый нәрсә дип беләм. Укып беләсездер инде, кияүдә булмаган хатыннар аеруча явыз һәм төрле авыруларга бирешүчән була. Вакытында ашамаган кешенең ашказаны авырткан кебек, җенси тормыш күрмәгән кеше дә дөм сәламәт була алмый. Гете сиксән яшендә унҗиде яшьлек кызга мәхәббәттә аңлашкан икән, моның өчен аны бозык дип һич кенә дә әйтә алмыйбыз. Киресенчә, мең мәдхия аңа. Димәк, үзен саклаган алман карты. Ә үзеңне саклау өчен режим белән яшәргә кирәк! Әхлаксызлык бөтенләй башка нәрсә ул. Әйтик, гайбәт, караклык, кеше үтерү, күтләклек һ.б. Ходай безне хатын-кыз белән мәңгегә бәйләгән. Мәңгелек ярату хисе салган ул безнең күңелләргә. Игътибар иткәнегез бардыр, ир кеше ир заты ашаган тәлинкәдән дә ашарга җирәнә, ә беренче очрашуда, танышуда ук хатын-кызны үбүдән тартынмый.

Фахишәләр турында сөйли башлаган идем бит. Бу үҗәт «сыйныфны» медицина күзәтүе астына алып, рәсми фәхешханәләр ачсаң, алар да, тилмереп йөрүче аерым ирләр дә бик канәгать булырлар иде, могаен. Аннары инде яшьләр дә, хатын-кызны көчләп, төрмәгә утырмаслар иде. Акчаны түлә дә, вәссәлам. Мондый яшьләрнең үзләрен дә «казык»ка утырталар төрмәдә. Бу инде ир кеше өчен үлем белән бер. Өлкәннәр өчен дә бик ярап куяр иде кебек бу күңел ачу йорты. Бер хатынга гына канәгать булып яшәгән ирләрне белмим мин. Бик шикле күренә, андыйлар. Бүрене бүреккә салсаң да, урманга карый, дигәндәй, ирләрнең күпчелеген барыбер «уҗымга» тарта. Әлеге дә баягы мәшһүр шагыйребез Такташ иркәләнер өчен чәчтарашка йөргән булса, мин фәкыйрегез наз күрер өчен фәхешханәгә йөрер идем, егетләр. Сәламәтлек турындагы белешмәм паспорт кебек үк һәрвакыт кесәмдә йөрер иде. Мине кабул итәчәк фахишәдә дә шундый ук белешмә булырга тиеш, әлбәттә. Һич шигем юк, минем әлеге язмама каршы чыгачак ирләр дә кача-поса гына булса да (акчалары булса) барачаклар анда. Мондый йортлар да ашханә, чәйханә кебек үк гадәти нәрсәгә әверелергә тиеш. Секстаң беркая да китеп булмый. Бөек алман фәлсәфәчесе Ницше әйтмешли, дөньядагы бөтен нәрсә дә секска буйсындырылган — тормыш, әдәбият һәм сәнгать, хәтта техника да. Бар нәрсә дә кешегә, аның югары идеалларына хезмәт итәргә тиеш. Хәтта фәхешханәләр дә.

Алга киткән күп кенә илләрдә фәхешханәләр закон тарафыннан тыелмый. Алай гына да түгел, ирләр өчен мондый күңел ачу йортларында булу дәрәҗә санала. Мисал өчен, Японияне генә алыйк. Анда ирләр өчен махсус фәхешханәләр эшли икән. Күптән түгел генә үзәк телевидение тапшыруларының берсендә бер япон хатыны интервью биргән иде. «Гаилә -- изге нәрсә, -- диде ул. -- Анда секска урын булырга тиеш түгел. Без кыз балабызны уртага салып йоклыйбыз. Мин ирем белән ундүрт айга ике генә тапкыр йокладым». Менә сиңа Япония! Анда хатыннар ирләрен фәхешханәгә үзләре әзерләп җибәрәләр. Яхшылап ял итсен өчен. Ә ял иткән ир акчаны эшли белә инде ул. Японидә гейша һөнәре (безнеңчә фахишә була) иң дәрәҗәлеләрдән санала. Ул матур киенә, матур бизәнә белү өстенә назлы, акыллы һәм белемле әңгәмәдәш тә булырга тиеш икән. Тик менә япон хатынының ире белән ундүрт айга ике генә тапкыр булуы бик аңлашылып бетмәде. Безнең хатыннар риза булмас мондый җәзага.

Фәхешханәләр ачу белән бергә без табигать тарафыннан кимсетелгән кешеләрнең проблемаларын да хәл итә алыр идек. Бу вафасыз һәм мәрхәмәтсез дөньяда хатын-кыз заты белән танышырга оялучы янсә моңа мөмкинлеге булмаган гарип кешеләр дә бар бит.

Казан каласында «Интим» кибете ачылгач, матбугатта кискен генә язмалар дөнья күрде. Янәсе, барып җиттек, мөселман җирендә әхлаксызлык чәчәк ата! Юк, җитәр, әхлаксызлык түгел бу. Үзебез турында гына уйламыйк әле. Әлеге кибетләргә йөрүчеләрнең күпчелеге ялгыз хатыннар һәм ирләр, гариплар. Бу кибеткә беренче тапкыр килеп кергәндә миндә дә җирәнү хисе уянган иде. Андагы ясалма җенси әгъзалар, табигый булмаган юл белән җенси рәхәтлек алу кораллары бездәй сәламәт кешеләрнең күңелен кайтара инде. Ә бу нәрсәләргә кемнәрдер бик тә, бик тә мохтаҗ. Резинадан эшләнгән, кабартыла торган «хатын-кызлар» һәм «ир-атлар»ның ни өчен шулай популяр булуын да аңлатып торуның кирәге юктыр дип уйлыйм. Ничәмә-ничә еллар төрмәдә утыручы мәхбүсләр дә кеше бит. Аларның да үз ихтыяҗлары бар. Минемчә, мондый кабартылган «хатыннар» армиядә дә булырга тиеш. Үземнән беләм. Торгынлык елларында мин ГДРда хезмәт иттем. Совет солдатлары немец кызларын һәм хатыннарын көчләгән чаклар аз булмады. Шуңа күрә дә безнең чәйгә, җенси хис уянмасын өчен, офицер хатыннарын көчләмәсен өчен (барыбер көчләделәр) бром салалар иде. Гаҗәп хәл, армия сафларында ике ел хезмәт итү дәверендә мин төшемдә бер генә тапкыр да хатын-кыз күрмәдем. Дөрес, соңгы ике-өч айда бромлы чәйне эчми башлагач, уйда гел хатын-кызлар гына була башлады. Менә шулай җәзалады, агулады һәм гариплəде безне совет системасы. Бромны аны сексуаль маньякларга гына эчертәләр. Свердловски өлкәсендә учебкада курсант булып йөргәндә хатын килгән иде. Анда да урын бирмәделәр. Һәм ярый әле бирмәгәннәр. Чөнки импотент идем мин ул вакытта. Без, курсантлар, барыбыз да импотент идек. Бу турыда «Бозык кеше язмалары» ...гән кыйссамда тәфсилләп язып чыктым инде мин.

Ходаем, бәлки укучым алдында мондый ук ихлас булырга кирәк тә булмагандыр. Әмма ишлисең бит, Казан подвалларында, баскыч асларында, аерым карчык-корчыклар тотучы «блатхаталар»да яңа Хиросима, Нагасакилар туып килә. СПИД атом бомбасы кебек кенә булмас, ул безне астыртын гына гүргә өстери. Бүгеннән үк аның юлын каплый башламасак, иртәгә соң булмагае.

Тарихның кара битләре

Б.Султанбеков. «Сталин и «татарский след». Казань. Татарское книжное издательство, 1995, 250 стр.

Урыс шовинистларының өндә дә, төштә дә хыяллана торган бер нәрсәсе - - башка халыкларны бетереп, ассимиляцияләп, тик бер милләт итеп кенә калдыру. Әлеге рәсми доктринаны халыктан яшермәделәр дә.

Заманында Россия империясенең мәгариф министры граф Д.Толстой: «Безнең төп бурычыбыз - - барлык халыкларны да урысландыру, урыска кушу», - - дип язган. Совет чорында исә бу сәясәт «киң фронт итеп» алып барылды. 50 ел эчендә илдәге 194 милләтнең 93е юкка чыкты. Һәм бу сәясәт рәсми төстә тормышка ашырылды: «интернациональ дуслык» хакына милли балалар бакчалары, мәктәпләр ябылды, алар урынын урыс уку-тәрбия йортлары алды. Моны Татарстан мисалында да ачык күрергә була. 70 нче еллар башына Казанда, башка шәһәрләрдә, район үзәкләрендә бер генә татар балалар бакчасы, мәктәбе дә калмады диярлек. Татар, бөтен илгә таралып, урысланырга мәҗбүр ителде.

Татарстанда ике дәүләт теле турында рәсми документ кабул ителсә дә, ул әлегә тормышка ашудан ерак тора. Тарихчы-публицист, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Булат Солтанбековның яңа чыккан «Сталин и «татарский след» исемле китабында кансыз тиранның милли зыялыларны, халкыбызның иң затлы шәхесләрен юк итү сәясәтен ничек итеп тормышка ашыруы мисаллар белән дәлилләнә. Бу язмаларны укыганда күңелне авыр хисләр биләп ала. Гитлерның кем икәнен аңлатып торасы юк. Әмма ул үзенең фашистларына кул күтәрми, үз идеологияләреннән баш тарткан коммунистларны, социалистларны да ярлыкый. Ә Сталин коммунизм төзүгә инанган миллионнарча ил улларын, кызларын -— алтын генофондны юк иткән. Шулай да татар, башкортка карата аның нәфрәте аеруча көчле булган. Татарстан, Башкортстан милли зыялыларын ул моңа кадәр күрелмәгән кансызлык белән бетергән. Иҗат әһелләренең 90 процентка якыны кискәдән аша (урысларда - - 10 процент) үткәрелгән. Монда дини фактор да роль уйнаган булырга кирәк. Сталин Ислам динен гомумән куралмаган. Өстәвенә әле, шул Ислам ярдәмендә 400 еллык коллык дәверен кичеп тә, татар, башкорт милләт буларак сакланып калган.

«Сталин и «татарский след» китабында 17 очерк тупланган. Аларның һәммәсе дә бик әһәмиятле, совет чорында татар халкы кичергән фаҗигането асылын күзалларга булыша. Шуларның берсе - - «Эхо выстрела у Лядского сада» дип атала. Сталинның иң яраткан алымнарыннан берсе провокация була. Бу очракта Татарстан хөкүмәте башлыгы Сәетгалиевкә «һөҗүм ясала» һәм «ул очраклы рәвештә генә исән кала». Шуны сылтау итеп, республиканың бик күп җитәкчеләре, хәтта эшчеләр дә кулга алына. Моның сере тик 1937 елда, Сәетгалиев төрмәгә ябылгач кына ачыклана: әлеге провокация турыдан-туры Сталин кушуы буенча оештырыла.

Революциягә кадәр дә, революциядән соң да Ильяс Алкин исеме күпләргә таныш була. Ул, ленинизм идеясенә чын күңелдән бирелгән кеше буларак, коммунизм тагән кеше буларак, коммунизм татар милләтенең чәчәк атуына китерер, дип уйлый. Ул да - - Сталин терроры корбаны. 1937 елның октябрендә аны унберенче һәм соңгы тапкыр кулга алалар һәм атып үтерәләр. Сәбәп бер генә: ул -- төпле белемле, кыю татар зыялысы. «Ильяс Алкин: Жизнь и судьба (легенды и реальность)» дигән очеркта сүз әнә шул хакта бара.

Бүгенге «Чечня сугышы»на дөрес бәя бирү өчен, тарихка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ә тарих шуннан гыйбарәт: урыс империясе, иң кансыз чаралар кулланып, бәйсез Чечняны басып ала. Сугыш 47 елга сузыла. Шовинистлар моны онытмыйлар. Һәм, җаен туры китереп, 1944 елның февралендә, чечен халкын туган җиреннән сөрәләр. Юлда мал йөртә торган салкын вагоннарда бик күп балалар, картлар, авыру кешеләр үлеп кала. Сүз уңаенда гына: Кавказдан шул чакта куылучы карачай, балкар, чечен, ингуш, ногай, месхет төрекләре --- барысы да мөселманнар. Христианнарга тимиләр... Без тарихтан Орадур (Франция), Лидице (Чехия), Хатынь (Белоруссия) авылларының фашистлар тарафыннан юк ителүен, кешеләрнең утта яндырылуын беләбез. Әмма фашистлар әлеге авылларны партизаннар хәрәкәтен бастырабыз дип яндыралар. Ә менә Чечняда бөтенләй башка хәл була: вагонга сыймый калган карт-корыны, бала-чаганы - - барлыгы 700 кешене --- тау башындагы Хайбах авылына җыеп, һәммәсен дә утта яндыралар. Кемнәр дисезме? Совет солдатлары, совет милициясе. Сталин бу эшне башкаручыларга мондый телеграмма җибәрә: «От имени ВКП(б) и Комитета обороны СССР объявляю благодарность всем частям и подразделениям РККА и войск НКВД за успешное выполнение важного правительственного задания на Северном Кавказе. И.Сталин»

Инде килеп, матбагачылар колагына бер тәкъдимемне дә ирештерәсем килә: әлеге китапны татар телендә бастырырга, һәрбер тарих укытучысының өстәлендә булуына ирешергә кирәк безгә.

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,
галим-педагог.

Ашыгыз тәмле булсын!

Р.Бушков, Ф.Мазитова. «Казанской кухни цвет». Казань. Татарское книжное издательство, 1995, 207 стр.

Татарстан китап нәшрияты «Татар халык ашлары» дигән бик файдалы һәм кирәкле китап бастырып чыгарган иде. Күп санлы укучылар соравы буенча бу китап татар һәм урыс телләрендә әллә ничә тапкыр басылып чыкты, аны Татарстанда һәм аннан читтә - - Русиянең якын һәм ерак төбәкләрендә яшәгән милләттәшләребез генә түгел, урыслар һәм башка милләт вәкилләре дә яратып укыды, ризыкны татарча әзерләп авыз итте, әмма китапка булган сусавын баса алмады.

Нәшрият татар ашларына багышланган китапларны әледән әле чыгарып тора. Шуларның соңгысы - - Р.Бушков һәм Ф.Мәҗитова авторлыгындагы «Казанской кухни цвет» дигәне күптән түгел генә укучылар кулына килеп керде, сатуга чыкты.

Китап рәссам Р.Шәмсетдин бизәлешендә, каты тышлыкта, урыс телендә нәшер ителгән. Аның беренче бүлекләре укучыны Казанда яшәүче урыс һәм татар халыкларының аш-су әзерләү тарихына (ул һәр халыкның икътисади һәм гомумяшәеш тарихы белән тыгыз бәйләнгән), көн саен, кунак чакырганда һәм бәйрәм өстәленә әзерләнә торган аш-су, аңа кирәкле яшелчә-җимеш, ит-сөт, балык, он-ярма һ.б. ашамлыклар, эчемлекләргә багышланган.

Китапның беренче өч бүлегендә Болгар, Казан ханлыклары чорыннан буыннан-буынга тапшырылып килгән ризык төрләре, эчемлекләр турында сөйләнә. Бүгенге татар халкына борынгы бабаларыбыз аш-су әзерләүдә бай мирас калдырган. Әмма ул байлыкның шактый өлеше, кызганычка каршы, безгә килеп җитмәгән, йә өстебездән узган канлы гарасатлар аркасында югалган... Урыс хакимлеге урнашкач, Казан өстәлендә урыс йогынтысы белән аларга гына хас ашамлыклар да урын алган. Дәверләр үтү белән урыс һәм татар аш-су осталары бер-берсеннән өйрәнгән, һөнәрләрен камилләштергән, бәсткән. Әмма һәр халык өстәл әзерләгәндә үзенә генә хас үзенчәлекләрен саклап калган.

Бу китапны укыгач, борынгы һәм хәзерге аш-су әзерләү ысуллары, сәүдә эшләре һәм сәүдәгәрләр, аш-су әзерләү осталары, базарлар, толкучкалар, халык саны, байлар һәм ярлылар өстәле, товар бәяләре турында мәгълүмат аласың.

Китапның татар халык ашлары турындагы бүлеге танылган аш-су остасы Фатима Гатаулла кызы Мәҗитова тарафыннан язылган. Китапта шулай ук Казан татарларының кунакчыллыгы билгеләп үтелә, бу турыда урыс һәм башка милләт вәкилләре, чит ил кунаклары һәм сәяхәтчеләренең фикерләре белән дә танышырга мөмкин.

Кухня, аш-су әзерләү өчен бик кирәк булган төрле кулинария төшенчәләре, Русиядә һәм Европада кулланылышта йөргән авырлык, сыеклык һ.б.үлчәү берәмлекләре китапта аерым бүлек итеп бирелгән.

Аннары инде җаның ни тели --- шуны әзерләү өчен бөтен төрле рецептлар китерелгән. Салкын ашлар, салат-винегрет дисеңме, балык, яшелчә, сөтле яисә итле ашлар, төрледән-төрле шулпалар, икенчегә бирелә торган ашлар, йорт кош-кортларыннан әзерләнә торган ашлар, гөмбә һәм башка урман һәм бакча җимешләреннән, он һәм ярмадан әзерләнә торган тәмледән-тәмле ризыклар, мич ашлары, эчемлекләр, аш тәмләткечләр, ашны әзерләү рецептлары, кирәкле нәрсәләрне куллану ысуллары, ашамлыкларны кышка әзерләү, тозлау, киптерү, компот, кайнатма ясау ысуллары турында да китап җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүмат бирә.

Укучыларыбызга шуны китаптан берничә рецепт тәкъдим итәбез.

Галия САЯНОВА.

Кишердән пешерелгән аш-пюре

Суган белән петрушканы вак кына итеп турыйлар. Кишерне юка телемнәргә турап савытка салалар һәм итле кайнар шулпа өстәп, атланмай салып бераз пешерәләр. Кайнап торган шулпага әлеге яшелчәләрне салып, яңадан кайнатып алалар. Пешкән яшелчәләрне изәләр, ак соус өстиләр һәм пюре хәленә китерәләр дә, 5—7 минут кайнатып алалар. Пюрега атланмай салалар һәм аерым савытта гренки белән өстәлгә китерәләр.

Кишер пюресына бераз пешкән дөге өстәп тә бирәләр.

Гөмбәдән пешерелгән пудинг

Яңа гына җыелган гөмбәләрне юып, чистартып, вак кына итеп турап, тоз салып 15 -20 минут парландырып пешерәләр. Әрчеп пешерелгән бәрәңгене кайнар килеш төеп, сөт салып бәрәңге боламыгы әзерлиләр. Аңа йомырка, бераз атланмай, тоз салып болгаталар да, майланган кайнар табага бер катлам гөмбә, бер катлам бәрәңге боламыгы салып, өстенә йомырка сөртеп, духовкада пешерәләр. Пудинг өчен 500 г гөмбә, 50 г бәрәңге, 100 мл сөт, 1 йомырка алына.

Чәй янына чәлпәк

Сөткә йә каймакка йомырка, шикәр комы, бераз чәй содасы салып болгаталар, он кушып камыр изәләр. Әзер камырны 80- 100 граммлы кисәкләргә бүләләр дә, уклау белән 20 -30 сантиметрлы, 1,5 мм калынлыкта кечкенә җәймәләр ясыйлар. Бу «чәлпәк» дип атала. Чәлпәкләрне кайнап торган эретелгән (топленое) майга салып пешереп алалар. Пешергәндә чәлпәкләрнең чит-читләрен бөгәләр. Әзер пешкән чәлпәкләр өстенә шикәр комы сибелә һәм кайнар килеш чәй өстәленә куела.

Чәлпәк өчен 1 кг он, 100 мл сөт, 10 йомырка, 600 г май, 30 г шикәр комы алына.

Булатка күчтәнәч

Роберт Миңнуллин. «Күчтәнәч». Казан. «Мәгариф» нәшрияты, 1995, 160 бит.

Чаллыдан сеңелемнең малаеннан хат килде. Бер биткә өч кенә сүз язган: «Туган көнгә кил», - дигән. Әнисеннән хат алдарак килгән иде, бик борчылып язган. «Апа, Булат татар мәктәбенә бармыйм, ди. Нишләргә инде? Бер вакыт табып, килеп китә алмассыңмы?» - - дигән. Булат белән бу турыда авылда да сөйләшкән идек инде. Минем үземә дә: «Андрей кая барса, мин дә шунда укыйм», -- дигән иде. Кат-кат сөйләшкәч, минем белән килешкән дә кебек булган иде. Шулай да аерылышканда: «Быел мәктәпкә бармыйм әле, матур итеп яза да белмим», - - дип калган иде. Биш яшеннән үзлегеннән укырга өйрәнде. Әлифбасы «Ватаным Татарстан» газетасы булды. Хәрефләрне шуннан өйрәнде. Быел аңа 7 яшь тула, мәктәпкә бармый чарасы юк. Мин дә туган көнгә бармый кала алмыйм. Тик менә Булатны сөендерерлек бүләк кайдан табарга? Уенчык машиналары да бар, бер җизнәсе урыс булгач, күз явын алырлык бик матур урысча китаплары да күп. Һич башка килми, белмим, нәрсә алырга? Уйлап, эзләп йөрим.

Беркөнне китап кибетендә эшләүче ханым бер китап бирде. Шундый матур китап. Роберт Миңнуллин. «Күчтәнәч». Булат та китапны бик яратты. «Күчтәнәч», дип кычкырып укыды да: «ашыйм, ашыйм», дип көлдерергә тотынды. Роберт абыйсының рәсемен күргәч, күз кысып, пәп итеп алды да, телен күрсәтеп, «Әнкәмнең догалары», дип, икенче бүлмәгә кереп китте. Байтак кына вакыт тавышы ишетелми торды. Китабын кулыннан куймаган икән әле. Әйләнеп чыкты да:

— Яхшы бу, — диде.

-- Ник яхшы? — дим. --- Нәрсәсе яхшы?

--- Тиз ятлана, тел тотлыгып тормый. Сөйлиммe? -- диде. Алты строфалы «Йолдыз буласым килә» дигән шигырьне ятлап та өлгергән икән. Ошап киткән, әтисеннән, әнисеннән, апасыннан шигырь сөйләтә. Янәсе, аларга бүләк итеп ятлый.

-- 1 сентябрь көнне укытучыңа сөйләргә ятлап куй, - - дим.

Кашларын җыерып, тынып калды. Әтисенә-әнисенә карап-карап алды. Сизелеп тора --- җилле-җилле сөйләшүләр булгалап алган. Шомлы тынлыкны Булат бозды, китабын ачып карады да:

-- Казан апа, хәйләкәр син түлке, - диде. Көлеп рәхәтләнә үзе. Китабын тотып Андрейларга кереп китте. Чыккач: «Нишләп йөрисең?» -- дип сорашам.

- - Мин татар гимназиясенә барам, -- дип әйттем, китабымны да күрсәттем.

Сүзсез генә аңлаша алуга барыбыз да җиңел сулап куйдык. Гап-гади бер гаиләдә зур бер мәсьәләне хәл итешкән, чып-чын бәйрәм ясаган, барыбызны да сөендергән өчен Робертка бик зур рәхмәт. Бүгенге көннең шаян, шук, тапкыр,акыллы, хәйләкәр, усал малайларына-кызларына хуш килерлек китап чыгарган өчен «Мәгариф» нәшриятына да, Татарстан газета-журналлар нәшрияты басмаханәсенә дә рәхмәт яусын. Тик аптырап калдым. Булатка шундый китап бүләк иткәнемне ишетсәләр, башка нәни туганнарым үпкәләр кебек. Мин аны Камилгә, Ләйсән, Наилә, Айрат, Әлмира, Радик, Нәфисә, Фәнис, Ришат, Салават, Энисә, Гөлназга да бүләк итәр идем. Барысы да мәктәп балалары. Ләкин, бик кызганыч, китапның тиражы биш мең генә, күрми дә калуыбыз бар. Хәер, бу китапның авторы Роберт Миңнуллин - - Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе. Үз китабын күбәйтүне дә, балалар өчен затлы, зәвыклы шундый китаплар чыгаруны да, бәясен арзанрак итүне дә турыдан-туры кайгыртыр өчен сайлап куелган халык депутаты да.

-- Чаллы малае Булаттан зур рәхмәт, сәлам аңа, -- яңа китап көтеп, борынын уа-уа шулай диеп калды.

Фәния ХУҖАХМӘТ.

ДҮШӘМБЕ

21 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.05 Мультфильм. 18.15 Телефильм: «Кот и клоун». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Гүгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булыр? 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Гашыйклар телеканалы». 21.05 Фортепьяно дуэты кичәсе. Э.Моназсон һәм Ф.Хәсәнова. 21.35 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Приключения капитана Врунгеля». 1 нче серия. 7.30 «КиноМеню». 8.00, 12.35 — «Юл патруле»., Атналык йомгаклар. 8.10, 12.50 — «Даруханә». 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10, 13.35 — «90х60х90». 9.30 «Спартак» кубогына. Хоккей. Финал. 13.05 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 Атна һәлакәтләре. 15.05 «Фитиль». 15.15 Нәфис фильм: «Дети как дети». 16.35 «Минем тарих». Борис Громов. 17.05 Гарри Бази «Пуленепробиваемый» фильмында (АКШ). 18.45 «Югарыда — йолдызлар гына» (MTV). 19.20 «Эфирда — музыка». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.00 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Телеэкспресс». 21.10 Казан: атна йомгаклары. 21.25 Нәфис фильм: «Игра». 1 нче кисәк. 23.25 TAP RECORDS коллекциясеннән. Бон Джови.

1 НЧЕ КАНАЛ

Техник чараларга профилактика үткәрелү сәбәпле, 15.00 сәгатькә кадәр тапшырулар күрсәтелми.

15.00, 1.50 — «Яңалыклар». 15.20 «Спортның җиде көне». 15.50 Авторалли: Париж—Мәскәү—Пекин. 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Тет-а-тет». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Пик сәгате». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 А.И.Солженицын белән очрашу. 22.10 Александр Збруев «Два билета на дневной сеанс» фильмында («Ленфильм»). 23.55 «Юрамалар». 0.15 «Спортның җиде көне» Футбол. 0.45 Пресс-клуб. 1.40 Авторалли: Париж—Мәскәү—Пекин.

«РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 9.25 Клип-антракт. С.Лазарева. 9.30 Өй экраны. Нәфис фильм: «Последний бункер». 10.55 Телегазета. 11.05 Безнең хәбәрчедән. «Мунча рапсодиясе». 11.20 Музыкаль экспромт. 11.35 Милиция хроникасы. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты» (Испания). 12.15, 16.30 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 17.20 Алтын шпор. 17.50 «Алыргамы — алмаскамы». 18.00 «Коткару-911». 18.55 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Дүшәмбе саен детектив. Нәфис фильм: «Последний враг» (Бөекбритания). 2 нче кисәк. 21.40 Репортер. 22.00 «Хакыйкать мизгеле». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Россиянең Зур театрында «При де Лозани».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

Техник чараларга профилактика үткәрү сәбәпле 13.00 сәгатькә кадәр тапшырулар күрсәтелми.

13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 13.20 «Үзем өчен Россияне ачам». 13.50 Телеблиц. 13.55 Тапшырулар тартмасы. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 — Телефильм: «Мануэла». 117 нче серия. 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30 , 22.40 — «ТВ — мәгълүматлары». 15.45 Телефильм: «Ленинградский балет». 16.25 «Көз» кинокапалы. Нәфис фильм: «Сильва. (Свердловск киностудиясе. 1944 ел). 17.55 Тарихи альманах. 18.20 «Әкият арты әкият». 18.55 Кичке телевизион программа. 19.05 «Телеблиц». 19.10 «Комсомолец» язмышы». 19.45 Спорт яңалыклары. 20.45 Имиплек телехезмәте. 20.55 Шәһәр эшләре. 21.05 Аскольд Макаров бенефисы. 21.55 Нәфис телефильм: «А.П.Чехов. Сценки». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 23.10 Телекомпакт.

СИШӘМБЕ

22 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.30 Балаларга фильм: «Принцесса-павлин». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 Татарстан Республикасының мөстәкыйльлегенә 5 ел тулуга карата. «Язучы фикере». Р.Мостафин. 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Туктальш». 20.40 «Пульс». Медицина программасы. 20.55 Күп серияле нәфис фильм премьерасы: «Тарзан». 6 нчы һәм 7 нче серияләр. 21.45 «Болл» клубы. 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Приключения капитана Врунгеля». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 7.30, 20.00, 23.55 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (21 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10 , 13.35 — «90х60х90». 9.25 Мультсериал: «Сказки народов мира». 9.50 Нәфис фильм: «Остров сокровищ». 1 нче серия. 10.50, 18.40 — «Юл патруле». 11.05 Атналык фаразлар. 11.35 «Даруханә». 11.50, 18.20 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.10 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 1 нче серия. 13.20 Кино музыкасы. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Маргарита Терехова. 15.05 «Музыка һәм матбугат». «Каләм акулалары». В.Малежик. 15.55 МХАТ театры спектакле: «Школа злословия». 18.50 «Европадан — егерме». (MTV). 19.35 «Эфирда — музыка». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.40 «Спорт-ревю. 21.05 «Телеэкспресс». 21.25 «Коммерция әйләнмәсе». 21.25 Казан автосалоны. 22.20

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

Нәфис фильм: «Игра». 2 нче кисәк. 0.20 TAP RECORDS коллекциясеннән. Теарс Фор Феарс группасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.55 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 11.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 11.40 «Ел әйләнәсендә — яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 11 нче серия. 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». Футбол. 15.50 Авторалли: Париж—Мәскәү—Пекин. 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Тутый кош артыннан». 16.40 «Сер итеп кенә». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.55 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 «Беренче куллардан». 22.05 Зоя Федорова, Сергей Лемешев «Музыкальная история» фильмында (Ленфильм). 23.40 «Юрамалар». 0.50 Телешоу: 50x50.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 «Париж сезоннары». 11.35 «Милиция хроникасы». 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Өмет стартлары». 16.50 «Ай тотучы». 17.50 Карарга ашыгыгыз! Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера». 12 нче серия. 18.15 Клип-антракт. Линда. 18.25 «Көтү залы». 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Юбиляр фильмотекасыннан. Г.Данелия. Нәфис фильм: «Паспорт». 22.25 Су спорты төрләре. Россия чемпионаты. Венадан тапшыру. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Мәхәббәт табышмагы». «Императрица мәхәббәте». Э.Радзинский программасы. 0.35 Криминаль хәбәрләр экраны.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.00 «Төш юрау». 10.48 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 13.20 Үзем өчен Россияне ачам. Новгород өлкәсе. 13.50 Телеблиц. 13.55 Көнлек телевизион программа. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19,55 — Телефильм: «Мануэла». 118 нче серия. 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22,40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.45, 19.10 — Мультфильм. 16.00 Баскетбол. «А.Белов кубогы»на халыкара турнир. «Спартак» — «Радио» (Вроцлав). «Юбилейный» спорт сараеннан трансляция. 17.35 Телефильм-балет: «Антоний и Клеопатра». 18.15 Бөтен Россия буйлап. 18.25 «Әкият арты әкият». 18.55 Кичке телевизион программа. 19.05 «Телеблиц». 19.45 Спорт яңалыклары. 20.45 «Имиплек телехезмәте». 20.55 «Телисеңме? Кара». 21.45, 23.10 — Телевизион спектакль: «Последняя альтернатива». Режиссер В.Латышев. 1 нче һәм 2 нче серияләр. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көнгә телевизион программа.

ЧӘРШӘМБЕ

23 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.55 Балаларга фильм: «Похищение в Тютюрлистане». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 «Кинонотка». 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры солистлары концерты. 21.10 Нәфис фильм: «Афганский излом». 22.15 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Приключения капитана Врунгеля». 4 нче һәм 5 нче серияләр. 7.30, 20.20, 0.30 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (22 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 9.10, 13.25 — «90х60х90». 9.25 Мульсериал: «Сказки народов мира». 9.50 Нәфис фильм: «Остров сокровищ». 2 нче серия. 11.00, 18.45 — «Юл патруле». 11.15 «Атна низаглары». 11.40 «Даруханә». 11.55, 18.25 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары». 12.15 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 2 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары.14.30 «Минем тарих». Борис Громов. 15.05 Нәфис фильм: «Отелло». 17.00 Рей Брэдбери: «Җимерүче». 17.30 Детектив сериал: «Таггерт». 1 нче серия. 18.55 Кино яңалыклары. 19.15 «Эфирда — музыка». 19.25 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 Күңел ачу программасы: «Хенки-пенки». 21.35 «Үз кешеләр». 22.10 Питер Устинов «Шпионы» нәфис фильмында (Франция).

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.40 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Тема». 10.50 «Хайваннар дөньясында». 11.35 Телеуен: «Миңе аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 14.00 Мультсериал: «Коапп». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 15.50, 0.25 — Авторалли: «Париж—Мәскәү—Пекин». 16.00 Күңелле ноталар. 16.20 «Ник һәм нигә?» 16.50 «Фэн-клуб». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.55 Телеуен: «Көен таны». 20.00 Татлы хыяллар фабрикасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Рене Клер кинокомедиясе: «Праздники любви» (Франция). 23.35 «Юрамалар». 23.55 «Яңа обывательләр».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25, 16.00 — Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Тәп мизгел». 9.05, 21.30 — Су спорты төрләре. Россия чемпионаты. Венадан тапшыру. 9.50, 20.35 — Өй экраны. Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьяң мәсьәләсе». 11.05 Рус мавыгулары. С.Дәүләтов. 11.50 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Бременские музыканты». 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.50 Телегазета. 17.55 Карарга ашыгыгыз! Нәфис фильм: «Бегство с Юпитера» (Австралия). 18.20 «Беркем дә онытылмаган». 18.25 Әдәби-публицистик цикл премьерасы: «Россия. Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95. 19.10 «Соңгы шагыйрь». С.Есенин. 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 22.25 Документаль фильм. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ — мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 13.20 «Үзем өчен Россияне ачам». Кинешма. 13.50 Көнлек телевизион программа. 13.55 Телеблиц. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 — Телефильм: «Мануэла». 119 нчы серия. 15.15 Бакчачыларга киңәшләр. 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ — мәгълүматлары». 15.45 Безнең кино. Нәфис фильм: «Вива, Кастро!» 17.05 Нәфис фильм: «Живые струны». 17.40 Тарихи альманах. 18.25 «Оптимист» классы. 1 нче класс. 18.55 Кичке телевизион программа. 19.05 Телеблиц. 19.10 Мультфильмнар. 19.45 Спорт яңалыклары. 20.40 Иминлек телехезмәте. 20.55 Футбол. «19 нчы август» кубогы. 21.45 «Блеф-клуб». 22.20 Хәтирәләребез җырлары. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 23.10 «Гыйбадәтханә». 23.40 Нәфис телефильм: «Жермена и Бенжамен» (Франция).

ПӘНҖЕШӘМБЕ

24 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.30 «Минем нәни дустым». Муса Маликов. 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Нәфис сүз кичәсе». Рузалия Зәкиева укый. 20.20 Сафиян Ибраһимов җырлары. 20.50 Нәфис фильм: «Афганский излом». 2 нче кисәк. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

6.50 «Зарядкага басыгыз!» 7.00 Мультфильм: «Кругосветное путешествие Кота в сапогах». 7.30, 20.20, 23.15 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (23 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Эфирда — музыка: «Ласковый май», «Ногу свело». 8.55 Нәфис фильм: «Гусарская баллада». 10.25 «01» тележурналы. 10.55 Кыска метражлы нәфис фильмнар: «Так надо», «И если я нарушу». 11.40 «Базар» тележурналы. 12.10 Европа сәхнәсе. 12.40 Планета кайтавазы. 13.10 Нәфис фильм: «Остров сокровищ». 3 нче серия. 14.10 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 3 нче серия. 15.30 CNN. «Стиль». 16.00 Ток-шоу. «Мин үзем». «Чит ил кешесенә кияүгә чыктым». 17.00 Нәфис фильм: «Только три ночи». 18.25 Сериал: «Таггерт». 2 нче серия. 19.20 Ушуайя. 19.40 «Кыюлар һәм матурлар». 20.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.05 «Коммерция әйләнмәсе». 21.30 Атна фильмы: «Адский поезд» (Франция). 23.40 «Red Wave» тәкъдим итә. Джефф Сканфакстер.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.40 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Татлы хыяллар фабрикасы». 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне», 15.50 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин. 16.00 «Мультитроллия». 16.20 «Золушкада кунакта». 16.40 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 17.00 «Кыска яңалыклар». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «... 16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен тапшыру». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгате». 19.35 «Лото-миллион». 20.05 «Хәтерләсеннәр өчен...» Тапшыруны Л.Филатов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Мәскәү. Кремль. 22.15 «ПАТТОН» фильмы: «Семь Оскаров» (АКШ). 1.20 «Юрамалар».

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25,16.00 Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Тәп мизгел». 9.05, 23.45 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 9.45 «Телегазета». 9.50, 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95. 11.15 Документаль фильм: «Из истории русского портрета XYIII века». 11.35 «Милиция хроникасы». 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Мечи свободы. Поход каталонцев» (АКШ). 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.00 Тапшырулар программасы. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «РОСТА» компасы. «Англиянең әкияти мәктәпләре». 17.20 Яңа тармак. «Сүнеп баручы йолдыз». 17.50 «Беркем дә онытылмаган». 17.55 Карарга ашыгыгыз! Мультфильм: «Соловей». 18.25 Клип-антракт. 18.30 «Әйдәп баручы фаразы». 18.55 «Безнең бакча». 19.25 «Русча караоке». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 21.30 Хроно. Авто һәм мотоспорт дөньясында. 22.05 Гадәттән тыш канал. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

Профилактик чаралар үткәрелү сәбәпле, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсендә 13 сәгатьтән 18 сәгатькә кадәр тапшырулар күрсәтелми.

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.15 «Төш юрау». 11.15 «Аукцион». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15, 15.40, 17.30 «Музыка мизгеле». 13.20 «Үзем өчен Россияне ачам». Великие Луки. 13.50 Телеблиц. 13.55 Көнлек телевизион программа. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 Күп серияле нәфис телефильм: «Мануэла» (Италия). 120 нче серия. 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 15.50 «Бөтен Россия буйлап». 16.00 Баскетбол. «А.Белов кубогы»на халыкара турнир. «Спартак» — «Динамо» (Мәскәү). «Юбилейный» спорт сараеннан трансляция. 17.35 Балалар өчен нәфис фильм: «Мальчик из спичечной коробки». 18.50 Мультфильм. 19.00 Кичке тапшырулар программасы. 19.05 «Телеблиц». 19.10 «Буй-буй музыка». 19.45 Спорт яңалыклары. 20.45 «Иминлек телехезмәте». 20.55 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Разборчивый жених». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Иртәгесе көн өчен телевизион программа. 23,10 «Чегән күңеле...» 23.40 Нәфис фильм: «Жермена и Бенжамен». 12 нче серия.

ҖОМГА

25 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 «Җырлыйм әле җырларымны». Венера Шәмиева. 18.25 «Һинд киносын яратучыларга». Киноконцерт. 19.00 «Татарстан». 19,30 «Видеоспорт». 19.55 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Ислам чакыруы». 20.20 «Җомга көн кич белән». Альманах. 21.20 «Болл» клубы. 21.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильмнар. 7.30, 20.20, 22.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Телеэкспресс» (24 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (MTV). 8.55, 13.35 «90х60х90. 9.10 Мультсериал: «Еноты». 9.35 Нәфис фильм: «Старая крепость». 1 нче серия. 10.45 Юл патруле. 11.00 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы. 11.30 «Даруханә». 11.45, 18.50, 19.10 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.05 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 4 нче серия. 13.50 Валюта бәясе. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 15.05 «Атнага бер тапкыр». 15.35 Нәфис фильм: «Падшие ангелы» (АКШ). 17.20 Рей Бредбери: «Күзге». 17.50 Сериал: «Таггерт». 3 нче серия. 19.20 Эфирда — музыка. 19.25 «Экология хәбәрчесе». 19.30 «Суперспорт». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Марчелло Мастрояини «Восемь с половиной» (Италия-Франция) нәфис фильмында. 0.45 Сильвия Кристель «Эммануэль» (Франция) нәфис фильмында.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.30 — Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Хәтерләсеннәр өчен...» Тапшыруны Л.Филатов алып бара. 10.50 «Иртәнге йолдыз». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Жизнь Клима Самгина». 10 нчы серия. 14.05 Мультсериал: «Коапп». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 15.50 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин. 16.00 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.25 «Орфей йолдызлыгы». 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Телесериал: «Таверна «Ямайка» (Бөекбритания). 1 нче серия. 22.50 «Юрамалар». 23.10 1995-1996 еллардагы футбол сезоны буенча чемпионнар лигасына җирәбә салу. 23.40 «Караш». 0.35 Музыкаль күзәтү. 1.20 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин.

«РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 Тапшырулар программасы. 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Хакыйкать мизгеле». 9.50, 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05, 23.45 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95. 11.15 «Телегазета». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Ле Монти» сәүдә йорты. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Мечи свободы. Поход каталонцев» (АКШ). 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.00 Тапшырулар программасы. 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Көнгерә». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 Яңа тармак. «Ижор һәм Нева ярларында». 17.50 Җомга саен Дисней. Нәфис фильм: «Свет в лесу». 19.25 Киноафиша. 19.40 «Кайнар уңлык». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Фортедан пьяного кадәр». Ю.Мамин программасы. 22.05 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.55 Төнге сеанс. Нәфис фильм: «Она выбирает романтику» (АКШ).

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Кинәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.38 «Кумирлар». 10.45 Такмаклар. 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 Джаз. 12.40 «Кунак». 13.00 ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны. 13.15, 15.40, 18.50 «Музыка мизгеле». 13.20 «Алар Россияне коткарачаклар». Сыктывкар. 13.50 «Телеблиц». 13.55 Көнлек телевизион программа. 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 Күп серияле нәфис телефильм премьерасы: «Мануэла» (Италия). 121 нче серия. 15.15 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22.4^ ТВ мәгълүматлары. 15.45 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Разборчивый жених». 17.25 ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы. 17.55 «Бәллүр ачкыч». Музыкаль клиплар фестивале. 18.15 «Зебра». Артек-95. 18.45 Кечке телевизион программа. 18.55 «Телеблиц». 19.00 Мультфильм. 19.45 Спорт яңалыклары. 20.45 Иминлек телехезмәте. 20.55 Фильмоскоп. Нәфис фильм: «День рождения Анны». 22.05 Телефильм: «С ярмарки». 22.30 Мультфильм. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.05 Кечке телевизион программа. 23.10 Чит ил киносы антологиясе. Нәфис фильм: «Перекати поле».

ШИМБӘ

26 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Гадәти шимбә». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «7 нче стиль». 20.40 Б.Шишаев. «Хәерсез кон». Телеспектакль. 22.25 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Эфирда — музыка. 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (25 август тапшыруын кабатлау). 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (22 август көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Казан автосалоны». 9.05 «Спорт-ревю». 9.15 «700 нче клуб». «Җаваплар». 9.50 Мультсериал: «Д'Артаньгав и три пса-мушкетера». 10.20 Нәфис фильм: «Пеппи-Длинныйчулок». 1 нче серия. 11.30 «Чаплиниада». «Янгын каланчасы». 11.55 Хәрби телевидение. 12.30 «Сәбәпсез спорт». 13.00 «Следствие ведут знатоки». 1 нче, 2 нче серияләр. 14.55 Нәфис фильм: «Брод». 16.15 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 16.35 Юл патруле. 16.45 Телесериал: «Тропическая жара». 17.50 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.50 Эфирда — музыка. 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Джеймс Белуши «Кудряшка Сью» комедиясендә. 0.20 «Югарыда — йолдызлар гына» (MTV).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.40 — Яңалыклар. 9.20 «Джунглилар чакыруы». 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.25 «Акыллылар». 10.40 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.30 «Сәламәтлек». 12.00 Провинция. «Территория». 12.40 «Бомонд». 13.00 «Кино гасыры». О.Жизнева В.Пудовкинның «Убийцы выходят на дорогу» (СССР, 1942 ел) фильмында. 14.20 «Күзге». 14.50 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин. 15.20 «Зур узышлар». 15.40 Документаль фильм: «Адольф: казнь после смерти». 16.30 «Хайваннар дөньясында». 17.05 «Бәхетле очрак». 18.25 Жуковскида халыкара авиакосмик салон. 18.55 Шерли Мак-Лейн «В ожидании светофора» (АКШ) кинокомедиясендә. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Телесериал: «Таверна «Ямайка» (Бөекбритания). 2 нче серия. 22.50 «Ак попугай» клубы. 23.35 «Манхэттен трансфер Мәскәүдә». 0.25 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин.

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Беренче дубль». 9.00 «Винил джунглилары». 9.30 «Пилигрим. Россиянең сәяхәтләр бюросы». 10.15 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95. 10.30 Амика Веритас. Юристлар телеконкурсы. 11.15 «Ничек яшәрбез?» 12.00 Яраткан комедияләрем. Нәфис фильм: «Любовь и голуби». 13.45 К.Мажейка. «Янәшәләр». 14.20 «Де факто». 14.35 Өй экраны. «Подвалы «Мажестик». «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. 1 нче кисәк. 15.30 «Хайваннар дөньясында». 16.25 «Америка йолдызлары». 16.55 Футбол. Россия чемпионаты. ЦСКА — «Локомотив» (Мәскәү). «Локомотив» стадионыннан трансляция. 18.55 «Йолдызлар яңгыры». 20.25 Юбиляр фильмотекасыннан. П.Тодоровский. Нәфис фильм: «Анкор, еще Анкор!» 22.10 «Үтә яшерен». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Аваз юлы». 0.25 «Төнге сөйләшү». 0.30 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос — бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 9.55 Көнлек телевизион программа. 10.00 Телевизион спектакль: «Последняя альтернатива». Режиссер В.Латышев. 12.10 Телефильм-концерт: «Живые струны». 12.45 «Рандеву». Таня Буланова. 13.15 «Теледоктор». 13.35 «Күз» киноканалы. Нәфис фильм: «Два долгих гудка в тумане». 15.00 Объектив. Документаль телефильм: «Кинооператор Андрей Москвин». 16.00 Баскетбол. «А.Белов кубогы»на халыкара турнир. Ярымфинал. «Юбилейный» спорт сараеннан трансляция. 17.35 Режиссер О.Ерышев фильмнары. «Лентелефильм» студиясе. «Одиссея Александра Вертинского». 1 нче фильм. 18.25 «Әкият арты әкият». 19.05 Кечке телевизион программа. 19.15 Мультфильм. 19.30, 22:40 ТВ мәгълүматлары. 19.50 Телеэкранда детектив. Нәфис фильм: «Миллионы Мадигана». 21.20 Экспресс-кино. 21.35 «Оранж-ТВ» «Теләмәсәң — карама» каналы тәкъдим итә: «Без названия», «Самое-самое», «Стрекоза», «Навигатор». 22.55 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 23.00 «Коллекция». Нәфис фильм: «Убежище» (АКШ).

ЯКШӘМБЕ

27 АВГУСТ

«ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 19.50 «Программа-2». 20.05 Телебуклет. Тапшырулар анонсы. 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.25 Телевидение фондыннан. «Шигърият». Рәшит Әхмәтҗанов. 20.45 «Алтын көшел». Авыл эшчәннәре өчен тапшыру. 21.35 Г.Камал. «Беренче театр». Телеспектакль. 22.20 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). 8.40 Коммерция әйләнмәсе (24 август тапшыруын кабатлау). 9.05 «Үз кешеләр». 9.40 Эфирда — музыка. 9.50 Мультсериал: «Д'Артаньгав и три пса-мушкетера». 10.15 «Пеппи Длинныйчулок». 11.25 «Чаплиниада». 12.00 «Минем кино» Виктор Мережко белән. 12.30 Нәфис фильм: «Сережа». 13.50 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 14.20 «Атна һәлакәтләре». 14.50 «Фитиль». 15.00 Нәфис фильм: «Операция «Ы» и другие приключения Шурика». 16.45 Red Wave тәкъдим итә: Jesus Johus, Оззи Озборн. 17.45 Телесериал: «Тропическая жара». 18.45 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Матт Дилан «Аптечный ковбой» фильмында. 22.35 Юл патруле. 22.55 Нәфис фильм: «Неприкаянные сердца». 0.30 «Исәнмесез!» (26 август тапшыруын кабатлау).

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 0.30 — Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильм: «Дядюшка Ау». 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.40 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». 12.00 «Бөтендөнья географиясе». «Тикшерүче» тележурналы (АКШ). 12.50 «Бөтен Россия». N шәһәрендә. 13.15 «Уйна, гармун». 13.45 «50 ел элек бу көннәрдә». 14.00 «Пи» билгесе астында. 14.40 Авторалли: Париж — Мәскәү — Пекин. 15.20 «Эфирда — музыка». 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.05 «Америка М.Таратута белән». 17.35 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 3 нче һәм 4 нче серияләр. 18.00 Вакыт. 18.20 «Әйтеп торучы». 19.00 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Гадәти булмаган могҗиза». И.Чурикова, И.Костолевский, Л.Долина, О.Меньшиков, Е.Коренева, М.Глузский, А.Вертинская катнашында киноконцерт. 20.00 «КВН-95». 22.00 «Якшәмбе». 22.47 Спорт яңалыклары. 22.55 Тапшырулар программасы. 23.00 Телесериал: «Таверна «Ямайка» (Бөекбритания). 3 нче серия. 23.55 «Бер күрүдә ярату».

«РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.20 Тапшырулар программасы. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30, 22.30, 0.05 Су спорты төрләре. Европа чемпионаты. Венадан тапшыру. 9.00 «Җәйге коктейль». Музыкаль программа (Молдова Республикасы). 9.20 «Алтын ачкыч». 9.35 Хәерле иртә. «Чемпионнар өчен иртәнге аш». 10.05 «Футболга чикләр юк». 10.50 «Аты, баты...» 11.20 «Рус лотосы». 12.05 «Консолидация». 12.10 Кино йорты. Нәфис фильм: «Медвежья свадьба». 13.45 Сезнең партнер. «Россиянең тимер юллары». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык...». 14.35 Өй экраны. «Подвалы «Мажестик». «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. 2 нче кисәк. 15.25 «Синең мөмкинлекләрең, кеше!» 15.55 «Формула-1» классында дөнья буенча автоузышлар. Бельгия Гран-прие. Спа-Франкошамнан трансляция. 18.00 Диснейның тылсымлы дөньясы: «Русалочка», «Новые приключения Винни-Пуха». 19.00 «Яр буендагы йорт». Ю.Трифонов. 19.25 «Ксюшада кунакта». 20.25 Голливудта төшерелгән. Нәфис фильм: «Ловкачи». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «Тапшырулар тартмасы». 23.55 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 9.55 Көнлек телевизион программа. 10.00 Нәфис фильм: «Убежище» (АКШ). 11.35 Телефильм. Рус романсларын Галина Писаренко башкара. 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.10 «Карарбыз». 5 нче телеканал программалары анонсы. 13.25 Документаль фильм: «Тайна пирамид» (Франция). 2 нче кисәк. 14.10 «Классика-5». Өметләр фестивале. 15.00 Баскетбол. «А. Белов кубогы»на халыкара турнир. Финал. «Юбилейный» спорт сараеннан трансляция. 16.35 Депутатларга сүз бирәбез. 17.05 «Одиссея Александра Вертинского». 2 нче фильм. 18.05 Телефильм: «Сочинское лето». 18.25 Киномания. «Неистовый Пазолини». 18.55 Месье Синема, сез кем? 19.25 Кечке телевизион программа. 19.30, 23.15 ТВ мәгълүматлары. 19.50 «Алкышлап». Глен Миллер. 20.35 Безнең кино. Нәфис фильм: «Житие Александра Невского». 21.55 Музыка мизгеле. 22.00 Иртәгесе көнгә телевизион программа. 22.05 Рок риваятьләре. «Заппа галәме». 23.35 «Адәм һәм Хава плюс».

ДҮШӘМБЕ, 21 АВГУСТ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.50, 7.58, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30, 20.45 — Радио-1. 17.45 «Борын-борын заманда...». 18.15 «Дүшәмбедән-дүшәмбегә». Мәдәният яңалыклары. 19.45 Һәвәскәр башкаручылар концерты.

СИШӘМБЕ, 22 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30, 21.45 — Радио-1. 12.25 - 14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Башкортстан артистлары концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә». 17.45 «Яшьлек» студиясе. 18.15 «Көн темаларына». Әңгәмәләр, аңлатмалар. 19.45 Татар композиторларының опералрыннан арияләр һәм балетларыннан өзекләр.

ЧӘРШӘМБЕ, 23 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Татарстан дулкынында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 21.00 — Радио-1. 12.25 - 13.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Старт». 19.45 Сораулар буенча концерт.

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 24 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 20.45 — Радио-1. 12.25—14.30 — «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Туры эфирда диалог». 17.45 «Казан һәм казанлылар». 19.45 Р.Абдуллин җырлары.

ҖОМГА, 25 АВГУСТ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 — «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 — Радио-1. 12.25- 13.30 — «Көн үзәге» информацион нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 Драма артистлары җырлый. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 Эстрада концерты.

ШИМБӘ, 26 АВГУСТ

6.00, 7.00 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 — Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 14.30 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 — Радио-1. 8.15 «Мәсьәләгә бер караш». 8.30 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Хәтер». Композитор Ф.Яруллинга багышлана. 9.30 «Көн артыннан көн». 10.30 «Сәясәт һәм шәхес». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Әбугалисина клубы».

ЯКШӘМБЕ, 27 АВГУСТ

7.00, 7.58, 13.40 — Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 — Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 «Малайларга — кызларга». 9.30 «Мирас». 12.15 «Сәламәтлек». 12.45 Ял концерты. 13.35 «Татарстан дулкынында». 14.10 Т.Миңнуллин. «Диләфрүзгә дүрт кияү». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле. 16.00 Радио-1.

«ӘНИ, ГАФУ ИТ, БАШКАЧА ЯШИ АЛМЫЙМ...»

Без Латвиядә яшәүче милләттәшебез Равил Яһудинның үз-үзен яндыруы турында хәбәр иткән идек инде. Хәзер шул хакта тулырак язма урнаштырабыз.

— Ул ишегалдына чыгып китүгә, үзәк өзгеч тавыш ишетелде. Тәрәзәгә йөгереп килсәм, ни күрим — улым дөрләп яна! Төрле яктан кешеләр йөгерешә, пиджак-курткалар белән томалап аны сүндерергә азапланалар. Урамга йөгереп чыктым: «Улым, нишләдең син?!» — дим. Ә ул: «Әни, миңа карама. Гафу ит, башкача яши алмыйм», — дип пышылдый.

Софья әбинең куллары, иреннәре калтырый. Татьяна Садыйк кызы, Равилнең хатыны, елый башлады. Аның кайгысын уртаклашырга килгән дуслары: «Кешеләр белән нәрсә генә эшләмиләр бит», — дип тәкрарлыйлар. Мин дә елыйм һәм Равил Яһудинның үлеменнән соң, аның туганнарына ничек сораулар бирәчәгемне үзем дә аңлап бетермим шикелле. Ул ишегалдында өстенә бензин сибеп, үз-үзен яндыра.

Яһудиннар гаиләсен 1943 елда немецлар Ленинград яныннан куып алып киләләр. Архив белешмәсе шул хакта сөйли. Хуторларның берсенә мәҗбүри эшкә җибәрәләр. 1944 елда бу җирләргә Совет Армиясе аяк баса. Хәнәфи Яһудин армиягә алына һәм рядовой булып сугышка китә. Ике атнадан соң Рига янындагы сугышларда һәлак була. Ул Баускидан ерак түгел туганнар каберлегендә күмелгән. Соңыннан полкташлары сөйләгәнчә, солдатлар чолганышта калалар, ләкин Хәнәфи дошманга бирелми, граната белән үз-үзен шартлата.

Ике балалы тол хатынга Даугавпилстагы иске йорттан фатир бирәләр. Элек бу йортта яшәүче яһүдләр шәһәр геттосында үтерелгән. Яһудиннар бүген дә җимерек дип табылган шушы йортта яшиләр. Җыйнак кына, яшел чирәм үскән ишегалдында Равил туып үскән, хатынын да шунда алып кайткан, биредә аның ике баласы уйнаган. Улы һәм кызы — инде үсеп җиткән, мөстәкыйль кешеләр.

— Дус, тату гаилә, — диләр күршеләре. — Равил — йорт җанлыклы, абруйлы, тыныч холыклы кеше иде. Аның азып-тузып йөргәнен дә, җәнҗал-тавыш чыгарганын да беркем хәтерләми.

Гаиләгә кайгы заводлар ябыла башлагач килә. Равил эшләгән станоклар төзәтү заводы да туктый. Хезмәт киңәшендә рәхмәт сүзеннән башка нәрсә булмаган югары квалификацияле слесарьның беркемгә дә кирәге калмый. Илле яшьтән узгач, ничек яңа һөнәргә укып йөрмәк кирәк? Эш эзләп арыгач, 1992 елның декабрендә, Р.Яһудин, тормышын җайлау нияте белән, Татарстанга китә. Эш таба, ләкин үз фатирыннан пропискадан төшеп, яңа урында пропискага керергә туры килә. Р.Яһудин Россия гражданлыгы ала. Ләкин эш хакы бик аз була, үзе тулай торакта яши, фатирын да тиз генә вәгъдә итмиләр. Туганнары әйтүенчә, ул гаиләсен бик сагына, аның бөтен акчасы 2-3 айга бер тапкыр өенә кайтып килүгә тотыла бара.

Бераз шулай азаплангач, ул кире гаиләсенә кайтырга уйлый. Быелның мартында кунак визасы буенча Латвиягә килгәч, даими яшәү өчен рөхсәт алырга дип департаментның җирле бүлекчәсенә мөрәҗәгать итә. Түрәләр аңа, яңадан Россиягә кайтып, консуллык аша шушы документны алырга тиешсең, дип җавап бирәләр. Законны хөрмәт итүче Р.Яһудин Псковка кайтып, консуллыкка мөрәҗәгать итә. Озак кына көткәннән соң җавап ала. Анда: «ДГИ хатында күрсәтелгәнчә, РФ гражданы Равил Яһудинга, хатынының Латвиядәге статусын билгеләүче закон гамәлгә кергәнче, даими яшәү өчен рөхсәт бирмәскә», диелгән була.

Мәгълүм ки, граждан булмаганнар турындагы закон быелның 12 апрелендә кабул ителгән. Аның икенче маддәсендә, закон субъекты «законда күрсәтелгән тәртип нигезендә, үз йортында чит илдән килгән хатынын һәм аның карамагындагы балаларны һәм ата-анасын кабул итәргә хокуклы», диелгән. Бишенче маддәдә исә, шул ук икенче маддә: «Латвия туфрагында пропискада булган һәм пропискада күрсәтелгән торак мәйданының статусына бәйсез рәвештә, вакыты чикләнмичә 1992 елның 1 июленә кадәр Латвиядә яшәгән башка ил гражданнарына һәм аларның балаларына карата гына кулланыла ала», диелгән. Шулай итеп, Т.Яһудина — Латвиядә даими яшәүче булып исәпләнә һәм аның ире бу законнан файдалана ала.

Равил янадан виза ала, өенә кайта һәм төрле оешмалар буйлап йөри башлый. Җыелган документларга ул «Вирпа» предприятиесеннән (элеккеге «Латвремстанок») алынган, аны эшкә урнаштырырга гарантия бирелүе турындагы белешмәне дә өсти. Ләкин аңа департаментта яңа закон турында берни дә белмәүләре турында әйтәләр.

Латвиядә тору вакыты бетеп бара, һәм ул аннан китәргә тиеш. Тик кая китәргә соң?

Даугавпилсның урыс общинасы берлеге әгъзасы Валентин Андреев менә нәрсәләр сөйләде:

— Равил безгә киңәш сорап килде. Аңа шәһәр судына гариза язарга ярдәм иттек. Ләкин Р.Яһудин Россия гражданы һәм ул шунда судка мөрәҗәгать итәргә тиеш дип, департаментка каршы эш кузгатмадылар. Югары судка кассацион шикаять яздык, ул бу карар белән килеште. Шулай итеп, Р.Яһудин Россия суды аша Латвия оешмасы карарына протест белдерергә тиеш булып чыга иде. Абсурд бит бу! Чираттагы шикаятьне Генераль прокурорга яздык. Яһудин аннан җавапны бик түземсезләнеп көтте, нәрсәгәдер өметләнә иде бугай.

— Әтигә берни дә — гражданлык та, ташламалар да кирәкми иде. Ул гаиләсе белән яшәп, үз-үзен туйдырырлык эшкә дә риза иде, — ди Марат Яһудин. — Нигә аңа шуны да рөхсәт итмәделәр?

Соңгы вакытта ул төшенкелеккә бирелде, үзен гаиләсенә артык мәшәкать ясаучы дип саный иде

...Пәнҗешәмбе көнне Равил иртән каядыр китә. Күңелсез генә кайтып керә. Өйдә әнисе генә була. Газ плитәсенә чәйнек куя, бензин тутырылган шешә алып, яшел чирәм үскән ишегалдына чыга. Шаһитлар сөйләвенчә, бик нык пешүенә карамастан, ул аңын югалтмый. «Ашыгыч ярдәм» табибларына үз исемен, адресын әйтә. Шуннан соң да әле өч сәгать яши, дөресрәге, газапланып үлә бара...

Нигә ул моны эшләде икән? Нигә үз хокуклары өчен көрәшмәде? Фаҗигадән соң, туганнары татарча һәм урысча язылган дәфтәр табып алалар. Анда — догалар, туганнары белән бәхилләшү сүзләре. Менә 13 апрельдә язылганы. Равил, радио аша бер хикәя тыңладым, дип яза. Аның каһарманы, эстон кешесе, «Эстония — эстонлылар өчен генә» дигән язу күрә. Ул моңа нәфрәтләнеп, шигырь яза, үз халкын уйланырга, бәгырьсез булмаска чакыра. Һәм өстенә бензин сибеп, үз-үзенә ут төртә. Соңыннан ул милли каһарманга әверелә, аның нәгърә авазы күп кешеләргә барып ирешә. Халык аны аңлый. «Мин хикәяне елый-елый тыңладым, — диелә көндәлектә. — Хаксызлыкка каршы бару өчен үз-үзеңне корбан итәргә кирәк микәнни?»

Соңгы язма 9 июльдә язылган. «Еламагыз. Әгәр дә мөмкин булса, минем җәсәдемне ишегалдындагы алмагач төбенә күмегез. Тирәнрәк итеп. Мин арыдым, башка көтәр әмәлем юк».

Ул сәясәт белән кызыксынмаган, законнар өйрәнмәгән, нинди гражданлык алырга һәм кайсы оешмаларга йөрергә кирәклеген белмәгән. Аның көрәшәсе килмәгән. Ул үз йортында гаиләсе белән, гадел хезмәт белән яшәргә теләгән. Меңнәрчә кешеләр дә шуны тели. Һәм моңа ирешә алмаганнарның өметсезлеге никадәр зур икәнен һәркем аңлый торгандыр.

С.ГАРТОВАНОВА.
(«Советская Россия»).

Соңгы сүз. ***Илсез татар идең син, Равил. Үлеп баручы империянең чираттагы корбаны булып дөньядан киттең. Авыр туфрагың җиңел булсын. И Тәңрем, аерма шул татарыңны туган җирләреннән.***

ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

Йолдызларны сүндермик

«Татарстан хәбәрләре» яшәүдән туктады. Аның җирлегендә «Мәдәни җомга» газетасының беренче саннары дөнья күрде. Бу хәбәрне мөхтәрәм язучыларыбыз шатланып каршы алды. Президентыбыз да моңа: «Мәдәниятебез күгендә тагын бер йолдыз кабынды», — дип үз сөенечен белдерде.

Әмма күңел әлеге шатлыкны уртаклашырга ашыкмый. Нәрсә, моннан 2 ел элек «Татарстан хәбәрләре»н чыгара башлау ялгышлык булганмыни? Ни сәбәпле республика югарылыгындагы татар газетасы бүген беркемгә дә кирәк түгел?

Кызганычка, бу сораулар әлегә зыялыларыбызны уйландырмый да, борчымый да. Минемчә, әлеге темага сөйләшү кирәк иде. Белгәнебезчә, «Татарстан хәбәрләре» республика закон чыгаручылары органы буларак туды. Әмма ул беренче көннәрдән үк үз йөзен, тематикасын таба алмады, буталды, аптырагач, универсаль эчтәлекле «Ватаным Татарстан»ны кабатлый башлады. Нәтиҗәдә, без татар укучыларына Конституциябез положениеләрен, аерым законнарны, кеше хокукларын аңлатырга, дәүләтчелегебезне торгызу идеяләрен яктыртырга тиешле газетаны тумас борын ук югалттык. Шул сәбәп белән, суверенлыгыбызга биш ел тулган бу көннәрдә дә татар укучысы үз ана телендә юридик белем ала алмый.

Мин үзем атналык әдәбият һәм сәнгать газетасында ниләр күрергә теләр идем? Әлбәттә, беренче чиратта газета өчен кирәкле кыска жанр әсәрләрен (парчалар, нәсерләр, тәэссоратлар, сатира, рецензияләр), бүгенге әдәбиятыбызның урта кулдан уза алмау сәбәпләрен ачыклаучы, әхлаксызлыкка каршы юнәлдерелгән объектив мәкаләләрне, төрки дөньясының иң яхшы үрнәкләрен, тәнкыйть һәм үзара тәнкыйтьне.

Менә шулай, җәмәгать. Алга таба милли матбугатыбыз күгендә бер яңа йолдыз балкытабыз дип, икенчеләрен сүндермәсәк иде. Безгә дәүләт төзелеше, юриспруденция буенча да газета яки журнал бик кирәк. Тик алдагы хәлгә тарымау өчен аны чыгару эшен компетентлы кешеләр кулына тапшыру бик мөһим.

Хәлил ШӘРИПОВ,
Чаллыдагы «Таң йолдызы» газетасы мөхәррире.

Дөньябызны нурландырыгыз

Бу юлы Казанга килүемдә моңарчы күзгә чалынмаган «Мәдәни җомга» дигән яңа гәзиткә тап булдым. Күңелне үзенә тартып тора торган, матур бизәлешле, 24 битле атналык басма. Әдәбият, сәнгать, мәдәният мәсьәләләрен яктыртучы дәү күләмле бу гәзитне беренче битеннән ахырынача укып чыктым. Бик тә ошады! Татарга күптәннән нәкъ менә шундый басма кирәк иде! Афәрин! Эчендәге «нигъмәтләрен» авыз иткәч тә, бик разый булып калдым: биредә зыялыларга да, гади игенчегә дә укыр нәрсә бар.

Озын гомерле була күрсен! Бер кабынган утны сүндермичә, рухи дөньябызны нурландырып, халкыбыз өчен һәрдаим игелекле эшләр эшләп яшәгез, дуслар!

«Мәдәни җомга» Татарстан чикләрен кош кебек очып чыгып, читтә, мәсәлән, безнең Ташкентта яшәүче милләттәшләргә дә барып ирешсен! Килер көн, иншалла, «Мәдәни җомга» ерак төбәкләрдә гомер итүче милләттәшләр тормышын да яктыртыр, һәр төбәктә аның үз хәбәрчеләре булыр, дигән өметтә калам.

Кайнар Ташкент сәламе белән **Альберт ГЫЙЛЬФАНОВ,**
«Али-групп» фирмасы директоры.

Арыслан йолдызлыгы астында туганнар

КОТЛЫЙБЫЗ

18 август

МОРАТОВ Газинур Васикъ улы — шагыйрь һәм публицист, «Мәдәни җомга» атналык газетасының баш мөхәррир урынбасары.

19 август

САБИРОВ Сафа Сабир улы — язучы.

СПОРИУС Алексей Андреевич — архитектор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

20 август

АБДУЛЛИН Рәшид Фарук улы — композитор, Татарстанның М.Җәлил исемендәге комсомол бүләге лауреаты.

ВӘЛИЕВ Равил Вәли улы — язучы, публицист, «Шәһри Казан» газетасы редакциясенең бүлек мөдире.

КАЗАНЦЕВ Вячеслав Васильевич — Казан Яшь тамашачылар театры артисты.

МӘҖИТОВ Илгиз Габидулла улы — режиссер, Татарстанның һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе.

21 август

ДАУТОВ Гали Юныс улы — Казан техника университетының кафедра мөдире, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы.

КОБЧИКОВА Марина Всеволодовна — В.Качалов исемендәге Рус зур драма театры актеры, Татарстанның атказанган артисты.

МИҢНУЛЛИНА Ләлә Рафаил кызы — К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

22 август

ХАЛИТОВ Яхъя Мөхәммәтгали улы (Яхъя Халит) — язучы-тәрҗемәче.

ӘЮПОВ Харрас Гыйльмегали улы — шагыйрь, Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире.

ЮРЧЕНКО Евгений Степанович — Казан Яшь тамашачылар театры актеры, Татарстанның атказанган артисты.

23 август

НУРУЛЛИНА Фидания Нургаяз кызы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

ИХСАНОВА Ләбибә Фәиз кызы — язучы.

Иҗтиһат

Гөлләр арасында...

Мин барганда Яхъя әфәндене йоклый, диделәр. Балыктан гына кайткан икән. Әйе шул, балыкчы да бит әле ул! Менә бит кеше дигәненнең нихәтле һөнәре бар! Мин ул үстергән роза чәчәкләренә карап сокланырга, алар арасында йөреп хозурланырга дип барган идем. Розалар «профессорының» үзен дә күрәсе килә бит. Яңадан бардым инде.

Ни атлы гына, ни төсле генә розалар юк анда: нарат җиләге төслесе, караңгы алсуы, уртасы сыек алсу, читләре күе миләүшә төслесе, кып-кызылы, сап-сарысы!.. Аларның исемнәрен белсәгез сез: астильбе, нью-доун, оранж-триумф... Роза чәчәкләренең матурлыгын, аларның хуш исен сөйләп кенә аңлатып булмый, әлбәттә, аларны үз күзең белән күрергә, үз борының белән иснәп карарга кирәк.

Анда әле розалар гына түгел, башка төрле чәчәкләр дә бик күп. Климатис дигән чәчкәсе исә — үзе бер сәнгать әсәре!

— Бер елны кыш уртасында Ессентукидан роза орлыклары алып кайтып, орлыктан үстердем, — дип сөйли Яхъя әфәнде. — Ике-өч ел үсте дә үлде. Җылы якларда туган нәрсә барыбер безнең салкын кышларга түзә алмый. Бакчамда гортензияне юксынам әле, — ди ул, — марганцовканы яратмый икән — үлде. Яңадан үстерәсе бар шуны.

Яхъя Халит алмаларны да үзенчә үстерә икән.

— Алманың орлыгын алып чәчтем, — дип сөйли Яхъя әфәнде. — Үскәч, шуңа үз сортының ботагын ялгадым. Бакчамдагы бер алма агачын да питомниктан алып үстермәдем.

Сез аның алмаларының тәмлелеген белсәгез! Безнең бакчада үскәннәр ише генәме! Агачта да алар җепкә элгән сыман асылынып торалар.

— Гомерем буе «Наука и жизнь», «Знание — сила», «Цветоводство», «Рыболовство», «Шахматы» журналларын алдырып укыдым. «Цветоводство» журналының әллә ничә еллык төпләмәсе бар миндә. Ә хәзер алдырып булмый, — дип зарланып та куйды Яхъя әфәнде. Зарлану дигәннән, ул гына түгел иде әле аның зары.

— Сигез ел буена розаларымны караклар ташыды. Шулар булмаса, әллә нинди чәчәкләр үстерер идем, — ди. Нострадамус әйтмешли, җинаятьчеләр, караклар заманы килде шул...

Роза гөлләрен, башка чәчәкләрне кадерләп үстергән кебек, Яхъя әфәнде ана телен дә шулай кадерләп, тәмләп тәрҗемә итеп, күп кенә мәшһүр язучыларны татарча «сөйләштергән» кеше. Алар арасында «Тын Дон»ы, «Күтәрелгән чирәм»е белән Михаил Шолохов, «Ике капитан»ы белән Валентин Каверин, «Яңа тормыш»ы белән Вилис Лацис, «Бәхил бул, Гөлсары»сы, «Анам кыры» белән Чыңгыз Айтматов, «Өч мушкетер»ы белән Александр Дюма һәм башка бик күп язучылар да бар.

Шулар исемә төшкәч, мин аннан:

— Хәзер тәрҗемә белән шөгыльләнгән бармы соң? — дип сорап куйдым.

— Юк, — диде ул кырт кисеп. — Эшләгән чакта эшләдек инде, ә хәзер безнең бераүгә дә кирәгебез юк. Мин үзем ике дәүләтнең атказанган мәдәният хезмәткәре, хатыным «Почет билгесе» ордены кавалеры, икебезнең дә сугыш вакытында эшләгәнлеккә медальләребез бар. Ә менә өйгә телефон куйдыра алмыйбыз. 1970 елдан бирле чиратта торабыз, югыйсә.

Шул чагында минем дә, ул үстергән гөлләргә карап, хозурланган күңелләрем төшеп, боегып, кителеп киткәндәй булды...

Менә шулай яшибез инде без...

Саимә ИБРАҺИМОВА.

Әй, керпе!.. Кайларда дөнья күрке?!

Бу санда Эрот Зарипов (1 нче бит), Рушан Шәмсетдинов, Нәҗип Нәккаш, Ринат Хәсәншин, Айдар Үтәганов рәсемнәре, Әсрар Шакирҗанов, Михаил Козловский, Мидхәт Шакирҗанов, Әкрәм Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алынган фотолар файдаланылды.

Мәдәни җомга

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә телəүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты: 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4453